ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
ИСЛАМНЫ ӨЙРӘНҮ ҮЗӘГЕ

**Камил Вәлиуллин**

# ИСЛАМ ТӘРБИЯСЕ
## ДӘРЕСЛӘРЕН УКЫТУ МЕТОДЛАРЫ

КАЗАН 2013

УДК 297
ББК 86.38
В15

Рецензентлар:
**Наилә Шәүкәт кызы Вәлеева**, педагогия фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасының атказанган фән хезмәткәре;
**Наилә Мөхәммәт кызы Гизатуллина**, педагогия фәннәре кандидаты, доцент, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы.

В 15 Вәлиуллин К.Х.
Ислам тәрбиясе дәресләрен укыту методлары. Укыту әсбабы /К.Х. Вәлиуллин. - Яр Чаллы: «Ислам нуры» эшмәкәрлек үзәге. - 2013. с. 193

***Ислам тәрбиясе дәресләрен укыту методлары» укыту әсбабы ике бүлектән тора: Беренче бүлек: 1) Ислам тәрбиясе – аңлатмасы, үзенчәлекләре, вазифалары һәм максатлары; 2) Ислам тәрбиясе дәресләренең уку программалары һәм планнары – программаның аңлатмасы, Ислам тәрбиясе программасының максатлары, өлешләре һәм нигезләре; 3) укыту методлары – аңлатмасы, методларга таләпләр, методларны сайлап алуга кайбер киңәшләр. Икенче бүлек: Дини дәресләрне һәм бәйрәмнәрне уздыру методлары: 1) Коръән Кәрим дәресләре; 2) Ислам гакыйдәсе (иман) дәресләре; 3) гыйбадәт (фикһ) дәресләре; 4) хәдис дәресләре; 5) сира дәресләре; 6) әхлак дәресләре; 7) мөселман дини бәйрәмнәрен уздыру; 8) ярышлар (бәйгеләр) уздыру. Һәрбер темадан соң кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр бирелә, кушымталар китерелә.***

***Укыту әсбабы югары һәм махсус дини уку йортларында укучы шәкертләргә, шулай ук, мәдрәсәләрдә һәм мәчетләрдә дин дәресләрен укытучы мөгаллимнәргә тәкъдим ителә.***

© Вәлиуллин К.Х., 2013

© Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе, 2013

© Исламны өйрәнү үзәге, 2013

## ЭЧТӘЛЕК

**КЕРЕШ....................................................................6**
**БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК ....................................................8**
***1. ИСЛАМ ТӘРБИЯСЕ ........................................ 8***
1.1 Ислам тәрбиясенең аңлатмасы ...............................8
1.2 Ислам тәрбиясенең үзенчәлекләре............................ 11
1.3 Ислам тәрбиясенең вазифалары ..............................15
1.4 Ислам тәрбиясенең максатлары ............................. 17
1.5 Ислам тәрбиясе дәресләрен алып баруның гомум кагыйдәләре...........................................................19
Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр........................22
***2. ИСЛАМ ТӘРБИЯСЕ ДӘРЕСЛӘРЕН УКУ ПРОГРАММАЛАРЫ ҺӘМ ПЛАННАРЫ ................................23***
2.1 Программаның аңлатмасы ......................................23
2.2 Ислам тәрбиясе программасының максатлары ..23
2.3 Ислам тәрбиясе программасының нигезләре......24
2.4 Программа тәкъдим итә торган укыту методлары ..............................................................................25
2.5 Уку планы......................................................................28
Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр........................29
Кушымталар................................................................ 30
***3. УКЫТУ МЕТОДЛАРЫ ...................................33***
3.1 Укыту методларының аңлатмасы ........................33
3.2 Укыту методларына таләпләр .................................35
3.3 Укыту методын сайлап алуда кайбер практик киңәшләр ..........................................................36
Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр........................38
**ИКЕНЧЕ БҮЛЕК: ДИНИ ДӘРЕСЛӘРНЕ ҺӘМ БӘЙРӘМНӘРНЕ УЗДЫРУ МЕТОДЛАРЫ ......................39**
***1. КОРЪӘН КӘРИМ ДӘРЕСЛӘРЕ...............................39***
1.1 Коръән Кәримнең мөселманнар тормышындагы әһәмияте............................................... 41
1.2 Коръән Кәрим белән эш итү рәвеше.......................43
1.3 Коръән Кәримне уку (кыйраәт) дәресе..................44

1.4 Коръән Кәримне ятлау (хифз) дәресе......47
1.5 Тәҗвид дәресе...... 50
1.6 Тәфсир дәресе......53
Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр......57
Кушымталар ......58
*2. ИСЛАМ ГАКЫЙДӘСЕ (ИМАН) ДӘРЕСЛӘРЕ ...... 71*
2.1 Ислам гакыйдәсенең аңлатмасы, рөкеннәре, кешегә һәм җәмгыятькә булган тәэсире...... 71
2.2 Кешедә иман тәрбияләүдә Коръән Кәримдәге һәм Пәйгамбәребез с.г.в.с. сөннәтендәге методлар ... 74
2.3 Иман тәрбияләүдәге нигезләр ......76
2.4 Ислам гакыйдәсен укыту максатлары ...... 81
2.5 Ислам гакыйдәсен укыту методлары ......82
Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр......83
Кушымталар......84
*3. ГЫЙБАДӘТ (ФИКЪ) ДӘРЕСЛӘРЕ ...... 104*
3.1 Фикһның һәм гыйбадәтнең аңлатмасы......104
3.2 Гыйбадәтнең шәхес һәм җәмгыятькә булган тәэсире......107
3.3 Гыйбадәтне укыту методлары ......109
Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр...... 112
Кушымталар...... 113
*4. ХӘДИС ДӘРЕСЛӘРЕ...... 120*
4.1 Хәдиснең аңлатмасы ......120
4.2 Хәдис укытуның максатлары ......122
4.3 Хәдис укытуның үзенчәлекләре ......123
4.4 Хәдис укытуның нигезләре......124
4.5 Дәреснең этаплары ...... 124
Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр......125
Кушымталар......126
*5. СИРА ДӘРЕСЛӘРЕ...... 131*
5.1 Сираның аңлатмасы...... 131
5.2 Сира укытуның максатлары ......132
5.3 Сира укытуның үзенчәлекләре ......132

5.4 Дәреснең этаплары ........................................................ 133
Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр........................ 134
***6. ӘХЛАК ДӘРЕСЛӘРЕ .............................................. 140***
6.1 Әхлакның аңлатмасы ................................................140
6.2 Әхлакның Ислам динендәге урыны.................... 141
6.3 Кешенең ихтыяри тотышының төрләре............. 142
6.4 Әхлакның төп нигезләре ........................................ 144
6.5 Ислам әхлагының көнбатыш этикетыннан
булган аермасы ............................................................. 145
6.6 Әхлакны укытуның максатлары ........................... 146
6.7 Әхлак дәресләрен укыту методлары .................. 148
Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр........................ 149
Кушымталар.............................................................................150
***7. МӨСЕЛМАН ДИНИ БӘЙРӘМНӘРЕ ...................... 159***
7.1 Мөселман дини бәйрәмнәре................................... 159
7.2 Мөселман бәйрәмнәрен уздыру максатлары...... 161
7.3 Мөселман бәйрәмнәрен уздыру методлары........ 162
7.4 Мөселман бәйрәмнәрен уздыруга киңәшләр..... 162
Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр........................ 164
Кушымталар............................................................................. 165
***8. ЯРЫШЛАР (БӘЙГЕЛӘР) ...................................... 178***
8.1 Ярышның (бәйгенең) аңлатмасы һәм максаты . 178
8.2 Ярышны (бәйгене) уздыруга киңәшләр .............. 178
Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр.........................180
Кушымталар............................................................................. 181
***КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ...................................... 192***

إِنَّ الْحَمْدَ لِلَّهِ نَحْمَدُهُ وَ نَسْتَعِينُهُ وَ نَسْتَغْفِرُهُ وَ نَعُوذُ بِاللهِ مِنْ شُرُورِ أَنْفُسِنَا

وَ مِنْ سَيِّئَاتِ أَعْمَالِنَا و مَنْ يَهْدِهِ اللهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَ مَنْ يُضْلِلْ فَلاَ هَادِيَ لَهُ

أَشْهَدُ أَن لآ إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ وَ أَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَ رَسُولُهُ

# КЕРЕШ

Мөхтәрәм газиз кардәшләр! Үсеп килүче яшь буыныбызга дини тәрбия бирү мәсъәләсе бүгенге көндә иң мөһим урын алып тора. Тәрбия бер-берсен тулыландыручы, бер-берсеннән аерылмаучы һәм аның төп нигезе булучы өч тарафтан тора: 1) Гаилә – балага җылылык, игътибарлылык, шәфкатьлелек бирүче, балада күркәм әхлакый сыйфатлар тәрбияләүче, аны төрле хәтәр нәрсәләрдән ерагайтучы, баланың үсеш һәм укуы белән идарә итүче урын; 2) мәктәп – балага төрле тарафтан тәрбия һәм белем бирүче махсус булган урын; 3) җәмгыять – гаилә һәм мәктәптән тыш, кешеләр арасындагы элемтәләр һәм мөгамәләләр белән идарә итүче урын булып, кешене җәмгыятьтәге кануннарны һәм тәртипләрне ихтирам итүгә әзерләүче урын.

Тәрбия – ул кешене бу дөньяда һәм Ахирәттә бәхеткә ирештерә торган иң лаеклы юл. Чөнки ул шәхеснең бөтен якларын үстерә, үзенә һәм башка кешеләргә карата яхшылык эшләргә теләк тудыра, фазыйләтле булган нәрсәләргә гадәтләндерә, яхшылык белән начарлыкны аера белүне өйрәтә, ялкаулык һәм битараф булуны бетерә. Тәрбия ул – сәламәт җисем һәм сәламәт акыл, дөрес яшәү рәвешен булдыручы нәрсә. Боларның бөтенесен исә, дини кыйммәтләргә таянып эш иткәндә генә булдырырга мөмкин.

Ризаэтдин бин Фәхреддин әйтте: «Дин кешелек җәмгыяте барлыкка килеп яши башлаганнан алып, әдәп,

әхлак, шәфкать, мөрәүвәт, изгелек, итагатьлелек, кешелеклелек, намус, сафлык, пакьлек, гаделлек, яхшылык һәм башка бик күп күркәм төшенчәне эченә алган һәм бозык эшләрдән тыелып, яхшы эшләр генә эшләргә өндәгән кануннар тупланмасы һәм тәртип, тәрбия һәм әхлакның нигезе, гаиләдә тәртип сакчысы, тормышның төзек, гомернең бәрәкәтле узуына сәбәп».

Бу китап югары һәм махсус дини уку йортларында укучы шәкертләргә, шулай ук, мәдрәсәләрдә һәм мәчетләрдә дин дәресләрен укытучы мөгаллимнәргә тәкъдим ителә. Әлеге әсбаб укытучы мөгаллимнәребезнең мактаулы һәм изге эшләрендә әз генә булса да ярдәм итсә без бик шат булыр идек.

Хак Сөбханәһү вә Тәгалә ошбу хезмәтне изге гамәлләрдән кылса иде. Вафат булуыбыздан соң да бу китапны укучылар үзләренең хәер догалары белән безне шатландырсыннар иде. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә ниятләребезне күзәтеп торучы һәм туры юлны күрсәтүче!

وَآخِرُ دَعْوَانَا أَنِ الْحَمْدُ للهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ

# БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

## 1. ИСЛАМ ТӘРБИЯСЕ

1.1 Ислам тәрбиясенең аңлатмасы
1.2 Ислам тәрбиясенең үзенчәлекләре
1.3 Ислам тәрбиясенең вазифалары
1.4 Ислам тәрбиясенең максатлары
1.5 Ислам тәрбиясе дәресләрен алып баруның гомум кагыйдәләре

### 1.1 Ислам тәрбиясенең аңлатмасы

Тәрбия итү мәктәп балаларына бирелергә тиешле булган әһәмиятле төшенчәләрнең берсе санала. Күренекле галим Хуҗиәхмәтов Әнвәр Нуриәхмәтович яза:

“Мәктәп укыту процессының өч функциясен тормышка ашыра: белем бирә, тәрбияли һәм акыл сәләтен үстерә.

Укыту функциясе барыннан да бигрәк белем бирүгә караса да, аны шуңа гына кайтарып калдырырга ярамый, ул шәхескә комплексլы йогынты ясый. Күргәнебезчә, белем һәм тәрбия бирү бердәм процесс.

Белем бирү функциясе иң элек фәнни белемнәрне үзләштерүне, осталык һәм күнекмәләрне камилләштерүне күз алдында тота.

Укыту процессында тәрбия бирү функциясе дә тормышка ашырыла. Шуңа бәйле рәвештә, укучыларда уңай шәхси сыйфатлар җыелмасы – дөньяга караш, әхлак, хезмәт, этик күзаллаулар, карашлар, ышанулар, шул җәмгыятькә туры килә торган тәртип һәм эшчәнлек ысуллары; омтылыш һәм максатлар системасы: мөнәсәбәтләр, ихтыяҗлар

формалаша. Тәрбия функциясе укытуның эчтәлеге һәм методларыннан килеп чыга, ләкин шуның белән бергә, ул укытучының укучы белән махсус оештырылган мөгамәләсе аркылы тормышка ашырыла.

Белем бирү һәм тәрбия арасында берьяклы булмаган элемтә яши: укытудан тәрбиягә килү. Тәрбия процессы дөрес оештырылганда, шулай ук укыту барышына уңай йогынты ясый, чөнки дисциплина, оешканлык, иҗтимагый активлык һәм башка сыйфатлар тәрбияләү укытуны уңышлы алып барырга шартлар тудыралар. Әйткәнебезчә, укучыларның тиешле тәрбиялелегеннән башка нәтиҗәле укыту процессы мөмкин түгел.

Укытуның акыл сәләтен үстерү функциясе укучыларда үз-үзләренә ышаныч тудыручы сыйфатларны (интеллектуаль ихтыяр көчен, эмоциональлекне) үстерә торган чараларны булдыру дигәнне аңлата. Шуңа бәйле рәвештә дидактикада укытуда акыл сәләтен үстерү дигән термин кулланыла. Ул белемнәрне һәм осталыкларны формалаштыру барышында укучыларның гомуми үсеш дәрәҗәсенә йогынты ясарлык чаралар кертүне дә күз алдында тота.

Укытуда белем, тәрбия һәм акыл сәләтен үстерү функцияләре үзара үрелеп барган катлаулы элемтәдә торалар: берсе икенчесенең барлыкка килүенә сәбәп булып тора, икенчесе аның нәтиҗәсе булып һәм шул ук вакытта беренче сәбәпнең активлашуына шарт булып тора”[1].

Ислам динендә тәрбия төшенчәсенә карауның үзенә генә хас юлы бар. Мөселман галимнәре Ислам тәрбиясенә түбәндәге аңлатмаларны бирәләр:

“Ислам тәрбиясе – ул кешенең фикерләрен, хисләрен, җисемен бөтен яктан үстерү; яшәү рәвешен һәм башкалар белән аралашуын мөкатдәс Ислам дине буенча тәртипкә салу, динебез таләп иткәннәрне тормышта, гамәлдә

[1] Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Дидактика: Югары һәм махсус урта уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2002. 32-33 битләр.

үтәү, ягъни мәгълүматләрне, белемнәрне, осталыкларны арттыру”[2].

“Ислам тәрбиясе – ул Ислам дине нигезләреннән килеп чыгучы һәм кешене исламча яшәү рәвешенә алып баручы гыйлми (фәнни) юлларны тасвирлаучы төшенчәләр”[3].

“Ислам тәрбиясе – ул мөселман шәхесенең фикерләрен, хисләрен, җисемен, иҗтимагый якларын үстерү һәм аның яшәү рәвешен Ислам дине карашларына вә күрсәтмәләренә нигезләнгән рәвештә тәртипкә салу”[4].

“Ислам тәрбиясе – ул шәхесне һәм җәмгыятьне тәрбия итүче Ислам төшенчәләреннән, күнегүләрдән һәм актив эшчәнлекләрдән торган бербөтен система”[5].

Ислам тәрбиясенә бирелгән аңлатмалардан түбәндәгеләрне әйтеп була:

- Ислам тәрбиясе шәхеснең бөтен тарафларын да үстерүгә әһәмият бирә (акыл, җисем, рух);

- Ислам тәрбиясенең максаты Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылу белән бәйле булып, кешенең Раббысы белән булган элемтәсенә әһәмият бирә, иманлы Ислам шәхесен булдыра;

- Ислам тәрбиясе тәгълим (теория) белән гамәлне (практиканы) тоташтыра, чөнки Ислам тәрбиясенең максаты укучының белемнәрен арттыру гына түгел, ә, иң мөһиме, укучыга ул белемнәрне тормыш һәм реаль вакыйгалар белән бәйләп бирү, Ислам дине яшәү рәвеше булуы өчен.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

---

[2] Гармус Габдул-Мүгты. Әсәлиб тәдрис әш-шәригәти әл-исләмийәти /Ислам шәригатен укыту методлары, гарәп телендә. – Ирбид (Иордания): “Дәрул-Кинди”, 1992/1412. 7 бит.

[3] Хәсән әш-Шәркави. Нәхү тәрбияти исләмийәти /Ислам тәрбиясенең грамматикасы, гарәп телендә. – Әл-Искәндәрия (Мисыр): “Мүәссәсәтү шәбәб әл-җәмигәти”, 1983. 10 бит.

[4] Субхи И. Әт-тәрбийәтү әл-исләмийәтү вә әсәлиб тәдрисүһә /Ислам тәрбиясе һәм аны укыту методлары, гарәп телендә. – Амман (Иордания): Дару-л-әркам, 1983. 9 бит.

[5] Рамзи Г. Мәфһүмү әт-тәрбийәти әл-исләмийәти гиндә әт-тәрбәвийин әл-мүслимин фи әл-вәкти әл-хәдыр. / Хәзерге заман Ислам тәрбиясе галимнәре каршындагы “Ислам тәрбиясе”нең төшенчәсе, гарәп телендә. – Амман (Иордания): “Дару әд-дыяәү ли-н-нәшри вә әт-тәүзиг”, 1998. 233 бит.

قُلْ إِنَّ صَلَاتِي وَنُسُكِي وَمَحْيَايَ وَمَمَاتِي لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ

**“Әйт: “Укыган намазым, бугазлаган корбаным, тормышым һәм үлемем – барысы да галәмнәрнең Раббысы Аллаһ өчендер”.** *(Әл-Әнгәм, 6/162).*

## 1.2 Ислам тәрбиясенең үзенчәлекләре

1. Ислам тәрбиясенең Аллаһы Тәгалә тарафыннан (раббани) булуы, ягъни аның чыганагы Аллаһы Тәгаләнең Кәләме (Сүзе) Коръән Кәрим һәм Пәйгамбәребез с.г.в.с. сөннәте булып, Аллаһы Тәгалә тарафыннан вәхи аркылы ирешкән[6]. Шушы үзенчәлеге белән Ислам тәрбиясе кеше тарафыннан булган тәрбия системасыннан нык аерыла, чөнки алар нигез буларак кешенең чикләнгән акылына һәм иҗтимагый мөгамәлә итүгә нигезләнгән.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَكَذَلِكَ أَوْحَيْنَا إِلَيْكَ رُوحًا مِنْ أَمْرِنَا مَا كُنْتَ تَدْرِي مَا الْكِتَابُ وَلَا الْإِيمَانُ وَلَكِنْ جَعَلْنَاهُ نُورًا نَهْدِي بِهِ مَنْ نَشَاءُ مِنْ عِبَادِنَا وَإِنَّكَ لَتَهْدِي إِلَى صِرَاطٍ مُسْتَقِيمٍ صِرَاطِ اللَّهِ الَّذِي لَهُ مَا فِي السَّمَاوَاتِ وَمَا فِي الْأَرْضِ أَلَا إِلَى اللَّهِ تَصِيرُ الْأُمُورُ

**“Менә, шулай итеп, сиңа да әмеребез илә Коръәнне вәхи иттек. Син Коръәннең ни икәнен дә, иманның ни икәнен дә белми идең. Әмма Без (теләгән) бәндәләребезне шушы китап ярдәмендә тугры юлга өндәр өчен нур иттек. Шөбһәсездер ки, син тугры юлны күрсәтүче. Ул – Күкләрнең вә Җирнең хуҗасы Аллаһның юлыдыр. Аң булыгыз! Бөтен эшләр ахырда Аллаһ хозурына барып тоташачак!”** *(Әш-Шура, 42/52-53).*

---

[6] Коръән Кәримнең сүзе дә, мәгънәсе дә Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелгән. Сөннәтнең мәгънәсе вәхи аркылы ирешкән, ә Пәйгамбәребез с.г.в.с. ул мәгънәләрне үз сүзләре, гамәлләре һәм тик торулары белән кешеләргә җиткергән. Кодси хәдисләр дә шуның шикелле.

وَلَكِنْ كُونُوا رَبَّانِيِّينَ بِمَا كُنْتُمْ تُعَلِّمُونَ الْكِتَابَ وَبِمَا كُنتُمْ تَدْرُسُونَ

**“Ләкин пәйгамбәр: “Аллаһ китабыннан өйрәнгәнегез белән вә пәйгамбәрдән дәрес алганыгыз белән Раббыгыз булган Аллаһка гына кол булыгыз, Аңа гына гыйбадәт кылыгыз”, – дип әйтергә бурычлы”.** *(Әли Гыймран, 3/79).*

2. Бербөтен булуы: кешенең хәзерге дөнья тереклегенең барча тарафларын һәм киләчәктә булучы Ахирәт тормышына әзерләвен үз эченә алуы, шулай ук кешегә төрле яктан бербөтен итеп каравы (җисем, акыл, рух).

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَابْتَغِ فِيمَا آتَاكَ اللَّهُ الدَّارَ الْآخِرَةَ وَلَا تَنسَ نَصِيبَكَ مِنَ الدُّنْيَا وَأَحْسِنْ كَمَا أَحْسَنَ اللَّهُ

إِلَيْكَ وَلَا تَبْغِ الْفَسَادَ فِي الْأَرْضِ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ الْمُفْسِدِينَ

**“Аллаһ сиңа биргән малдан Ахирәтне кәсеп ит. Дөньядагы өлешеңне дә онытма. Аллаһ сиңа мал биргән кеби син дә мохтаҗ кешеләргә малыңнан бир. Җир йөзенә бозыклык таратма. Тәхкыйк, Аллаһ бозыкларны сөйми”.** *(Әл-Касас, 28/77).*

3. Гармонияле булуы: кешенең Яратучысы Аллаһы Тәгалә белән, үзе, туганнар һәм җәмгыятьтәге кешеләр белән, матди һәм рухи нәрсәләр, дөнья һәм Ахирәт белән килешле (гармонияле) рәвештә мөгамәлә итүе. Кешеләр, тигез һәм мөстәкыйль тормыш алып барулары өчен, бер-берсенең чикләрен үтмичә, бер-берсе белән килешкән хәлдә булулары зарур.

4. Ислам тәрбиясенең какшамас һәм сыгылмалы (гибкий) булуы: төп төшенчәләренең һәм нигезләренең үзгәрмәс һәм какшамас булуы, тармакларының исә, үсеш һәм үзгәртүне кабул итүе.

Ислам тәрбиясенең максатлары, Галәмгә, Кешегә, Тереклеккә һәм алар арасындагы бәйләнешләре хакындагы карашлары, шәхеснең сыйфатларына карата карашлары, Ислами кыйммәтләренең системасы, заманнар вә урыннар үзгәрүе белән, үзгәрмәс һәм какшамас.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

إِنَّا نَحْنُ نَزَّلْنَا الذِّكْرَ وَإِنَّا لَهُ لَحَافِظُونَ

**“Тәхкыйк, Без Зикерне (Коръәнне) иңдердек һәм тәхкыйк, аны, әлбәттә, саклыйбыз”.** *(Әл-Хиҗер, 15/9).*

Шәхес һәм җәмгыятьне тәрбия итүдә куллана торган чаралар һәм методлар исә, үзгәрүчән һәм үсешне кабул итүче. Бу аермага аеруча игътибар итү кирәк, чөнки кайбер кешеләр Ислам тәрбиясенең төп төшенчәләрен һәм нигезләрен, аның методлары һәм тәрбияви чаралары белән бутыйлар, аларның араларын аера алмыйлар.

5. Камиллекле булуы: белемне, сәләтне, осталыкны арттыру, әйләнә-тирәдәге нәрсәләр хакында дөрес, төпле фикер һәм уңай юнәлеш булдыру. Төп максат – Аллаһы Тәгаләне тану һәм Аңа иман китерү.

6. Кешелекле булуы: кешедә уңай кыйммәтләр булдыру. Аллаһы Тәгалә кешенең Яратучысы, барча әмерләрнең Патшасы. Шул сәбәпле, кешедә Яратучысына яисә үзенә яки кешеләргә карата тискәре мөнәсәбәткә урын калдырмау.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَقُلِ اعْمَلُوا فَسَيَرَى اللَّهُ عَمَلَكُمْ وَرَسُولُهُ وَالْمُؤْمِنُونَ

**“Әйт: “Изге гамәлләр кылыгыз! Әлбәттә, Аллаһ вә Аның рәсүле һәм мөэминнәр сезнең гамәлләрегезне күрерләр”.**

*(Әт-Тәүбә, 9/105).*

7. Әхлаклы булуы. Коръән Кәримдә әхлакка карата мөһим нәрсәләр бар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. югары дәрәҗәдәге әхлак өчен иң олугъ мисал һәм нигезле чыганак булып тора. Ислам тәрбиясе үсеп килүче буыннарда өстенлекле әхлак булдырырга омтыла. Ислам әхлагы динебезнең аерылмас өлеше булып, иманлы булуны һәм яшәү рәвешен шәригать хөкемнәре буенча алып баруның җимеше булып тора. Ул җиңел һәм гади булуы белән аерылып тора, кешенең табигатенә туры килә, һәрбер кеше аны көчләп

түгел, үз ихтыяры белән кабул итә. Кешенең Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләгә якын булуы өчен мөһим күрсәткеч булып тора.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَنَفْسٍ وَمَا سَوَّاهَا فَأَلْهَمَهَا فُجُورَهَا وَتَقْوَاهَا

**"Һәр адәми затка һәм аны (Җир йөзендә яшәрлек итеп) яралткан Аллаһ белән ант итәм. Өйрәтте Аллаһ ул нәфескә явызлыкны һәм өйрәтте тәкъвалыкны, яхшылыкны".**

*(Әш-Шәмс, 91/7-8).*

Кеше вакыт-вакыт начарлык кылырга этәрелсә дә, аңарда шәһвәтен тыю, начарлык эшләүне кире кагу кодрәте бар. Шул сәбәпле Ислам дине кешегә җаваплылыкны йөкләү белән бергә кешенең ихтыяр көчен, тырышуын, сабырлыгын тәрбияләүгә көчен юнәлдерә.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَلْتَكُن مِنْكُمْ أُمَّةٌ يَدْعُونَ إِلَى الْخَيْرِ وَيَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ

وَيَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنْكَرِ وَأُوْلَئِكَ هُم الْمُفْلِحُونَ

**"Сезләрдән арагызда хәерле эшләргә чакыручы һәм фәхеш гамәлләрдән тыючы кешеләр, әлбәттә, булсын! Әнә шундый кешеләр булган җәмәгать һәлак булудан котылып, өстенлек табучыдыр".** *(Әли Гыймран, 3/104).*

Исламдагы әхлак тәрбиясе яхшылыкка омтылу һәм начарлыктан ераклашу кешенең табигатенә туры килүдән гыйбарәт.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

إِنَّ اللَّهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالإِحْسَانِ وَإِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ

الْفَحْشَاءِ وَالْمُنكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ

**"Тәхкыйк, Аллаһы Тәгалә һәр эштә гадел булырга, яхшы эшләр кылырга вә якын кардәшләрнең хакын үтәргә боерадыр. Һәм Аллаһ сезне фәхеш эшләрдән һәм зураеп хактан ка-**

**чудан, хаксыз золым итүдән тыядыр. Аллаһ сезне вәгазьли, шаять вәгазьләнерсез!”** *(Ән-Нәхел, 16/90).*

8. Гамәли булуы: тормышны алып бару өчен сәләтләрне булдыру. Шушы сәләтләрне хәләл кәсеп өчен эшләтүгә омтылдыру.

9. Ислам тәрбиясенең фарыз булуы. Аллаһы Тәгаләнең барлыгына иман китерү, ялгыз бер Үзенә генә итагать итүне тәрбияләү белән Ислам шәригате гамәлгә ашырыла. Ислам тәрбиясе әти-әниләргә, укытучыларга, тәрбия өчен җаваплы булучыларга фарыз. Киләсе буыннарга аны тапшыру әманәт булып тора. Аллаһы Тәгалә Үзенең пәйгамбәре аша барча кешеләргә шәригатен иңдерде, аның белән гамәл итүне фарыз кылды. Кеше үз өстендәге әманәтен үтәргә һәм шәригать белән гамәл кылырга кадир булуы өчен аның шуңа әзер булуын, тәрбия алуын таләп итә.

## 1.3 Ислам тәрбиясенең вазифалары

***1. Рухка карата вазифалар.***

Аллаһы Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә, Раббыбызның барча кылган эшләребезне күзәтеп торуына, фәрештәләргә, китапларга, пәйгамбәрләргә, Ахирәт көненә, кубарылуга, хисапка, Җәннәткә, Җәһәннәмгә, савап алуына яисә газап ителүенә һ.б. зарур булган нәрсәләргә катгый рәвештә иман китерүгә нигезләнүе.

***2. Нәфескә карата вазифалар.***

Нәфеснең сабыр, батыр булуы, ирешкән авырлыкларны күтәрү, игелекле, мәрхәмәтле, дөрес сүзле, әманәтле, начарлыклардан ерак булуы, динебез чакыручы башка нәрсәләргә иҗтиһад итүгә нигезләнүе.

***3. Иҗтимагый вазифалар.***

Тәкъвалыкка, әмерләргә буйсынуга, тыелганнардан ерак булуга, итагатькә хирыс булуга, кешеләр арасындагы

бәйләнеш һәм мөгамәләләрне тәртипкә салуга нигезләнүе. Кеше хакларын белеп, аның чикләрен үтмичә, гамәл итәргә тиешле эшләрен белеп камиллеккә алып баруы. Һәрбер җитәкче, аның җитәкчелегендә эшләүчеләр өчен, җаваплы икәнен белүе.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَالْمُؤْمِنُونَ وَالْمُؤْمِنَاتُ بَعْضُهُمْ أَوْلِيَاءُ بَعْضٍ يَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَيَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ وَيُقِيمُونَ الصَّلَاةَ وَيُؤْتُونَ الزَّكَاةَ وَيُطِيعُونَ اللَّهَ وَرَسُولَهُ أُوْلَئِكَ سَيَرْحَمُهُمُ اللَّهُ إِنَّ اللَّهَ عَزِيزٌ حَكِيمٌ

**“Мөэмин ирләр вә мөэминә хатыннар бер-берсенә дуслар вә ярдәмчеләр: алар кешеләрне иманга, дингә вә яхшылыкка өндәрләр һәм начарлыклардан тыярлар, намазларын вакытында үтәп, зәкятләрен бирерләр вә һәр эштә Аллаһка һәм Аның рәсүленә итагать итәрләр, шундый кешеләргә Аллаһ тиз рәхмәт кылыр, тәхкыйк, Аллаһ – Газиз вә Хәким”.**

*(Әт-Тәүбә, 9/71).*

***4. Акылга карата вазифалар.***

Фикерләүгә, төрле яктан уйлап карауга нигезләнүе.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَفِي الْأَرْضِ آيَاتٌ لِلْمُوقِنِينَ وَفِي أَنفُسِكُمْ أَفَلَا تُبْصِرُونَ

**“Иманнарында нык рух белән торганнар өчен фани дөньяда аятьләр (Коръәннең хаклыгына дәлилләр) китердек. Дәхи үзегезнең төзелешегездә дә моңа дәлилләр бар. Шуны да күрмисез!”** *(Әз-Зәрият, 51/20-21).*

***5. Мисал китерү вазифасы.***

Кешеләр белән мөгамәләдә һәм тормыш алып баруда үрнәк булу өчен мисаллар китерү.

## 1.4 Ислам тәрбиясенең максатлары

***I. Гомум максатлары.***

1) Диннең нигезләрен, гадәтләрен саклау, Аллаһы Тәгаләнең йортлары дип саналган мәчетләрне сөю, чөнки Исламга чакыру бөтен кешеләргә дә юнәлгән, ә аерым кешеләр яисә берәр җирлек белән генә чикләнмәгән.

2) Чын күңелдән дингә һәм аның әдәпләренә бирелү юлы аша, иң беренче урынга югары әхлакый нигезләрне куючы шәхесне булдыру.

3) Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең сирасын, сәхабәләрне, табигиннарны, табгү-табигиннарны, Ислам диненә зур өлеш керткән мәшһүр шәхесләрне, галимнәрне ихтирам итү.

4) Көч-кодрәтен реаль тормышка һәм иҗтимагый халәткә карата юнәлдергән, начар булган нәрсәләргә һәм өметсезлеккә буйсынмаган, ә матди сәбәпләрен булдырып, Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл итүче шәхесне тәрбияләү.

5) Гамәл башкаруны һәм аны осталык белән башкаруны сөюче, ризыкның иң хәерлесе хәләл икәнен аңлаучы шәхес тәрбияләү.

6) Бер-береңә ярдәм итүгә, бүләкләр бирешүгә мәхәббәт ояту; җәмәгать белән эшләнә торган эшләрдә катнашучы, аның проблемаларын хәл итүче һәм үзен генә сөюдән ерак булучы шәхес тәрбияләү.

7) Гаиләсен сөюче һәм аның мәнфәгатьләрен кайгыртучы, туганлык җепләрен саклаучы шәхес тәрбияләү.

8) Җәмгыятьне начар якка тайпылудан, Ислам гакыйдәсенә һәм аның максатларына каршы килүче нәрсәләрдән саклау.

9) Мөселманнарның бер-берсе белән булган элемтәләрен ныгыту.

10) Кешегә һәм җәмгыятькә зарар китерүче, Ислам гакыйдәсенә каршы килүче хорафатлар һәм гадәтләрдән ераклашу.

11) Ислам дине нигезләрен саклаучы, чисталык-пөхтәлеккә, матурлыкка, җисемен көчле һәм сәламәт тотуга чакыручы шәхес тәрбияләү.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. әйтте: “Аллаһы Тәгалә каршында көчле мөэмин зәгыйфь булучыдан хәерлерәк һәм сөеклерәк”.

***II. Аерым максатлар.***

1) Аллаһы Тәгаләнең исем-сыйфатларын, ачык һәм яшерен әйтүнең дәрәҗәләрен белү, Аллаһы Тәгалә разый булган барча гамәлләрне эшләү һәм Ул ачуланган гамәлләрдән ераклашу.

2) Динебез алып килгән әмер һәм тыюларның, белемнәрнең барчасы кешенең һәм җәмгыятьнең үзе өчен. Безгә исә, биргән нигъмәтләре өчен, сүз белән дә һәм гамәл белән дә, Аллаһы Тәгаләгә шөкер итәргә тиешбез икәнлеген аңлату.

3) Укучыларда Аллаһы Тәгаләгә тәкъвалыкны үстерү, нәфесләрдә (тойгы һәм хаҗәтләрдә) дини этәргеч сәбәпләрне гадәтләндерү.

4) Коръән Кәримгә мәхәббәт уяту һәм аны дөрес укуга этәрү, аңа карата хөрмәт тәрбияләү, мәгънәләрен аңлау һәм аятьләре хакында фикерләү.

5) Укучыларны хәдис-шәрифләр белән таныштыру һәм алардан хөкемнәр чыгаруга этәрү (истә калдырулары һәм алар буенча гамәл итүләре өчен).

6) Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең, сәхабәләрнең һәм мәшһүр шәхесләрнең тормышыннан күркәм үрнәкләр эзләү.

7) Укучыларга гыйбадәт һәм мөгамәләт хөкемнәрен аңлату, шуларга туры китереп гамәл кылулары өчен.

## 1.5 Ислам тәрбиясе дәресләрен алып баруның гомум кагыйдәләре

***Дәресне башлау***

Укытучы сыйныфка дәрес алдыннан кереп, балаларның дәрескә әзерлекләрен тикшерә: тактаның чисталыгы, акбурның (маркерның) барлыгы, партада фәкать дәрескә кагылышлы әсбапларның булуы һәм аларның партаның кырыенда булулары.

Укытучы балаларның тәһарәтле булырга тиешлекләрен искә төшерә һәм кемнең тәһарәте булмаса, аны дәрес башлаганчы алырга кирәклеген әйтә.

Дәрес башлану белән укучылар басалар һәм укытучы балаларга: «Әс-сәләәмү-гәләйкүм» дип әйтә, ә балалар «Вә гәләйкүмүс-сәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү» дип кайтаралар.

Укытучы: «Әгүзү билләһи минәш-шайтанир-раҗим. Бисмил-ләһир-рахмәнир-рахим» дип дәресне башлап җибәрә (балалар белән бергә әйтелсә яхшырак та була).

Соңыннан дәрес башлар алдыннан әйтелә торган дога укыла:

1) Башлангыч сыйныф (1-4) укучылары түбәндәге доганы укыйлар:

رَبِّ زِدْنِي عِلْمًا نَافِعًا

*(Рабби зиднии гилмән-нәәфигән)*

Мәгънәсе: “Я Рабби, миңа файдалы гыйлем арттырырга насыйп әйлә!”

2) Башка сыйныф укучылары түбәндәге доганы укыйлар:

اللهمَّ ارْزُقْنَا عِلْمًا نَافِعًا وحِفْظًا كَامِلاً وَذِهْنًا شَامِلاً وَفَهْمًا ذَكِيًّا وَتَوْفِيقًا لِتَحْصِيلِ الْعُلُومِ.

اللهمَّ أخْرِجْنَا مِنْ ظُلُمَاتِ الْجَهْلِ وَالْوَهْمِ وَأكْرِمْنَا بِنُورِ الْعِلْمِ وَالْفَهْمِ. اللهُمَّ افْتَحْ لَنَا أبْوَابَ عِلْمِكَ وَانْشُرْ عَلَيْنَا خَزَائِنَ رَحْمَتِكَ. بِرَحْمَتِكَ يَا أرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

*(Әл-Лааһүммә-рзүкнәә гилмән нәәфигән вә хифзән кәәмилән вә зиһнән шәәмилән вә фәһмән зәкиййән вә тәүфиикан литәхсыылил-гүлүүм. Әл-Лаһүммә әхриҗнәә мин зулүмәәтил-җәһли вәл-вәһми вә әкримнәә бинүүрил-гилми вәл-фәһми. Әл-Лаһүммә-фтәх ләнәә әбвәәбә гилмикә вән-шүр гәләйнәә хазәәинә рахмәтик. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин).*

Мәгънәсе: "Я Рабби, безгә файдалы гыйлемлекне һәм күңелгә тәмам алуны һәм киң зиһенне һәм зирәк аңлауны насыйб ит. Я Рабби, безне наданлык һәм күңел караңгылыгыннан чыгарып, гыйлем һәм аңлау нуры белән хөрмәтлә. Я Рабби, безгә гыйлемлек ишекләрен ач һәм рәхмәт хәзинәләреңне чәч. Әй камил рәхмәт кылучы Аллаһ, һәрбер нәрсә Синең рәхмәтең белән генә булыр".

Әгәр укытучы кыңгырауга хәтле сыйныфка керергә өлгермәгән булса, югарыдагыларны үтәгәннән соң дәрескә әзерлекләрен тиз генә тикшереп чыга һәм дәресен башлап җибәрә.

***Дәреснең барышы***

Кызлар белән малайлар аерым утыралар. Малайларның алгы парталарда яисә аерым рәттә утыруы хуплырак күренә.

Дәресне Аллаһы Тәгалә, Коръән Кәрим, Ислам динебез нигезләре белән бәйләп алып бару юлларын табарга.

Дәрес арасында, укучылар ял итеп алулары өчен, физкультминуткалар уздыру.

Сорауга җавап бирү өчен укучылардан кул күтәрүне таләп итү.

Дәрес барышында укучыларның дөрес утыруларына игътибар итәргә, вакытында кисәтү ясарга.

Өй эшен дәрес беткәнче бирергә тырышу, ничек эшләргә икәнлеген аңлатып бирү һәм язып алганнарын тикшереп чыгу.

***Дәреснең ахырында***

Дәрес бетәр алдыннан түбәндәге дога укыла:

الحَمْدُ للهِ الَّذى أخْرَجْنَا مِنْ ظُلُماتِ الجَهْلِ وَالوَهْمِ. وَنَوَّرَ قُلُوبَنَا بِنُورِ الْعِلْمِ وَالفَهْمِ.

اللهُمَّ اغْفِرْ لَنَا وَلِوَالِدَيْنَا وَلِأُسْتَاذِنَا وَسَلِّم دِينَنا وَاجْعَلْ مَلِكَنا سَالِمًا وَرَؤُفًا لَنا بِحَقِّ نَبِيِّنَا

محمدِ الْمُصْطَفَى صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ.

*(Әлхәмдү лил-Ләәһи-лләзии әхраҗнәә мин зулүмәәтил-җәһли вәл-вәһми. Вә нәвввәра кулүүбәнәә бинүүрил-гилми вәл-фәһми. Әл-Лаһүммә-гфир ләнәә вә ли-вәәлидәйнәә вә ли-үстәәзинәә вә сәллим диинәнәә вә-җгәл мәликәнәә сәәлимән вә раүфән ләнәә бихәккы нәбиййинәә Мүхәммәдинил-Мүстафәә салләл-Лааһү гәләйһи вә сәлләм).*

Мәгънәсе: “Һәрбер мактау Аллаһы Тәгаләгә хас. Ул Аллаһы Тәгалә безне наданлык һәм аңламаулык караңгылыгыннан чыгарды һәм шулай ук безнең күңелләребезне гыйлем һәм аңлау нуры белән нурландырды. Я Рабби, пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа с.г.в.с. хакына безнең гөнаһларыбызны һәм шулай ук ата-ана һәм остазларыбызның гөнаһларын кичер, динебезне дә, дөньябызны да төзек һәм сәламәт кыйл һәм шулай ук патшабызны сәламәт һәм безгә шәфкатьле вә мәрхәмәтле кыйл”.

Кыңгырау булу белән дәрес тәмәмлана (тәнәфес вакытында укучыларны дәрескә кагылышлы мәсъәләләр белән мәшгуль иттермәү).

Укытучы балаларга «Әс-сәләмү гәләйкүм», балалар исә, аягурә баскан хәлдә «Вә-гәләйкүмүс-сәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү» дип кайтаралар.

## Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр:

1. Тәрбия сүзе нинди мәгънәләрдә кулланыла?

2. Ислам тәрбиясенә нинди аңлатмалар бирелә? Шул аңлатмаларны китерегез.

3. Ислам тәрбиясенең үзенчәлекләрен, аңлатмалары белән, китерегез.

4. Ислам тәрбиясенең вазифалары нидән гыйбарәт?

5. Ислам тәрбиясенең гомум һәм аерым максатларын санап чыгыгыз.

6. Ислам тәрбиясе дәресләрен алып баруга нинди кагыйдәләр бар? Укыту әсбабында китерелгән кагыйдәләргә өстәп тагын нинди кагыйдәләр китерер идегез?

# 2. ИСЛАМ ТӘРБИЯСЕ ДӘРЕСЛӘРЕН УКУ ПРОГРАММАЛАРЫ ҺӘМ ПЛАННАРЫ

2.1 Программаның аңлатмасы
2.2 Ислам тәрбиясе программасының максатлары
2.3 Ислам тәрбиясе программасының нигезләре
2.4 Программа тәкъдим итә торган укыту методлары
2.5 Уку планы

## 2.1 Программаның аңлатмасы

Программаның (гарәп телендә "мәнһәҗ") шәригатьтәге аңлатмасы: "Дәресләр аша өйрәнелә торган мәгълүматлар, хакыйкатьләр, төшенчәләр, фикерләр, белемнәр, методлар һәм осталыклар җыелмасы".

Әнвәр Нуриәхмәт улы Хуҗиәхмәтов яза: "Уку программасы системалы һәм эзлекле рәвештә уку фәннәрен бүлекләргә, темаларга, пунктларга бүлә. Программа лаборатор һәм практик занятиеләрне, экскурсия һәм тәҗрибәләрне, мөстәкыйль эшләрне һәм махсус күзәтүләрне, теоретик белемнәрнең тиешле күләмен, укучы ия булырга тиешле белем һәм күнекмәләрне билгели"[7].

## 2.2 Ислам тәрбиясе программасының максатлары

1. Шәхеснең омтылышларын, сәләтләрен, гадәтләрен, рухи кыйммәтләрен бөтен яктан үстерү.

2. Җәмгыятьтә булган максатларны тормышка ашыру. Җәмгыятьтәге максатлар Коръән Кәрим һәм Пәйгамбәребез

[7] Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Дидактика: Югары һәм махсус урта уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2002. 52 бит.

с.г.в.с. нең сөннәтеннән алына. Шул сәбәпле аның максатлары матди гына түгел, ә рухи һәм матди була.

3. Укыту тәртибенең, мәктәпнең, җәмгыятьнең ярдәм итүе белән укучыга укыту-тәрбия бирү.

Ислам тәрбиясе программасының максатларының түбәндәге нигезләре билгеләнгән булырга тиеш: а- Ислам гакыйдәсе белән туры килүе; ә- укыту баскычларының (башлангыч, төп, урта) бер-берсе белән килешенгән булуы; б- башкарылырга таләп ителүче нәрсәләрнең бөтен төрләрен үз эченә алуы (акыл, психик халәте, яшәү рәвеше, рух); в- тәгъбирнең (формулировканың) төгәл һәм ачык булуы; г- чынбарлыкка туры килүе (башкару һәм чагыштыру өчен кабул ителүче булу).

## 2.3 Ислам тәрбиясе программасының нигезләре

1. Игътикад нигезләре: а) Гакыйдә (иман) белән нык бәйләнгән булуы (бу бик мөһим, аннан чыгып китү һич дөрес түгел); ә) кеше - Аллаһы Тәгалә тарафыннан бар ителгән мәхлук һәм ул - ихтирам ителергә тиешле шәхес; һәрбер шәхес үзенең теләкләре, фикерләре, ихтыяр көче белән аерылып тора; б) дөнья яшәеше - Ахирәт тормышына әзерлек кенә; в) Ислам дине Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелгән ахыргы хөкемнәр, Мөхәммәд с.г.в.с. пәйгамбәрләрнең мөһере; г) иман гамәл кылуны таләп итә, иман гамәлсез, гамәл имансыз була алмый, алар нык бәйләнештә торалар.

2. Белем нигезләре: а) Ислам гыйлемнәренең һәм тәҗрибә юлы белән барлыкка килгән гыйлемнәренең Исламның галәм, кеше, тормыш хакындагы карашы, фикере (Ислам гакыйдәсе) белән килешенгән берлектә булуы; ә) гарәп теле - Ислам гыйлемнәренең чыганагы (нигезе); б) тормыш

өчен кирәкле белемнәр мөселманнар өчен фарыз кифая[8], шәригать белемнәре фарыз гаен[9] дип санала.

## 2.4 Программа тәкъдим итә торган укыту методлары

Кешелекне илаһи нур белән тәрбияләү һәм туры юлга күндерү өчен Ислам тәрбиясе дәресләрен укыту методларының иң хәерлесе – Коръән Кәрим һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. сөннәтендә килгән методлар булып тора:

1. Коръән Кәримдә һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. сөннәтендәге кара-каршы сөйләшү методы; ике яисә күбрәк кеше арасындагы бер темага һәм бер максатка нигезләнгән сорау-җавап методы.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَضَرَبَ لَنَا مَثَلًا وَنَسِيَ خَلْقَهُ قَالَ مَن يُحْيِ الْعِظَامَ وَهِيَ رَمِيمٌ قُلْ يُحْيِيهَا الَّذِي أَنشَأَهَا

أَوَّلَ مَرَّةٍ وَهُوَ بِكُلِّ خَلْقٍ عَلِيمٌ

**“Ул үзенең ничек яратылганын онытып: - Бу черемеш сөякләргә кем җан өрә алсын? – дип, Безгә хәйләле сорау бирә. (Ий, Мөхәммәд) әйт син: - Аларны иң беренче яралткан (Аллаһ) терелтәчәк. Ул һәр яралтылганны асылы белән белүчедер”.** *(Ясин, 36/78-79).*

Әбү Һурайра р.а.г. дән риваять ителә: Пәйгамбәребез с.г.в.с. әйтте: «Иң куркыныч, үтергеч 7 гөнаһтан саклагыз». Сәхабәләр әйтте: «Әй, Рәсүлуллаһ нинди ул гөнаһлар?»

---

[8] Фарыз кифәя – һәр мөселман өстендә аны үтәү бурыч булса да, ләкин араларыннан берсе яисә берничәсе башкару сәбәпле башкаларның өсләреннән төшә торган фарыз. Бу гамәлне башкаручы саваплы була. Ләкин бу гамәлне мөселманнарның берсе дә башкармаса, аларның барчасы гөнаһлы (фасик) була (мәсәлән: мәеткә җеназа намазы укылуы).

[9] Фарыз гаен – һәр мөселман өстендә аны үтәү бурыч булып тора һәм араларыннан берсе яисә берничәсе башкару сәбәпле башкаларның өсләреннән төшми торган фарыз (мәсәлән: көненә биш вакыт намаз уку).

Ул әйтте: «Аллаһы Тәгаләгә ширек итү, сихерчелек, гаепсез кеше үтерү, риба ашау, ятимнең малын хаксыз ашау, сугыш кырыннан качу, гыйффәтле мөселман хатын-кызны зина кылуда гаепләү». (Бохари, Мөслим, Әбү Дауд).

2. Коръән Кәримдә зекер ителгән пәйгамбәрләр, элек яшәгән халыклар хакындагы кыйссалар һәм тәрбияви кыйссалар белән тәрбияләү (бигрәк тә башлангыч сыйныфларда).

3. Коръән Кәрим һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. сөннәтендәге гыйбрәтле хикәяләр белән тәрбияләү (гыйбрәтле хикәяләр мәгънәләрне аңлау өчен кулланыла).

Аллаһы Тәгалә әйтә:

مَثَلُ الَّذِينَ حُمِّلُوا التَّوْرَاةَ ثُمَّ لَمْ يَحْمِلُوهَا كَمَثَلِ الْحِمَارِ يَحْمِلُ أَسْفَارًا بِئْسَ مَثَلُ الْقَوْمِ الَّذِينَ كَذَّبُوا بِآيَاتِ اللَّهِ وَاللَّهُ لَا يَهْدِي الْقَوْمَ الظَّالِمِينَ

**“Тәүрат китабы бирелеп тә, аның буенча гамәл кылмаган бәндәләрнең хәле тау-тау китап төягән ишәкнеке кебектер. (Күп китап ташыса, ишәккә белем кермәс) Аллаһның аятьләрен бозып күрсәтүче кавемнең хәле бик тә яман. Аллаһ залимнәрне тугры юлга күндермәс”.** *(Әл-Җомга, 62/5).*

Әбү Һурайра р.а.г. дән риваять ителә: “Ул Рәсүлүллаһ с.г.в.с. нең түбәндәге сүзләрне әйткәнен ишеткән: “Сезләрнең берегезнең ишеге янында бер елга булып, шул елгага көненә биш тапкыр кереп коенып чыкса, тәнендәге пычрагыннан нәрсә булса да калыр идеме?” Әйттеләр алар: “Юк, әлбәттә, пычрагыннан бер нәрсә дә калмас иде”. Әйтте ул: “Шуның шикелле, көненә биш вакыт намаз укучының Аллаһы Тәгалә гөнаһларын юып төшерә”. (Мөслим).

4. Үрнәк белән тәрбияләү.

Аллаһы Тәгалә барча пәйгамбәрләрне һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. не кешеләр алардан үрнәк алулары һәм дини тәрбияне тормышка ашырулары өчен җибәрде.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

لَقَدْ كَانَ لَكُمْ فِي رَسُولِ اللَّهِ أُسْوَةٌ حَسَنَةٌ لِمَنْ كَانَ يَرْجُو اللَّهَ وَالْيَوْمَ الْآخِرَ وَذَكَرَ اللَّهَ كَثِيرًا

**"Тәхкыйк, Аллаһ рәсүлендә сезгә ияренгә тиешле булган күркәм холык вә яхшы сыйфатлар бардыр, Аллаһтан савапны һәм Ахирәттә Җәннәтне өмет иткән хәлдә Аллаһны күп зекер итүче мөэминнәр өчен".** *(Әл-Әхзәб, 33/21).*

قَدْ كَانَتْ لَكُمْ أُسْوَةٌ حَسَنَةٌ فِي إِبْرَاهِيمَ وَالَّذِينَ مَعَهُ

**"Тәхкыйк, сезгә Ибраһим пәйгамбәрдә вә аңа ияргән мөэминнәрдә яхшы үрнәк булды".** *(Әл-Мумтәхәнә, 60/4).*

Укытучыга балалар өчен төрле үрнәкләр китерү бик мөһим, чөнки укучылар, бигрәк тә башлангыч сыйныфтагылар, олыларның эшләрен (яхшымы яисә башкамы) кабатлыйлар.

5. Күнегүләр үткәрү һәм гамәли яктан башкару белән тәрбияләү, мәсәлән, тәһарәт алдыру, намаз укыту, авыруның хәлен белү һ.б.

6. Нәсыйхәт бирү белән тәрбияләү.

Пәйгамбәрләр кыйссаларыннан, тарихи вакыйгалардан, сәхабәләрнең, табигиннарның, салих һәм мөхтәрәм мөселманнарның тормышларыннан өстенлекле гамәлләрен, яхшы якларын китерү.

7. Кызыксыну уяту һәм дөньядан имансыз китүдән курку белән тәрбияләү.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

ادْعُوا رَبَّكُمْ تَضَرُّعًا وَخُفْيَةً إِنَّهُ لَا يُحِبُّ الْمُعْتَدِينَ وَلَا تُفْسِدُوا فِي الْأَرْضِ بَعْدَ إِصْلَاحِهَا وَادْعُوهُ خَوْفًا وَطَمَعًا إِنَّ رَحْمَةَ اللَّهِ قَرِيبٌ مِنَ الْمُحْسِنِينَ

**"Раббыгызга ялвара-ялына, аулакта дога кылыгыз. Белеп торыгыз, Ул чиктән чыгучыларны, әлбәттә, сөйми. Җир йөзен тәртипкә салганнан соң, ул тәртипне бозмагыз. Газабыннан**

**куркып, рәхмәтен өмет итеп Аллаһка гыйбадәт кылыгыз. Хактыр ки, игелек кылганнарга Аллаһның рәхмәте бик якын".**

*(Әл-Әгъраф, 7/55-56).*

8. Ислам тәрбиясе дәресләрен укучыларның тормышларындагы һәм җәмгыятьтәге хәлләр белән бәйләү. Укучы канәгать булуы һәм гамәлдә тотуы өчен, шәригать хөкемнәрен һәм нигезләрен тормыштагы мисаллар белән ачыклау.
9. Дини эшчәнлекне дәрестә яисә мәктәптә генә түгел, ә сыйныфтан тыш эшләрдә дә җәелдерергә тырышу. Шул юнәлештә төрле чаралар үткәрү.
10. Укучыларның дини мөнәсәбәтләргә бәйле вакыйгаларны сәхнәләштерүе (әгәр шуңа теләкләре булса).
11. Укучыларга дини мәкаләләр язу өчен мөмкинлек бирү һәм кардәшләре каршында чыгыш ясарга шартлар тудыру.

## 2.5 Уку планы

Уку планы мәктәптә (мәдрәсәдә яисә мәчет каршындагы якшәмбе мәктәбендә) һәрбер класста (төркемдә) уку фәннәренең санын билгели. Предметларны өйрәнү эзлеклелеге укучыларның танып белү мөмкинлегеннән чыгып билгеләнә.

Уку планы мәктәптә (мәдрәсәдә яисә мәчет каршындагы якшәмбе мәктәбендә) өйрәнелә торган һәрбер уку предметының гомуми сәгатьләре (дәресләре) санын билгели. Шулай ук һәр уку предметының атналык сәгатьләр санын һәм атналык сәгатьләренең гомуми санын билгели[10].

[10] Карагыз: Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Дидактика: Югары һәм махсус урта уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2002. 55 бит.

## Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр:

1. Программа сүзенең аңлатмаларын китерегез.

2. Ислам тәрбиясе программасының нинди максатлары бар? Шуларны китерегез.

3. Ислам тәрбиясе программасының максатларында нинди нигезләр билгеләнгән булырга тиеш? Аларны әйтеп чыгыгыз.

4. Ислам тәрбиясе программасының игътикадка һәм белемгә керә торган нигезләрен санап чыгыгыз.

5. Программа тәкъдим итә торган укыту методлары нинди ул? Шуларны аңлатмалары белән китерегез.

6. Уку планы нәрсәләрне билгели? Шуларны әйтеп бирегез.

# Кушымталар

*Уку планнарының үрнәкләре*

***“Госмания” мөселман урта мәктәбенең 2004/2005 уку елына уку планы***

| Уку предметлары | Атнага сәгатьләрнең саны | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Башлангыч | | | | Төп | | | | | Урта | |
| | **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **6** | **7** | **8** | **9** | **10** | **11** |
| Татар теле | 3 | 4 | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | 2 | 1 | 1 |
| Татар әдәбияты | 2 | 2 | 2 | 2 | 3 | 2 | 2 | 2 | 2 | 3 | 3 |
| Рус теле | 3 | 4 | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | 2 | 1 | 1 |
| Рус әдәбияты | 3 | - 2 | 2 | 2 | 3 | 2 | 2 | 2 | 2 | 3 | 3 |
| Гарәп теле | - | 2 | 3 | 4 | 4 | 5 | 4 | 4 | 4 | 4 | 5 |
| Инглиз теле | - | - | - | - | - | - | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Математика | 4 | 4 | 4 | 4 | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | 4 | 5 |
| Гомум тарих һәм Рәсәй тарихы | - | - | - | - | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Татарстан тарихы | - | - | - | - | - | - | - | - | 1 | 1 | 1 |
| Җәмгыять белеме | - | - | - | - | - | - | - | 1 | 1 | 1 | 2 |
| Рәсәй һәм Татарстан географиясе | - | - | - | - | - | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | - |
| Табигать белеме | 1 | 1 | 2 | 2 | - | - | - | - | - | - | - |
| Биология | - | - | - | - | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 1 |
| Физика | - | - | - | - | - | - | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Химия | - | - | - | - | - | - | - | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Музыка | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | - | - | - | - |
| Рәсем | | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | - | - | - | - |
| Рәсем һәм сәнгатьле хезмәт | 1 | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| Физкультура | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | - | - | 2 | 2 | 2 |
| Тормыш иминлеге нигезләре (ТИН) | - | 1 | 1 | 1 | - | 1 | - | - | 1 | 1 | 1 |
| ТИН һәм физкультура берләшкән курс | - | - | - | - | - | - | 2 | 2 | - | - | - |
| Хезмәт | - | 1 | 1 | 1 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 |
| ***Ислам нигезләре*** | - | 1 | 1 | 1 | - | - | - | - | - | - | - |
| ***Фикһ*** | - | - | - | - | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 |
| ***Гакыйдә*** | - | - | - | - | - | - | - | - | - | 1 | 1 |
| ***Тәфсир*** | - | - | - | - | - | - | - | - | - | 1 | 1 |
| ***Хәдис*** | - | - | - | - | - | - | - | - | - | 1 | 1 |
| 5 көнлек укыту атнасы буенча максималь укыту нагрузкасының күләме | 20 | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| Укучы компоненты: Гарәп теле | 1 | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| Укучы компоненты: ***Ислам нигезләре*** | 1 | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| Уку планының гомум күләме (6 көнлек укыту атнасы) | **22** | **26** | **26** | **27** | **32** | **34** | **35** | **36** | **36** | **38** | **38** |

Уку планына ачыклау язуыннан:

1. 2-4 сыйныфларда сәламәтлек сәгатьләре кертелмәгән, чөнки мәктәпнең үзенчәлеге һәм тәртибе буенча бу дәресләр укучыларның һәр көн 20-минутлык намаз уку белән тулыландырыла.

2. Уку планына Ислам динен тирәнтен өйрәнү өчен түбәндәге предметлар кертелгән: Ислам дине нигезләре (1-4 сыйныфлар), фикһ (Ислам хокукының нигезләре – 5-11 сыйныфлар), гакыйдә (Ислам дөнья карашы – 10-11 сыйныфлар), тәфсир (Коръәннең аңлатмалары – 10-11 сыйныфлар), хәдис (Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. нең сүзләре – 10-11 сыйныфлар). Бу предметлар көннең икенче яртысына күчерелгән.

3. 5-11 сыйныфларда сәламәтлек сәгатьләре кертелмәгән, чөнки мәктәпнең үзенчәлеге һәм тәртибе буенча бу дәресләр укучыларның һәр көн 20-минутлык намаз уку белән тулыландырыла.

4. 6-9 сыйныфларда тормыш иминлеге нигезләре, тиешле бүлекләрен үзенә алучы, физкультура һәм фикһ белән берләштерелеп укытыла.

***Мәчетләр каршындагы берьеллык курслар өчен уку планы***[11]

Елына 28 атна, атнасына 6 сәгать исәбеннән

| Укыту маддәләре | Еллык сәгатьләр саны | Барлыгы |
|---|---|---|
| 1. Гакыйдә. | 36 | 36 |
| 2. Гарәп әлифбасы. Коръән уку кагыйдәләре (тәҗвид). | 38 | 38 |
| 3. Фикһ. | 36 | 36 |

[11] Мәчетләр каршындагы берьеллык курслар өчен укыту программасы. Төзүчесе: Вәлиулла хәзрәт Якупов. – Казан: ТҖМДН нәшрияты, 2011. 8, 19-20 битләр.

| | | |
|---|---|---|
| 4. Коръән. Коръән аятьләрен, зикерләрне, догаларны уку һәм ятлау (хифз). | 26 | 26 |
| 5. Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. нең сөннәте. Сира (Мөхәммәд с.г.в.с. нең тормыш юлы турында кыскача төп мәгълүматлар). | 10 | 10 |
| 6. Әдәп-әхлак. | 22 | 22 |
| Барлыгы | 168 | 168 |

1. Дәресләр атнага 1 яки 2 көн укытылалар. Атнага 2 көн булса, 1 көнгә 3 сәг. дәрес вакыты бүлеп бирелә. Дәресләрне үтү вакытларын, укучыларның буш яки уңайлы вакытларына карап билгеләргә.

2. Балалар белән олыларны аерым төркемнәргә бүлергә, чөнки балалар белән олылар белемне төрлечә үзләштерәләр. Темаларны үтү вакытларын, укучыларның материалны үзләштерү сәләтенә карап бүлгәләргә кирәк.

# 3. УКЫТУ МЕТОДЛАРЫ

3.1 Укыту методларының аңлатмасы
3.2 Укыту методларына таләпләр
3.3 Укыту методын сайлап алуда кайбер практик киңәшләр

## 3.1 Укыту методларының аңлатмасы

Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә кешеләрне яралтып бу дөньяга китерде һәм аларны туры юлга (һидаять юлына) күндерү өчен пәйгамбәрләр җибәреп, шәригать иңдерде. Кешене Ислам тәрбиясенә ирештерү һәм Аллаһы Тәгалә тарафыннан булган тәртипләргә күндерү өчен методларны сайлауда иреклe кылды. Ислам тәрбиясе үз эченә кешенең бөтен якларын ала: акылын, рухын, нәфесен (тойгы-хаҗәтләрен), хисләрен һәм җисемен.

Укыту методлары тәгълими һәм гамәли төргә бүленәләр.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

إِنَّ السَّمْعَ وَالْبَصَرَ وَالْفُؤَادَ كُلُّ أُوْلَئِكَ كَانَ عَنْهُ مَسْئُولاً

**“Аллаһ биргән колак, күз, күңел – боларның һәрберсеннән Кыямәт көнне сорау булыр, аларны саваплы урыннарга гына кулланыгыз!”** *(Әл-Исра, 17/36).*

Мәгълүм булганча, кеше ишетү һәм күрү, фикерләү һәм тәҗрибә, әңгәмә һәм язу аша, үзендә булган сәләтләре, хисләре, элек алган мәгълүматларын эшләтү белән өйрәнә. Кешенең акылы биш хис органы (күз, колак, ис сизү, тәм тату, кул белән тою) ярдәмендә тышкы галәмгә, тәрәзәләр аша караган кебек, карый.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

لَقَدْ كَانَ لَكُمْ فِي رَسُولِ اللَّهِ أُسْوَةٌ حَسَنَةٌ لِمَنْ كَانَ يَرْجُو اللَّهَ وَالْيَوْمَ الآخِرَ وَذَكَرَ اللَّهَ كَثِيرًا

**“Тәхкыйк, Аллаһның рәсүлендә сезгә иярергә тиешле булган күркәм холык вә яхшы сыйфатлар бардыр, Аллаһтан савапны һәм Ахирәттә Җәннәтне өмет иткән хәлдә Аллаһны күп зекер итүче мөэминнәр өчен”.** *(Әл-Әхзәб, 33/21).*

Метод төшенчәсе – куелган максатларга ирешү юлы – дигән мәгънәгә ия. Укыту методлары укыту-тәрбия максатларына ирешүдә укытучы һәм укучының бергәләп эшләү рәвеше буларак аңлатыла.

Әнвәр Нуриәхмәт улы Хуҗиәхмәтов яза: “Укыту методлары – укытучыларның укыту процессында укучыларны тәрбияләү юллары, аларга белемнәрне бирү, ул белемнәрне тикшерү һәм ныгыту юллары, укучыларның акыл көчләрен һәм сәләтләрен үстереп, аларда мөстәкыйль эшли белүне барлыкка китерү юллары, шулай ук укучыларның укытучы җитәкчелегендә белемнәрне һәм күнекмәләрне үзләштерү юллары. Укучыларга яңа белемнәрне бирү һәм аларның яңа белемнәрне алу максатларына түбәндәгеләр хезмәт итәләр: укытучының сөйләве, әңгәмә, дәреслекне һәм башка китапларны уку, өйрәнелә торганны төрле төрдә күзәтүләр”[12].

Һәрбер укыту методы үз эченә укытучының өйрәтү эшчәнлеген (материалны аңлату, сөйләү, әңгәмә һ.б.) һәм укучының уку, танып белү эшчәнлеген оештыруны ала.

Уку-укыту эше ике яклап бара: укытучы укыта, укучы укый. Монда укытучы роле бик әһәмиятле. Ул – укучылар өчен иң беренче һәм төп белем чыганагы да, уку-укыту эшенең оештыручысы да. Укытучының максаты – укучыны укыту, аңа белем бирү, тәрбияләү, аның акылын, хисен үстерү, рухи яктан бай, эзләнүчән шәхес формалаштыру. Укучылар исә укытучының биремнәрен, күнегүләрен үтәргә тиеш. Бу эштә укыту методының роле зур.

“Белемнәрне үзләштерүдә аеруча аңлылыкка, аларның

[12] Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Дидактика: Югары һәм махсус урта уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2002. 61 бит.

аеруча ныклыгына ирешү һәм аларны системага китерү максатларында кабатлау һәм тикшерү төп чара булып тора. Кабатлау төрле формада һәм күләмдә кулланыла. Укучыларның белемен тикшерү өчен төрлечә сорау формалары кулланыла һәм төрле контроль эшләр үткәрелә"[13].

## 3.2 Укыту методларына таләпләр[14]

Укыту методлары психологик нигезгә ия. Баланың характер һәм яшь үзенчәлекләре укыту һәм белем бирү алымнарына хәлиткеч йогынты ясый. Укучыларның фикер эшчәнлеген тирәнтен аңлау, шәхес үзенчәлекләрен белү укытуның камилрәк алымнарын табарга ярдәм итә.

Укыту методларына куела торган түбәндәге таләпләрне санап китәргә була:

1. Укытуның укытучы тәкъдим иткән юлы тәрбияви характерда булырга, ягъни белемнәрне үзләштерүдә генә түгел, укытуның тәрбияви мөмкинлекләрен тормышка ашырырга тиеш.
2. Укыту методлары фәнни нигезләнгән булырга тиеш. Шул чакта укытучы укытуның бу методы аркылы нинди бурычлар куярга һәм чишәргә мөмкин икәнлеген күрә ала.
3. Укыту методларының системалыгы аларның камиллеген билгели.
4. Укыту методларының аңлаешлы булуы да әһәмиятле шарт булып тора. Белем бирү юлы укучы өчен аңлаешлы булырга, ә инде уку материалын үзләштерү алымнары яшь үзенчәлекләренә туры килергә тиеш. Белемнәрне үзләштерү методы бер үк вакытта авыр да, җиңел дә булырга мөмкин.
5. Күргәзмә әсбаплар куллану да – укыту методларына куелган таләпләрнең берсе.

---

[13] Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Дидактика: Югары һәм махсус урта уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2002. 61 бит.
[14] Шунда ук. 62-64 битләр.

6. Белемнәр нигезләнгән һәм тотрыклы булырга тиеш. Шулай ук укыту методының нәтиҗәлелеге турында да әйтеп үтәргә кирәк. Укытучының аңлатуы һәм укучыларның белемнәрне үзләштерүе планлаштырылган яки теләгән нәтиҗәне бирергә тиеш.

7. Укучыларның танып белү эшчәнлеген индивидуальләштерү таләбе дә куела. Укучыларның индивидуаль яки гомуми үзенчәлекләре белемнәрне үзләштерү методларын сайларга һәм нигезләргә мөмкинлек бирә.

## 3.3 Укыту методын сайлап алуда кайбер практик киңәшләр[15]

Методларны сайлау, барыннан да элек, тәрбия максатлары белән билгеләнә.

Укыту методлары укучыларның мөстәкыйльлекләрен үстерүгә һәм белемнәрне практикада куллана белүгә юнәлергә тиеш.

Методлар һәм методик алымнар сайлау программаның өйрәнелә торган якындагы бүлегенең эчтәлеге белән билгеләнә.

Кайбер темаларны өйрәнгәндә нигез итеп экскурсияне алу файдалы була[16].

Белемнәрнең сыйфаты методны дөрес сайлауга бәйле.

Программаның һәрбер бирелгән өлешен өйрәнүдә төп роль бирелгән куелган максатка һәм программаның шул өлешенең эчтәлегенә күбрәк җавап бирә торган конкрет методка төшә. Шул очрак өчен сайланган төп эш ысулына башка методына башка методлар да кушылалар, тик аларны белемнәрнең эчтәлегенә ачыклык бирү өчен һәм аларны җитәрлек кадәр нык итеп үзләштерүдә балаларга

---

[15] Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Дидактика: Югары һәм махсус урта уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2002. 64-66 битләр.

[16] Мәсәлән, мәчет әдәбе белән танышу дәресендә мәчетне зиярат итүне оештыру.

ярдәм итәр өчен файдалы һәм уңайлы чагыштырмалар да алырга кирәк.

Аерым методларның һәм методик алымнарның бер-бер артлы килүләре турындагы мәсъәләне хәл иткәндә, эшнең шул бирелгән кисәгендә укытуның барышы турында уйларга кирәк һәм яңа белемнәрне бирүдә, белем һәм күнекмәләрне нык беркетүдә нинди методлар кулланырга кирәклеген, шул ук максат белән нинди күнегүләр эшләргә кирәклеген, үткәнне ничек кабатларга, балалардагы белемнәрнең күләмен һәм сыйфатын, шулай ук күнекмәләрне тикшерүне ничек уздыру кирәклеген хәл итәргә кирәк. Шулай ук бу очракта укучыларның эш белән кызыксынуларын ничек итеп яхшырак кузгату, иң әһәмиятлене ныграк хәтердә калдыру, фикерләү активлыгының үсеше өчен уңайлы җирлек тудыру; балаларда эмоциональ кичерешләр уяту турында да уйларга кирәк.

Укыту методлары белемнәрне бирүдә һәм үзләштерүдә системалыкны һәм эзлеклелекне тәэмин итәргә тиешләр. Мәсәлән, балаларны конкрет материал белән таныштырмый торып, гомумиләштерүләрне бирергә ярамый. Укучыларны хәзерләми торып, мөстәкыйль эш бирергә ярамый.

Методларны сайлаганда укучыларның яшь аерымлыкларын исәпкә алырга кирәк. Мәсәлән, башлангыч мәктәп укучылары өчен лекция методы урынлы түгел, чөнки әле аларның фикерләве һәм игътибары укытучының озакка сузылган һәм диалог белән бүленмәгән сөйләвен сиземләрлек дәрәҗәдә үсмәгән. Бу яшьтәге укучылар өчен катлаулы күзәтүләр, тәҗрибәләр, шулай ук китап буенча үзлегеннән эшләү өчен катлаулы биремнәр дә авыррак бирелә. Башлангыч мәктәптә күрсәтмәлелекне киң кулланырга мөмкинлек бирүче методларга аерата зур урын бирелергә тиеш.

Программаның бөтен бер темасы яки бүлеге өчен эшләү методын сайлаганнан соң, укытучы барлык эшне аерым

дәресләргә бүлә һәм аннан соң инде аерым дәресләрнең һәр өлеше өчен конкрет эш төрләрен билгели.

**Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр:**

1. Метод төшенчәсе нинди мәгънәгә ия?
2. Укыту методларына нинди аңлатма бирелә? Шуны китерегез.
3. Һәрбер укыту методы үз эченә нәрсәне ала?
4. Укыту методларына нинди таләпләр куела? Аларны санап чыгыгыз.
5. Укыту методын сайлап алуда кайбер практик киңәшләрне китерегез.

# ИКЕНЧЕ БҮЛЕК: ДИНИ ДӘРЕСЛӘРНЕ ҺӘМ БӘЙРӘМНӘРНЕ УЗДЫРУ МЕТОДЛАРЫ

## 1. КОРЪӘН КӘРИМ ДӘРЕСЛӘРЕ

1.1 Коръән Кәримнең мөселманнар тормышындагы әһәмияте
1.2 Коръән Кәрим белән эш итү рәвеше
1.3 Коръән Кәримне уку (кыйраәт) дәресе
1.4 Коръән Кәримне ятлау (хифз) дәресе
1.5 Тәҗвид дәресе
1.6 Тәфсир дәресе

Коръән Кәрим – Ислам диненең мәңге булучы, бетмәс могҗизасы. Аллаһы Тәгалә аны Үзенең Рәсүле Мөхәммәд с.г.в.с. гә, кешеләрне карангылыктан яктылыкка чыгару өчен, иңдергән. Коръән Кәрим – Аллаһы Тәгаләнең Кәләме (Сүзе) ул.

Коръән Кәрим гарәп телендәге китап һәм аны Рәсүлебез Мөхәммәд с.г.в.с. гә 23 ел дәвамында Аллаһы Тәгалә Җәбраил г.с. фәрештә аркылы иңдерде һәм ул Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең могҗизасы булып, ул аны бөтен кешеләргә алып килде.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

قُلْ نَزَّلَهُ رُوحُ الْقُدُسِ مِنْ رَبِّكَ بِالْحَقِّ لِيُثَبِّتَ الَّذِينَ آمَنُوا وَهُدًى وَبُشْرَى لِلْمُسْلِمِينَ

**«Әйт (Әй, Мөхәммәд с.г.в.с.): «Аны (Коръәнне) Изге Рух (Җәбраил г.с.) Раббың хозурыннан хаклык белән иңдерде. Иман китерүчеләрне нык торсыннар өчен (иманнарында) һәм мөселманнарга һидаять (туры юл) вә шатлыклы хәбәр булсын өчен».** *(Ән-Нәхел, 16/102).*

Коръән Кәрим Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелгән ахыргы Китап булу сәбәпле, Аллаһы Тәгалә аңа, үзенә генә хас, кайбер аермалыклар бирде:

а) Коръән Кәрим Иләһи күрсәтмәләрнең бөтенесен үз эченә алды һәм үзеннән әүвәлге Китапларның бөтенесендә килгән Аллаһны берләү һәм Аңа гына гыйбадәт һәм итагать итүне тәсдыйклап килде һәм башка Китапларда килгән яхшы гамәлләрне һәм өстенлекләрнең барысын үзенә җыйды:

وَأَنزَلْنَا إِلَيْكَ الْكِتَابَ بِالْحَقِّ مُصَدِّقًا لِمَا بَيْنَ يَدَيْهِ مِنْ الْكِتَابِ وَمُهَيْمِنًا عَلَيْهِ

**«Һәм сиңа (Әй, Мөхәммәд с.г.в.с.) хаклык белән булган Китапны (Коръәнне) индердек әүвәлге Китапның хөкемнәрен тәсдыйклаган хәлдә һәм аның дөреслегенә шәһадәт биргән хәлдә».** *(Әл-Маидә, 5/48).*

б) Коръән Кәрим – кешеләргә дәлил булып калу өчен, аны кешеләрнең үзгәртүеннән Кыямәт көненә хәтле Аллаһы Тәгалә сакларга вәгъдә бирелгән ялгыз бер Китап:

إِنَّا نَحْنُ نَزَّلْنَا الذِّكْرَ وَإِنَّا لَهُ لَحَافِظُونَ

**«Тәхкыйк, Без Зикерне (Коръәнне) иңдердек һәм тәхкыйк, аны, әлбәттә, саклыйбыз».** *(Әл-Хиҗер, 15/9).*

в) Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримне барлык кешеләргә дә ике дөньяда да бәхетле булырга сәбәп булучы шәригать итеп иңдерде (әүвәлге Китаплар кебек мәгълүм халыкка хас итеп түгел). Коръән Кәрим әүвәлге халыкларга хас бул-

ган шәригатьләрнең бөтенесен мәнсух итте (гамәлдән чыгарды) һәм Коръәндә һәр заманга һәм һәр урынга яраклы булган мәңге һәм ахыргы хөкемнәр килде.

## 1.1 Коръән Кәримнең мөселманнар тормышындагы әһәмияте

Коръән Кәрим Ислам шәригатенең бөтен нигезләрен үз эченә ала. Коръән Кәрим "Укы! Һәрнәрсәне яралтучы Раббың исеме белән!" (Әл-Гәләк, 96/1) дигән Аллаһы Тәгаләнең боерыгы белән иңдерелә башлаган. Һира тау куышында Пәйгамбәребез с.г.в.с. гә иңдерелгән әлеге беренче изге аять-күрсәтмә, өммәтнең белем дөньясына таба юл алуына иң зур сәбәп-этәргеч булган. Һәм бу үз алдыңа аерым-үзенчәлекле максат куеп уку; бик зур игътибар белән, тирәнтен уйлап, тормышка-көнкүрешкә үз карашыңның нинди булуын тикшереп карау гамәле. Шулай итеп бу әмерне "Укы!" гына дип түгел, ә "Аңларга тырыш!" дип тә кабул итәргә; үзеңә, әйләнә-тирәңә, дөньяга күңел күзе белән карарга тырышырга бурычлыбыз.

Аллаһы Тәгалә "Фатиха" ("Әлхәм") сүрәсендә әйтә:

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ الْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ مَالِكِ يَوْمِ الدِّينِ إِيَّاكَ نَعْبُدُ وَإِيَّاكَ نَسْتَعِينُ اهْدِنَا الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ صِرَاطَ الَّذِينَ أَنْعَمْتَ عَلَيْهِمْ غَيْرِ الْمَغْضُوبِ عَلَيْهِمْ وَلَا الضَّالِّينَ

**"Рәхимле, Шәфкатьле Аллаһ исеме белән башлыйм. Чын мактау галәмнәрне, бөтен мәхлукларны тәрбияләүче Аллаһы Тәгаләгә тиешле. Аллаһы Тәгалә бу дөньяда барча кешеләргә мәрхәмәтле, ягъни мөэминнәргә дә, көферләргә дә нигъмәтләрен бирә, әмма Ахирәттә мөэмин бәндәләренә генә бирәчәк. Аллаһы Тәгалә, гаделлек белән хөкем итүче, Ахирәт көненең Патшасы. Ий тәрбиячебез, Аллаһ! Без Сиңа гына**

**гыйбадәт кылабыз һәм һәр эшебездә Синнән генә ярдәм сорыйбыз. Ий тәрбиячебез, Аллаһ! Безләрне туры юлга күндер! Ул юлны Син әүвәлгеләргә нигъмәт итеп бирдең, безләрне Синең ачуың төшкән һәм хак юлдан адашкан кешеләрнең юлыннан кылма!" "Амин."**

"Фатиха" сүрәсе шушы максатларны әйтеп чыкты һәм ул дога шәкелендә килеп, шушы сүрәне укучы белән Раббысы Аллаһы Тәгалә арасында башкарыла. Шуннан чыгып без Коръән Кәримнең иң әһәмиятле максатларын әйтә алабыз:

1. Яшәвебез һәм гамәлләрне башкаруыбыз Аллаһы Тәгаләнең Патшалыгы белән генә була. Ул барчабызны бар кылган, бөтен нәрсәләрне безгә буйсындырган. Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән нигъмәтләре өчен сүз белән дә, гамәл белән дә шөкер итүебез, бар иткән нәрсәләренә карап изгеләштерүебез һәм мактавыбыз тиеш.

2. Аллаһы Тәгаләнең газабыннан курку һәм Кыямәт көнендә Аның рәхмәтен өмет итү.

3. Кешенең Аллаһыга гына гыйбәдәт кылуы, җәмгыять гаделлек һәм тигезлеккә нигезләнүе, Аллаһы Тәгалә галәмдәге көчләрне буйсындырганы өчен Аңа шөкер итү.

4. Гыйбадәт итүдә, тормышта, кешеләр белән мөгамәлә итүдә Коръән һәм сөннәткә иярү, Аллаһы Тәгалә күрсәткән туры юлдан тайпылмау.

5. Пәйгамбәрләрдән, салих кешеләрдән яхшы үрнәкләр алу.

6. Элек яшәгән халыкларның тарихыннан гыйбрәт алу, Коръән Кәримдә зекер ителгән начар сыйфатларыннан ераклашу, күркәм якларыннан үрнәк алу.

## 1.2 Коръән Кәрим белән эш итү рәвеше

1. Коръән Кәримне укыганда, тыңлаганда, ятлаганда һәм өйрәнгәндә тиешле әдәпләрне сакларга, Аллаһның изге Китабына хөрмәт белән карарга.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

اللَّهُ نَزَّلَ أَحْسَنَ الْحَدِيثِ كِتَابًا مُّتَشَابِهًا مَّثَانِيَ تَقْشَعِرُّ مِنْهُ جُلُودُ الَّذِينَ يَخْشَوْنَ رَبَّهُمْ ثُمَّ تَلِينُ جُلُودُهُمْ وَقُلُوبُهُمْ إِلَى ذِكْرِ اللَّهِ ذَلِكَ هُدَى اللَّهِ يَهْدِي بِهِ مَنْ يَشَاءُ وَ مَن يُضْلِلِ اللَّهُ فَمَا لَهُ مِنْ هَادٍ

**“Сүзләрнең иң татлыларын (аятьләрне) бер-берсенә аваздаш итеп, Аллаһ бер Китап итеп туплады һәм (бүлеп-бүлеп) иңдерде. (Коръәнне укыганда) Раббыга тирән мәхәббәт тәрбия иткән кешеләрнең тәннәре чымырдап китәр, шуннан соң аларның тәннәре дә, күңелләре дә (миһербан тулып) Аллаһка юнәлер. Менә шушы Китап Аллаһ күндергән җитәкчедер. Ул (шушы Коръән белән) теләгән кешесен тугры юлга күндерер. Аллаһ юлдан яздырган кешене беркем дә тугры юлга алып чыга алмас”.** *(Әз-Зумәр, 39/23).*

2. Коръән аятьләренең мәгънәләрен аңларга тырышу һәм алар белән тәэсирләнү.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

أَفَلَا يَتَدَبَّرُونَ الْقُرْآنَ أَمْ عَلَى قُلُوبٍ أَقْفَالُهَا

**“Алар Коръәнне аңламыйлармы? Әллә аларның күңеленә йозак салынганмы?”** *(Мөхәммәд, 47/24).*

3. Коръән Кәрим белән эш иткәннең тәне госелле-тәһарәтле, киеме һәм урыны пакь булуы.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

لَا يَمَسُّهُ إِلَّا الْمُطَهَّرُونَ

**“Ул Коръәнне пакь булмаган кеше тотмас, мәгәр тәһарәтле пакь кеше генә тотар”.** *(Әл-Вакыйгәһ, 56/79).*

4. Коръән Кәримне уку алдыннан “Әгүзү-билләһи-минәш-шайтанир-раҗим” дип әйтү.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

فَإِذَا قَرَأْتَ الْقُرْآنَ فَاسْتَعِذْ بِاللَّهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ

**“Ий мөэмин бәндәм, әгәр Коръән укырга теләсәң, башта “Әгүзү-билләһи-минәш-шайтанир-раҗим” дип әйт!”**

*(Ән-Нәхел, 16/98).*

5. Һәрбер сүрә алдыннан “Бисмилләһир-Рахмәнир-Рахим” дип әйтү (“Тәүбә” сүрәсеннән кала).

6. Коръән Кәримнең укуы тәҗвид кагыйдәләренә нигезләнеп дөрес башкарылуы, хәрефләрнең мәхраҗлары ачык һәм төгәл, уку тыныч һәм басынкы (тыйнак) булуы.

7. Уку тавышын яхшырту, чөнки күркәм тавыш йөрәкне тынычландыра, анда ныклы ышаныч тудыра һәм игътибарга чакыра.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَأَنصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ

**“Коръән укылганда ихлас тыңлагыз, сүз сөйләмичә, эш эшләмичә тик торыгыз! Шулай итсәгез, шаять, рәхмәт кылынырсыз”.** *(Әл-Әгъраф, 7/204).*

## 1.3 Коръән Кәримне уку (кыйраәт) дәресе

***1. Коръән Кәримне уку (кыйраәт) дәресенең максатлары***

1) Коръән Кәримне дөрес уку;

2) Аллаһы Тәгаләнең олугълыгын хис итү һәм Аның Китабын укуда басынкы (тыйнак) булу;

3) Коръән Кәримне уку әдәбен һәм аңа карата ихтирам күрсәтү;

4) шәкертләрне Коръән Кәримне даими укуга гадәтләндерү;

5) Коръән Кәримнең төрле тарафлардагы могҗизалары[17] белән хис иттерү;

6) калебнең басынкы (тыйнак) булуы һәм нәфеснең канәгать булуы.

Шул рәвешле Коръән Кәримне өйрәнү һәм уку – гыйбадәтләр, фикерләр һәм рух өчен азык икәнен белү кирәк. Коръән Кәрим - Аллаһы Тәгалә тарафыннан булган туры юл, гадәтләрне һәм холыкларны яхшырту юлы, дөньяда һәм Ахирәттә бәхет чыганагы.

***2. Укытуның методлары***

I. Башлангыч (1 – 4) сыйныфларда Коръән Кәримне укыту методлары.

Бу сыйныфларда укучыларның гарәп хәрефләре белән Коръән Кәримне әле әйбәт укый алмауларын күз алдында тотып, укытучыга түбәндәге эшләргә нигезләнү тиеш була:

1) Тыңлату;

2) охшатып (ияреп) укыту;

3) кабатлату.

Шуларны күздә тотып укытучы дәрестә түбәндәгеләрне үти:

а) укучыларны дәрескә әзерли, игътибарларын шуңа юнәлтә;

ә) укытучы сүрәне яисә аятьне, ашыкмыйча, һәр хәрефне ачык рәвештә әйтеп, тыныч кына дөрес итеп укый;

б) бергәләп уку: укучылар сүрәне яисә аятьләрне укытучы артыннан бергәләп укыйлар;

в) аерым уку: укытучы бер аятьне укып, укучыларның һәрберсеннән шул аятьне дөрес укуны таләп итә (шул рәвешчә дәрестә укып чыгарга тиешле булган сүрә яки аятьләрне укып бетергәнче);

г) укытучы укучыларның сүрәләрне яисә аятьләрне ятлауга этәрә һәм яттан сөйләгәнне тыңлый;

[17] Ягъни гыйбарәләренең оста телле булуында һәм аларның сөйләү рәвешендә, аңлатуында һәм тәртибендә, булган гыйлем һәм белемнәрендә, кануннар чыгаруында.

д) бәяләү: дәрес ахырында укытучы белән укучылар дәрестә үткән сүрә яисә аятьләрне укып чыгалар; укытучы дәрестә үткәнне укучылар тарафыннан үзләштерүләрен тикшерә һәм өй эше бирә.

II. Башка сыйныфларда Коръән Кәримне укыту ысуллары.

Бу сыйныфларда укучылар гарәп хәрефләре белән Коръән Кәримне укый белгәнгә, укытучы дәреснең күбрәк өлешен укучыларның Коръәнне дөрес итеп укуларына һәм тиешле әдәпләрне саклауга игътибарын юнәлтергә тиеш. Аятьләрнең мәгънәләрен аңлатуга вакытны күп сарыф итү белән шөгыльләнмәскә кирәк.

Укытучы укыту дәресләрендә түбәндәгеләрне үти:

1. Әзерлек: укучыларның Коръән Кәримне өйрәнүләре өчен яхшы мөхит булдыра. Аның методлары: 1) Коръән Кәрим аятьләренең иңү сәбәпләрен сөйләү; 2) укучыларның күңелләренә хуш килгән кыйссалар зекер итү; 3) Коръән Кәрим аятьләрендә булган шәригать хөкемнәре хакында фикер алышу; 4) тормыштагы вакыйгаларны яисә кешеләр арасында булган гадәтләрне мисал итеп китерү.

2. Укытучы сүрәне яисә аятьләрне ашыкмыйча, һәр хәрефне ачык рәвештә әйтеп, тыныч рәвештә үрнәк булып укый.

3. Укучылар укытучы артыннан бергәләп укыйлар.

4. Укучыларга Коръән Кәримне үзләре генә күңелдән яки пышылдап укырга форсат бирә, бу кыска вакыт эчендә була.

5. Укучыларның һәрберсе тарафыннан укыла торган аятьне дөрес укулары. Шул рәвешчә дәрестә укып чыгарга тиешле булган сүрә яки аятьләрне укып бетергәнче дәвам итә.

6. Бәяләү: укылган сүрә һәм аятьләрдә булган иң мөһим урыннарын ачыклау, дәрестә укыган сүрә яисә аятьләрне укып чыгу; өй эшен бирү.

3. Укудагы хаталарны төзәтү методлары

Укучы Коръән Кәримне хата белән укыса, укытучы түбәндәге методларны үти:

- укучыдан хаталарын үзе табып, үзенә төзәтүне сорый (укучы моны булдырса, бу иң яхшысы);
- әгәр булдырмаса, укытучы укучылардан аның хаталарын төзәтүне сорый;
- әгәр булдырмасалар, укытучы үзе төзәтә;
- укытучы укучының хаталы укый торган сүзен яисә аятьне тактага язып, хаталы урыннарын төсле акбур (маркер) белән билгели;
- укытучы укучының хаталану сәбәпләрен тикшерә;
- хаталарын аңлаганы соңында укучыдан укытучы хата белән укыган урынын дөрес итеп укуын сорый.

## 1.4 Коръән Кәримне ятлау (хифз) дәресе

Коръән Кәримне ятлау олуг фазыйләтләрдән (өстенлекләрдән) санала. Аллаһы Тәгалә мөселманнарга Коръән Кәримне ятлауны җиңел кылды, нинди телләрдә сөйләшүләренә карамастан, укыган вакытта хакны кабул итүләре өчен.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَلَقَدْ يَسَّرْنَا الْقُرْآنَ لِلذِّكْرِ

**“Тәхкыйк Коръәнне укырга җиңел вә мәгънәсен аңнарга ачык кылдык”.** *(Әл-Камәр, 54/17).*

Коръән Кәрим, язып алынган битләрдә генә түгел, ә күкрәкләрдә ятланган килеш тә саклана. Бу, Китап әһелләренә (нәсара һәм яһүди динендә булучыларга) капма-каршы булып тора, чөнки алар үз китапларын язылган килеш кенә саклыйлар. Шул сәбәпле алар үз китапларын карап кына укый алалар. Һичбер китап, Коръән китабы

шикелле, җиңел ятланмый. Бу Аллаһы Тәгалә тарафыннан Коръәнгә генә бирелгән аермалык.

Сира һәм хәдис китапларында килгәнчә, сәхабәләр Коръәнне ятлауда бер-берсе белән ярышканнар. Коръәнне хатыннары һәм балалары да ятлый торган булган, төнге намазларында укыганнар, хәтта йортларыннан умарта кортлары тавышлары шикелле гөҗләү ишетелгән. Пәйгамбәребез с.г.в.с. сәхабәләрнең йортлары яныннан үткәндә аларның өйләреннән Коръән укыган тавышларын ишетеп, тыңлап тора торган булган.

Пәйгамбәребез с.г.в.с. әйтте: «Көнчелек кылу ике очракта гына рөхсәт ителә: Коръәнне яттан өйрәнеп, көнен-төнен укуга багышлаучы ир кешегә, Аллаһы Тәгалә биргән малны көнен-төнен дин юлына таратучы ир кешегә».

Коръән Кәримне ятлау һәрвакыт укып һәм кабатлап торган кешегә тагы да җиңелрәк була. Әгәр ул сирәк укыса, ятлаганын кабатламаса, укучыга ул авыр булып тоелачак һәм ятлаганы тиз онытылырга мөмкин, ә оныту гөнаһ санала. Ләкин оныту кабатлап тормаган өчен генә булмый, гәрчә кабатлап тору онытмау өчен иң яхшы метод булып торса да. Оныту ике төрле була: 1) Калебенең дөньяга нык бәйләнгәне сәбәпле Коръән Кәримне укуга һәм кабатлауга игътибарсызлык итүгә китерүе. Онытуның шушы төре тәнкыйть ителә. 2) Картаю, зиһеннең начаруы һ.б. сәбәпләр белән онытуы, ә аз укуы һәм кабатламавы сәбәпле түгел.

***Коръән Кәримне ятлау (хифз) дәресенең максатлары***

1) Коръән Кәримне ятлау Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен башкарылырга тиешлеген, Аллаһ каршында зур җаваплылык алуын аңлату;

2) Коръән ятлаучыда күркәм әхлакый сыйфатлар тәрбияләү;

3) Коръән Кәримнән аять һәм сүрәләр ятлаттыру.

***Ятлату методлары***

Укытучы Коръән Кәримне ятлаучыларга түбәндәге киңәшләр бирә:

- Коръәнне ятлауда ихласлык (эчкерсезлек) булу, ягъни Аллаһы Тәгаләгә якынаю, Аның ризалыгын алу максаты белән ятлау, ә кешеләр алдында мактану, шөһрәт-дан алу өчен түгел;

- гөнаһлардан һәм начар гамәлләрдән ерак булу, чөнки гөнаһ кылу ятлауга киртә булып тора һәм шайтанның вәсвәсәсе Аллаһы Тәгаләне зекер итүдән ераклаштыра;

- ятлау белән яшь вакытта мәшгүль булуы яхшырак, чөнки яшь вакытта вакыт ягыннан да, зиһен ягыннан да мөмкинчелекләр күбрәк була;

- Коръәнне ятлауга аерым вакыт бирү, бигрәк тә бу иртәнге намаздан соң булса яхшы;

- ятлау белән арыган, кайгылы, мәшәкатьле вакытта мәшгүль булу хупланмый (мондый вакытларда Коръәнне укып кына күңел тынычлыгы алса яхшырак), чөнки болар Коръәнне ятлауга киртә булып торалар;

- Коръән Кәримне ятлау өчен, эш белән шөгыльләнүчеләрдән, шаушулы урыннардан ераграк урын сайлау һәм моның өчен иң яхшысы мәчет булып санала;

- Коръәнне ятлауга үз теләге һәм омтылышы булуы, ә әти-әнинең, укытучыларның мәҗбүрләве түгел, чөнки мондый ятлау озакка сузылмаячак; үз теләге белән ятлаганы өчен савап күбрәк була һәм андый кешенең, Коръән-хафиз буларак, дәрәҗәсе аерым була; ятлаучыда үз омтылышын булдыру өчен аңа күркәм нәсыйхәтләр бирү;

- ятлаучылар арасында ярышу мохите булдыру;

- өйрәнелүче аять-сүрәдәге хәрефләренең мәхраҗларын дөрес һәм ачык итеп, тәҗвид кагыйдәләренә туры китереп, тиешле әдәпләрне саклап укуы;

- Коръән Кәримне бер төрле мосхафтан уку;

- Коръән Кәримне махсус төркемнәрдә ятлау яисә Коръәнхафизлардан яисә Коръәнне төгәл, хатасыз укучылардан алу;

- бишәр аять ятлау һәм аларны иң киме 100 тапкыр ка-

батлау; ятлау бер-берсе белән бәйле булырга тиеш, моның өчен бер аятьтән икенче аятькә әкрен генә күчеп барырга кирәк, мосхафның бите тәмамланганчы; соңыннан ятланган бит кабатлана һәм бу бит аннан соң килгән бит белән бәйләнә; шундый рәвештә сүрә ятлаганчы дәвам итә; ятлаган сүрәне әйбәтләп беркетмичә (ятламыйча) башка сүрәгә күчәргә тәкъдим ителми;

- Коръән Кәримне ятлау җиңелрәк булсын өчен Коръәннең мәгънәләрен аңларга тырышырга кирәк һәм моның өчен гарәп телен өйрәнү, тәфсирләр уку зур булышлык күрсәтәләр;
- ятлауны ике, өч кешелек яисә күбрәк кешелек төркемнәрдә өйрәнергә тырышу, чөнки үзе генә ятласа кылган хаталарын күрмәскә мөмкин, ә кардәшләре, укытучысы янында булса, алар аны төзәтергә мөмкин; шулай ук, башка укучыларны күреп ярышу хисе көчәя.

## 1.5 Тәҗвид дәресе

“Тәҗвид” сүзе «яхшырту, осталык белән максатка ирешү» дип тәрҗемә ителә. Тәҗвиднең шәригатьтәге мәгънәсе - һәр хәрефне үз мәхраҗыннан (чыга торган урыныннан) чыгару, һәм хакын (зарури сыйфатларын: хәрефнең үзгәрмәс сыйфатларын) һәм тиешлесен (өстәмә сыйфатларын: тәҗвид кагыйдәләрен) аңа бирү.

Тәҗвид фәне – шәригать фәне дип санала. Анда тупланган кагыйдәләрне, Коръән Кәримне уку рәвешләрен иң беренче Рәсүлебез Мөхәммәд с.г.в.с. нең авызыннан ишетелгәнчә сәхабәләр өйрәнгәннәр, сәхабәләрдән табигиннар өйрәнгәннәр, имамнар һ.б. Менә шул рәвешчә ул безнең көннәргә хәтле килеп җиткән.

Тәҗвид фәненең максаты – Коръән Кәримне укыганда аның сүзләрен хаталардан, бозулардан саклау, чөнки

Коръән Кәримне дөрес укыган кеше күп әҗер-саваплы була, ә хаталар белән укыган кеше гөнаһлы була.

***Тәҗвидне укыту максатлары***

1) Шәкертләрнең, программада каралган, тәҗвид кагыйдәләрен үзләштерүләре;

2) тәҗвид кагыйдәләрен гамәли яктан куллана алулары;

3) Коръән Кәримгә карата хөрмәт һәм тиешле әдәпләрне тәрбияләү.

***Тәҗвидне укыту бурычлары***

1) Тәҗвид фәненә хас терминология белән таныштыру, аларга аңлатмалар бирү.

2) Тәҗвид фәненең кереш белемнәрен, хәрефләрнең мәхраҗларын һәм тәҗвид кагыйдәләрен аңлату.

3) Коръән Кәримне укыганда үткән тәҗвид кагыйдәләрен таба алуга һәм аларны гамәлдә үтәүгә җиткерү.

4) Шәкертләрнең тәҗвид фәненең мөһимлеген аңлаулары.

5) Коръән Кәримне уку дәресләрендә Аллаһы Тәгаләнең Олугълыгын хис итү һәм Аның белән сөйләшүдә басынкы (тыйнак) булу.

6) Коръән Кәримне уку әдәбен һәм аңа карата ихтирам күрсәтүне сеңдерү.

***Тәҗвидне укыту методлары***

Шәкертләрне укыту тәгълими вә гамәли дәресләр, шәкертләрнең мөстәкыйль рәвештә башкарган гамәлләре аша башкарыла. Укыту процессында түбәндәге методларны куллану зарур:

1) Аңлату-күрсәтмәле метод – шәкертләргә яңа тема аңлаткан вакытта кулланыла. Лекция рәвешендә алып барыла.

2) Уку эшчәнлеген күзәтү һәм үз-үзеңә контрольлек итү методы – өйләренә күнегү һәм эшләр бирү, дәрестә сораулар бирү, контроль эшләр уздыру, имтихан үткәрү рәвешендә башкарыла. Шәкертнең үз-үзенә бәя бирүе, хаталарын күрүе һәм аларны төзәтүе өчен.

Укыту методлары: 1) Кагыйдәләрне аңлаешлы рәвештә аңлату. 2) Коръән Кәримнән мисаллар китерү; кирәк вакытта мисалларны шәкертләргә әйттерү. 3) Үткән кагыйдәләргә өй эшләре бирү. 4) Дәрес башында өй эшләрен тикшереп чыгу (төрле методлар белән). 5) Дәреснең башында алдагы дәрестә үткән кагыйдәләрне кабатлау; булган сорауларга җавап бирү.

“Тәҗвид кагыйдәләрен” уку процессында шәкертләргә, иң беренче, дәресләрне калдырмауга игътибар итү кирәк. Дәрес вакытында шәкертләргә, мөгаллим дәрестәге теманы аңлаткан вакытында, дәреснең барышын, кирәк булган өлешләрен һ.б. беркетеп бару, чөнки шәкертләргә дәрестәге теманы, таләп ителгән нәрсәләрне аңлап үтү кирәк. Дәрес барышында сораулар туса, шәкерт аларны үзенә билгеләп алып, соңыннан ул сорауларны, мөгаллим биргән аерым вакытта бирә ала.

Дәресләрдән соң, шул ук көнне яисә икенче көнне (озакка сузмыйча), дәрестә үткән теманы уку әсбабыннан укып чыгарга, биргән күнегүләрне эшләп чыгарга тырышырга кирәк. Сораулар туса яисә нәрсәдер аңлашылмаса, җавабын башта үзенә табарга тырышырга кирәк. Моның өчен тәкъдим ителгән төп әдәбиятны да, өстәмә әдәбиятны да кулланырга мөмкин. Бу да ярдәм итмәсә, сорауны язып алып, аны киләсе дәрестә мөгаллимгә бирү кирәк.

Тәҗвид дәресе алдыннан үткән кагыйдәләрне кабатлап алу кирәк. Һәм гомумән алганда, шәкертләргә үткән кагыйдәләрне һәрвакыт кабатлап торырга тырышырга кирәк, чөнки бу тәҗвид фәнен яхшы үзләштерүгә ярдәм итә.

Игътибарны аерата гамәли дәресләргә бирү кирәк, чөнки тәҗвид фәнен яхшы үзләштерү гамәли беркетү белән бик нык бәйләнештә тора. Кагыйдәләрне яттан өйрәнү генә җитәрлек түгел, аларны гамәли яктан да беркетергә кирәк. Гамәли дигәне, шәкертнең Коръән Кәримне укы-

ган вакытта, аятьләрдә булган кагыйдәләрне таба белү, шул кагыйдәләрнең гарәпчә исемнәрен әйтеп бирүне (язып алуны) аңлата.

## 1.6 Тәфсир дәресе

«Тәфсир» сүзенең телдәге мәгънәсе: ачу, төшендерү, аңлатып бирү, шәрех бирү. "Тәфсир"нең шәригатьтәге мәгънәсе: Коръән Кәримнең мәгънәләрен аңлату һәм аның күрсәтмәләрен вә хикмәтләрен тасвирлау белән шөгыльләнүче белемнәр тармагы яисә фән.

Аллаһы Тәгалә рәсүленә мөрәҗәгать итеп әйтә:

وَأَنزَلْنَا إِلَيْكَ الذِّكْرَ لِتُبَيِّنَ لِلنَّاسِ مَا نُزِّلَ إِلَيْهِمْ وَلَعَلَّهُمْ يَتَفَكَّرُونَ

**"Ий Мөхәммәд г-м, Без сиңа Коръән иңдердек, кешеләр өчен хаслап иңдерелгән шәригать хөкемнәрен өйрәтмәклегең өчен, шаять фикерләп карарлар!"** *(ән-Нәхел, 16/44).*

Пәйгамбәребез с.г.в.с. Коръән Кәримне аңлый иде һәм ул аны сахәбәләренә аңлатып бирә иде. Шулай ук, сахәбәләр дә Коръән Кәримне аңлыйлар иде, чөнки ул аларның телләрендә иңдерелгән иде, ләкин аңлауларында бер тигез түгел иделәр.

Коръән Кәримне тәфсир итүдә сахәбәләр түбәндәгеләргә нигезләнә иделәр:

1) Коръән Кәримнең үзенә.

2) Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең аңлатмаларына: ул аларга Коръән аятьләрен аңлатып бирүче иде, сахәбәләр әгәр аңламасалар аңа мөрәҗәгать итәләр иде.

3) Аңлауларына һәм иҗтиһад итүләренә.

Сахәбәләрдән мәшһүр мөфәссирләр: Әбү Бәкер, Гомәр, Госман, Гали, ибн Мәсгүд, ибн Гәббәс, Үбәйә бин Кәгъб, Зәйд бин Сәбит, Әбү Муса әл-Әшгәри, Габдуллаһ ибн Зүбәйр, Әнәс бин Мәлик, Габдуллаһ бин Гомәр, Җәбир бин Габдуллаһ, Габдуллаһ ибн Гамр бин әл-Гас, Гайшә.

Табигыйннар гасырында Ислам фәтехләре киңәя һәм сәхабәләр төрле якларга таралалар. Һәрберсе үз гыйлемен шул якларда тарата, алардан үз гыйлемен табигиннар алалар. Шул сәбәпле, төрле күп юнәлешләр (мәдрәсәләр) барлыкка килә.

Мәккәдә ибн Габбас мәдрәсәсе таралып, мәшһүр шәкертләре түбәндәгеләр булган: Сәгыйд бин Җәбир, Мүҗәһид, Гикрама (ибн Габбасның хезмәтчесе), Таус бин Кисән әл-Ямәни, Гәтаъ бин Әби Рибәх.

Мәдинәдә тәфсир кылу белән Үбәйә бин Кәгъб мәшһүр булып китә. Аннан алган табигиннар түбәндәгеләр: Зәйд ибн Әсләм, Әбү Гәлия, Мөхәммәд бин Кәгъб әл-Куртуби.

Гыйракта ибн Мәсгүд мәдрәсәсе барлыкка килә. Тәфсир кылу белән мәшһүр булып киткән табигиннар түбәндәгеләр: Гәлкамә бин Кайс, Мәсрук, Әл-Әсвәд бин Язид, Гәмир әш-Шүгби, әл-Хәсән әл-Бәсри, Катәдә бин Дәгәмә әс-Сүдүси.

Алардан бу гыйлемне табгү-табигиннар алалар.

Өмәвиләр гасырының (661-750/41-132 еллар) ахырында – Гәббәсиләр гасырының (750-950/132-4нче гасырның уртасы) башында классификацияләү дәвере башлана. Хәдисләрне классификацияләү төрле бүлекләрдән булып, тәфсир кылу шул бүлекләрнең бер өлеше иде. Бу дәвергә сүрәләрне һәм аятьләрне башыннан алып ахырына хәтле тәфсир кылу хас түгел иде.

Тәфсирне Пәйгамбәребез с.г.в.с. нән, сәхабәләрдән, табигиннардан риваять итүдә галимнәр бик зур тырышлык күрсәтәләр. Моның белән шөгыльләнүчеләрнең иң мәшһүрләре: Язид бин Һәрун әс-Сәлми (һиҗри белән 117 елда вафат), Шүгбә бин әл-Хүҗҗәҗ (һиҗри белән 160 елда вафат), Вәкиг бин әл-Җәрах (һиҗри белән 197 елда вафат), Сүфьян бин Гәйинә (һиҗри белән 198 елда вафат), Рух бин Гибәдә әл-Бәсри (һиҗри белән 205 елда вафат), Габдүрраззак бин Һәмәм (һиҗри белән 211 елда вафат),

Әдәм бин Әби Ийәс (һиҗри белән 220 елда вафат), Габдү бин Хәмид (һиҗри белән 249 елда вафат).

Аларга барып тоташа торган тәфсирләр юк, ләкин “әл-Мәъсүр” тәфсирләрендә[18] чылбыры аларга барып тоташа торган риваятьләр бар.

Соңыннан алардан соң тәфсирне хәдистән аерым, Коръәннең тәртибе буенча тәфсир кылучы галимнәр барлыкка килә. Алар түбәндәгеләр: Ибн Мәҗә (һиҗри белән 273 елда вафат), Ибн Җәрир әт-Табәри (һиҗри белән 310 елда вафат), Әбү Бәкер бин әл-Мүнзир ән-Нишәбүри (һиҗри белән 318 елда вафат), Ибн Әби Хәтим (һиҗри белән 327 елда вафат), Әбү әш-Шәйх бин Хәббән (һиҗри белән 369 елда вафат), әл-Хәким (һиҗри белән405 елда вафат), Әбү Бәкер бин Мәрдәвия (һиҗри белән 410 елда вафат).

Аларның тәфсирләренең чылбыры Пәйгамбәребез с.г.в.с. гә, сәхабәләргә, табигиннарга, табгү-табигиннарга тоташып риваять ителә.

***1. Тәфсир укытуның максатлары***

Аерым максатлар һәрбер дәрескә, темасына карап, куела:

1) Коръән Кәримдәге мәгънәләрне аңлау һәм алар белән тәэсирләнү;

2) укучыларның Коръән Кәрим аятьләренең хәзинәләреннән белемнәрен арттыру;

3) Коръән Кәрим аятьләре үз эченә алган хөкемнәрне, күркәм холыкларны, үз-үзен тоту әдәпләрен ачыклау;

4) укучыларның Коръәндә булган нәрсәләр белән канәгать булуларын, бөтен заманнарга һәм урыннарга тормыш өчен яраклы тулы система булуын ныгыту;

5) шәкертләрне Коръән Кәримне тәфсир итүдәге методларга гадәтләндерү (аларга аны аңлау җиңел булсын өчен);

6) тормышыбызны Коръән күрсәткән туры юлга юнәлтү;

7) пәйгамбәрләрнең, салих булучы кешеләрнең тормыш-

[18] “Әл-Мәъсүр” тәфсирләре – Коръәнгә, сөннәткә яисә сәхабәләрдән риваять иткәнгә нигезләнгән тәфсирләр.

ларына ияру, аларның тормышлары һәм яшәү рәвешләре белән тәэсирләнү;

8) Коръән Кәримнең могҗизалыгын бәян итү.

***2. Укыту методлары***

1. Әзерләү: укучыларны мәгълүмат кабул итүгә хәзерләү һәм игътибарларын җәлеп итү, укытыла торган аятьләрнең мәгънәләренә карата карашларын ныгыту. Аның методлары: 1) укытыла торган аятьләргә бәйле булган кызыклы кыйссалар сөйләү; 2) мөнәсәбәтле сөйләү яисә тапшыру тыңлау яки газета-журналларда нәшер ителгән хәбәрләрне уку, сөйләү; 3) табигатьтә булган күренешләр: җир тетрәүләр, янартауның (вулканның) атылуы, су басулар, давыллар, көчле җилләр һ.б. турында мәгълүмат бирү.

2. Аятьләрдә булган мәгънәләр, дини хөкемнәр, әдәпләр хакында укучыларга гомуми фикер бирү.

3. Аятьләргә тәфсилле шәрх (аңлатма) бирү һәм фикер алышу. Аның методлары:

- аерым сүзләрнең һәм гыйбәрәләрнең мәгънәләре хакында фикер алышу, шул сүзләргә синонимнар табу, мисаллар китерү, схемалар яисә рәсемнәр куллану;
- аятьләрдә булган мисаллар, кыйммәтләр, хөкемнәр, нигезләр хакында фикер алышу;
- аятьләрнең мәгънәләрен ачыклау өчен, мисал итеп Коръән Кәрим аятьләрен һәм хәдис-шәрифләрне китерү;
- аятьләрнең иңү сәбәпләрен китерү;
- аятьләр белән бәйле кыйссалар китерү;
- аятьләрне тормыш вакыйгалары белән бәйләү;
- Коръәндә килгән кайбер вакыйгаларны һәм кыйссаларны мисалга китерү.

4. Укытучының шушы аятьләрне укучылардан ятлауны таләп итүе.

5. Нәтиҗә ясау.

## Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр:

1. Коръән Кәримнең үзенә генә хас нинди аермалыклар бар? Шуларны китерегез.

2. Коръән Кәримнең иң әһәмиятле максатларын әйтеп чыгыгыз.

3. Коръән Кәрим белән эш итү рәвеше нидән гыйбарәт? Шуларны санап чыгыгыз.

4. Коръән Кәримне уку (кыйраәт) дәресенең максатларын, укытуның методларын, укудагы хаталарны төзәтү методларын әйтеп чыгыгыз.

5. Коръән Кәримне ятлау (хифз) дәресенең максатларын, ятлату методларын санап чыгыгыз.

6. Тәҗвиднең укыту максатларын, укыту бурычларын, укыту максатларын китерегез.

7. Тәфсир укытуның максатларын, укыту методларын әйтеп чыгыгыз.

## Кушымталар

*Тәҗвид дәресләрен алып баруга якынча программа үрнәге*

***Кереш бүлек***

1 дәрес. Коръән Кәрим. Коръәнне бастыру тарихы. Коръән басмалары. Казан басмасы.

2 дәрес. Тәҗвид фәне.

3 дәрес. Коръән Кәримне уку һәм аның гыйлемен үзендә йөртүченең өстенлекләре.

4 дәрес Коръән Кәримгә карата булган әдәпләр (Коръән Кәримне укыр алдыннан, укыган вакытта үтәлә торган әдәпләр, гомуми әдәпләр).

5 дәрес. Әгүзү билләһи минәш-шәйтанир-раҗим сүзләрен әйтүнең хөкеме, куллана торган тәгъбирләре, ачык һәм яшерен әйтү мөстәхәб булган урыннар, кайтарып уку урыннары, сүрәнең башыннан башлап китү ысуллары, «Тәүбә» сүрәсен уку ысуллары.

6 дәрес. Бисмилләһир-рахмәнир-рахим сүзләрен әйтүнең хөкеме.

***Төп бүлек. Тәҗвид кагыйдәләре***

1 дәрес. Тәнвин һәм сәкенле «нун» кагыйдәләре: 1) Изһәр; 2) Идгам мәгаль гуннә; 3) Идгам билә гуннә; 4) Иклаб; 5) Ихфа мәгаль гуннә.

2 дәрес. Сәкенле «мим» кагыйдәләре: 1) Идгам мисләин мәгаль гуннә; 2) Ихфа шәфәви; 3) Изһәр шәфәви.

3 дәрес. Тәшдидле «нун» һәм «мим» хәрефләренең кагыйдәсе.

4 дәрес. Мәд: 1) Мәд табигый; 2) Мәд моттәсыйл; 3) Мәд монфасыйл; 4) Мәд ләзем; 5) Мәд гарыйз; 6) Мәд лин.

5 дәрес. Вакыфның аңлатмасы; вакыф кылынган (тукталган) сүзнең ахыры үзгәрү рәвеше.

6 дәрес. Калькалә.

7 дәрес. Истигалә хәрефләре.

8 дәрес. Истифәлә хәрефләре.

9 дәрес. Идгам: 1) Идгам мисләин (Идгам мисләин мәгаль гуннә; Идгам мисләин билә гуннә); 2) Идгам мутәҗәнисәин; 3) Идгам мутәкарибәин.

10 дәрес. Изһәр камәрия.

11 дәрес. Идгам шәмсия.

12 дәрес. Васл.

13 дәрес. Сәктә.

14 дәрес. Тәксир тәнвин.

*Тәфсир дәресләрен алып баруга якынча программа үрнәге*

1. Тәфсир фәненең аңлатмасы, барлыкка килүе.
2. Мөфәссирнең шартлары һәм әдәпләре. Мәшһүр тәфсирләр.
3. Әл-Фәтиха сүрәсе: сүрәнең исемнәре, аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары, әл-Фәтиха сүрәсенең фәзыйләтләре.
4. Әл-Бәкара (1-5 аятьләр): аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары.
5. Аятел-Көрси (әл-Бәкара, 2/255): аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары, фәзыйләтләре.
6. Әл-Ихлас сүрәсе: сүрәнең иңү сәбәбе, ихласлыкның мәгънәләре, аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары, фәзыйләтләре.
7. Әл-Фәләкъ сүрәсе: сүрәнең иңү сәбәбе, аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары, фәзыйләтләре.
8. Ән-Нәс сүрәсе: сүрәнең иңү сәбәбе, аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары, фәзыйләтләре.
9. Әл-Мәсәд сүрәсе: сүрәнең иңү сәбәбе, аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары.
10. Ән-Нәср сүрәсе: аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары.
11. Әл-Кәфирун сүрәсе: сүрәнең иңү сәбәбе, аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары.

12. Әл-Кәүсәр сүрәсе: сүрәнең иңү сәбәбе, аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары.

13. Әл-Мәгүн сүрәсе: ике төркем кешеләр турында булуы, аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары.

14. Кураеш сүрәсе: аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары.

15. Әл-Фил сүрәсе: фил вакыйгасы, аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары.

16. Әл-Һүмәзәһ сүрәсе: өч өлешкә бүленгән булуы, аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары.

17. Әл-Гаср сүрәсе: аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары, фәзыйләтләре

18. Әт-Тәкәсүр сүрәсе: аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары.

19. Әл-Каригаһ сүрәсе: аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары.

20. Әл-Гадият сүрәсе: сүрәнең иңү сәбәбе, аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары

21. Әз-Зәлзәлә сүрәсе: башка исеме, сүрәнең иңү сәбәбе, аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары.

22. Әл-Бәйинәһ сүрәсе: сүрәнең башка исемнәре, аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары.

23. Әл-Кадр сүрәсе: сүрәнең иңү сәбәбе, аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары.

24. Әл-Галәк сүрәсе: шушы сүрәнең әүвәлге 5 аяте иңдерелү вакыйгасы, аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары.

25. Әт-Тин сүрәсе: аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары.

26. Әд-Духә сүрәсе: сүрәнең иңү сәбәбе, аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары.

27. Әш-Шәрх сүрәсе: башка исеме, аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары.

28. Йәсин сүрәсе: аерым сүзләрнең һәм аятьләрнең аңлатмалары. Фәзыйләтләре.

*Коръән Кәрим дәресен уздыру үрнәге*

**Тема: Мөселманнарның изге Китабы – Коръән Кәрим**

**Максат: Коръән Кәрим белән, аның төрле басмалары белән таныштыру.**

***Дәрес барышы***

Дәрес укытучының сөйләве белән башлана: Күп өлкәләргә караган һәм төрле елларда чыккан, байтагы, әлбәттә инде, гарәп графикасы белән басылганнары, таушалып, саргаеп беткән китаплар күргәзмәсенә күзәтү үткәрү, нәтиҗәләр ясау. Әйе, кешелек дөньясында нинди генә китаплар булмаган. Әмма тормыш зилзиләсе белән борынгы китапларының кайберләре бөтенләй юкка чыккан, кайберләре саргаеп, таушалып беткән. Беренче һәм соңгы битләре югалып, авторы һәм исеме билгесез булган китаплар иксез-чиксез. Бу гарәп графикалы чыганакларыбызны, рәхмәт яусын, белем сөюче халкыбыз саклап калган. Иҗтимагый тормышның коточкыч туфаннарыннан, эзәрлекләүләрдән исән калган, әллә нинди бозу, начар ният белән “ревизияләүләрдән” саф, пакъ калган, халкыбызны милләт буларак югалтудан саклауда төп рольне уйнаган гаҗәеп олуг бер Китап бар.

Укучыларга Коръәннең һәм Коръән тәфсиренең төрле бастырылган нөсхәләре күрсәтелә.

Бу – мөселманнарның изге Китабы – Коръән Кәрим.

“Коръән Кәрим” дип тактага һәм дәфтәрләргә язып куела, һәрвакыт баш хәреф белән язылганлыгы ассызыклана, дөрес әйтү күнегүләре үткәрелә.

Алга таба укучылар плакатка зәвык белән язылган Ибраһим Гази сүзләрен укыйлар: “Дәүләтләр булган – беткән, халыклар яшәгән – эзе дә калмаган. Ай калган, Кояш калган да китап калган”.

Укытучы: - Бу хак сүзләргә тагын нәрсә дә булса өстәргә телисезме? Нинди өстәмәләр бар?

- Китапларның да Китабы Коръән калган...

- Ай, Кояш кебек күңелләрне нурландырып торган Коръән калган...

- Коръән нинди Китап соң ул? Мөселман дөньясының миллионлаган кешесе күңеленә нинди очкын белән үтеп кергән һәм ни өчен “Изге Китап” дип аталган ул? Эчтәлеге нәрсәләрдән гыйбарәт? Төзелеше нәрсә белән үзенчәлекле? Сәнгатьчә кыйммәте нәрсәдә? Төрле милләт халыкларының Коръән белән кызыксынуын нәрсәләр белән аңлатырга?

Мөгаллим дәрестә әнә шул һәм башка сорауларга бергәләп җавап табарга тырышачакларын кисәтә, Октябрь инкыйлабына кадәр Коръән тәфсиренең башлангыч сыйныфтан алып, укуның соңына кадәр өйрәнелүе, мәдрәсә шәкертләренең Коръәннән зур-зур өзекләрне, ә аеруча тырышларының Коръәнне тулысынча яттан белүләре, аны көйләп, дулкынланып һәм башкаларны да дулкынландырып сөйләүләре, йөрәкләргә үтеп керерлек итеп тәфсирен әйтүләре турында сөйли.

Укытучы: Шулай итеп. Коръән нинди Китап ул?

Бергәләп нәтиҗәгә киленә: Коръән безнең бабаларыбыз өчен кайгылы һәм хәсрәтле көннәрендә юатучы, акны карадан аерырга өйрәтүче, тән сәламәтлеген тәрбияләүче, рухи өлгергәнлеккә өндәүче, кешеләрнең күзләрен ачарга ярдәм итүче аң-белем хәзинәсе булган...

Фикерне дәлилләү Изге Китапка презентация үткәрү тәртибендә бара.

1) Иң әүвәл укытучы бу Изге Китапны, сак кына һәм кадер белән тотып, укучыларга күрсәтә, интерактив тактадан аның тышлыгын, өч-дүрт битен бик игътибар белән карарга тәкъдим итә, аның, күренгәнчә, гарәп телендә язылганлыгын, гарәп телендә укылырга тиешлеген хәбәр

итә. Соңыннан, сүзен җөпләп, ул кулындагы Коръәннән бер өзекне бөтен кагыйдәсен туры китереп (яттан, тиешле көйләве белән) укый, ә укучылар укылганның текстын интерактив китаптан карап баралар.

2) Дәрестә мөгаллимнең Коръән тәфсире турында дә мәгълүмат бирүе мөһим. Мәгънә бозу ихтималы булганга, Коръәнне башка төрки халыклар теленә тәрҗемә итү тыела. Коръән гарәп телендә укылырга тиеш дип табыла. Чыннан да, мәктәп-мәдрәсәләрдә гарәп-фарсы телләре өйрәнелгәнгә, татар зыялылары Коръәнне аңлап, иркен һәм җиңел укый алганнар. Әмма мөселман өммәтеннән булган һәркемнең Коръәнне белүе фарыз саналган, һәм бер-бер артлы Коръән тәфсирләре басылып, чыгып торган (кадрда берничәсе күрсәтелә).

Укытучы: - Шунысы мөһим: Коръән тәфсирен дә халкыбыз үзенең рухи азыгы дип кабул иткән, Коръәнне кадерләгән кебек үк кадерләгән, изге санаган. Хәзерге яшьләр дә, укучылар да, гарәпчә белмәсә дә, тәфсире аша Коръән белән таныша, аның көченә төшенә ала.

3) Коръәннең Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. исеме белән бәйле булганга, укучыларны аның сирасы белән таныштыру максатка ярашлы. Алдан өйдә хәзерләнү өчен өч-дүрт укучыга, аны этапларга бүлеп, Мөхәммәд с.г.в.с. нең сирасын өйрәнергә тапшырыла. Хәзерләнгән укучылар дәрестә чыгыш ясыйлар, ягъни белгәннәре белән урталашалар.

Укытучы: - Сүрә – Коръәннең өзеге, бүлеге дигәнне аңлата. Аять – Коръән сүрәләренең бүленеш берәмлеге, сүрәдәге абзац.

Балаларга Коръән тәфсире таратыла. Аның тышлыгы, титул бите, аерым битләре каралганнан соң, укучылар тәфсирнең эчтәлек өлешен укыйлар. Нәтиҗәләргә киленә: Коръән исемләнгән аерым өлешләрдән – сүрәләрдән тора. Барлыгы 114 сүрә. Сүрәләр үз чиратында номерлар белән

билгеләнгән-бүлгәләнгән кисәкләрдән – аятьләрдән тора. Мөгаллим укучыларга Коръәннән бүленеш үзенчәлеген күрсәтә, өстәмә мәгълүматлар китерә.

Тәфсирне карап укучылар сүрә, аятьләрнең урнаштырылу тәртибен ачыклыйлар. Беренчесе – Фатихә сүрәсе. Бу сүрәне мөселманнар намазларында рәкәгать саен укыганлыгы әйтелә. Мөгаллим сүрәне укучылар белән бергәлектә укый.

Коръәннең гарәп телендәге төп нәсхәсен тиешле кагыйдәләр белән укылырга тиешлеген, аңа тәһарәт алмыйча кагылу зур гөнаһ саналганын аңлату. Балалар нәрсә турында сүз барганын белеп торсыннар өчен, башта тәфсирне, аннары Коръәннең төп текстын уку да максатка ярашлы.

Дәрескә нәтиҗә ясап, укытучы:

- Коръән Кәрим – ул Аллаһы Тәгаләнең Кәләме (Сүзе), ачык гарәп телендә, Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. гә, фәрештә Җәбраил г.с. аша вәхи аркылы, мөтәватир хәлендә, 23 ел дәвамында иңдерелгән. Аллаһы Тәгалә тарафыннан сакланырга вәгъдә ителгән, Ислам диненең, мөселманнарның Изге Китабы. Анда Ислам диненең кануннары аңлатыла.

*Тәҗвид дәресен уздыру үрнәге*

**Тема: Идгам мәгаль гуннә кагыйдәсе**

**Максат: Укучылар тарафыннан “идгам мәгаль гуннә” кагыйдәсен белүгә, Коръән Кәримне укыганда аны таба белүгә һәм дөрес укуга ирештерү.**

***Дәрес барышы***

***1. Өйгә бирелгән эшне тикшерү, үткән кагыйдәне кабатлап алу, сорауларга җаваплар бирү.***

Укытучы әүвәлге дәрестә бирелгән өй эшен укучыларның дәфтәрләреннән тикшерә, хаталы урыннарын күрсәтә. Өй эшләренә нәтиҗә ясала: хаталы мисаллар тактага язылып тикшерелә, аңлатыла.

Соңыннан укытучы әүвәлге дәрестә үткән кагыйдәне кыскача кабатлап ала, Коръәннән мисаллар китерә, кагыйдәнең авыррак аңлашыла торган урыннарына игътибар иттерә.

***2. Яңа теманы аңлату.***

Укытучы: Бүгенге дәресебезнең темасы: “Идгам мәгаль гуннә кагыйдәсе”. “Идгам” дигәне “икеләтү”, “ассимиляция”, “мәгаль гуннә” дигәне “борын аркылы” дип тәрҗемә ителә. Татар телендә: “Хәрефне борын аркылы икеләтү кагыйдәсе”. Димәк, шушы кагыйдә буенча бер хәреф икенче хәрефкә кертелеп, борынга җибәрелеп укыла.

Идгам мәгаль гуннә кагыйдәсе: Әгәр тәнвин яисә «нун» сәкен ی – م – ن – و хәрефләренең берсенә очраса, әүвәлге хәреф (сәкенле «нун» яисә тәнвиннең нун өлеше) үзеннән соң килгән хәрефкә кертелеп, борынга җибәрелеп, бераз тоткарланып (2 хәрәкәлек микъдар) укыла.

Димәк, кагыйдә буенча, сәкенле «нун» яисә тәнвиннең нун өлеше үзеннән соң килгән хәрефкә кертелә һәм аның укылышы үзеннән соң килгән хәрефкә охшаш була. Мәсәлән, сәкенле «нун» яисә тәнвиннән соң (ن) хәрефе килсә сәкенле «нун» яисә тәнвиннең нун өлеше борынга җибәрелгән (ن) хәрефе итеп укыла, (م) хәрефе килсә сәкенле «нун» яисә тәнвиннең нун өлеше борынга җибәрелгән (م) хәрефе итеп укыла.

Ике хәрәкәлек микъдар дигәне – ике бармакны бөгү яисә турайту дип аңлашылырга тиеш.

Мисаллар карап үтәбез:

**111/5** فِي جِيدِهَا حَبْلٌ مِن مَّسَد

Бу аятьнең беренче өлешендә өтер тәнвиннән соң “мим” хәрефе килү сәбәпле, тәнвиннең “нун” өлеше “мим” хәрефенә кертелеп борынга җибәрелеп ике микъдар тоткарланып укыла.

Икенче өлешендә сәкенле “нун” хәрефеннән соң “мим” хәрефе килү сәбәпле, сәкенле “нун” хәрефе тулысынча

“мим” хәрефенә кертелеп борынга җибәрелеп ике микъдар тоткарланып укыла.

Шушындый рәвештә тәҗвид китабында китерелгән калган мисаллар да карала.

Бу кагыйдәнең искәрмәсе бар: әгәр сәкенле «нун» (و) яисә (ي) хәрефләренең берсенә очраса һәм икесе дә бер сүздә булсалар, ул вакытта изһәр була, идгам булмый.

Димәк, идгам мәгаль гуннә кагыйдәсенең искәрмәсе “нун” хәрефе һәм (و) яисә (ي) хәрефләре белән генә бәйле. Шулай ук, бу искәрмә Коръәндә дүрт сүздә генә килә:

(قِنْوَانٌ); (صِنْوَانٌ); (بُنْيَنٌ); (الدُّنْيَا)

Бу сүзләргә мисаллар түбәндәге аятьләрдә килә:

وَمِنَ النَّخْلِ مِن طَلْعِهَا قِنْوَانٌ دَانِيَةٌ (6/99) رَبَّنَآ ءَاتِنَا فِي الدُّنْيَا حَسَنَةً 2/201

كَأَنَّهُم بُنْيَنٌ مَّرْصُوصٌ (4/61) وَنَخِيلٌ صِنْوَانٌ 13/4

Соңыннан укытучы шәкертләрнең сорауларына җаваплар бирә (әгәр булса).

***3. Теманы гамәли яктан ныгыту.***

Шушы дәрестә һәм элеккеге дәресләрдә үткән кагыйдәләрне ныгыту өчен дәреснең гамәли өлеше уздырыла. Моның өчен берәр сүрәне яисә аерым аятьләрне алып, шәкертләрдән бөтен үткән кагыйдәләрне әйтеп чыгуны сорау яисә аерым кагыйдәнең (мәсәлән, идгам мәгаль гуннә кагыйдәсенең) ничә тапкыр кабатланып килгәнен әйтеп бирүне сорау яки үткән кагыйдәләрнең күпме булуын сан белән билгеләүне сорау һ.б. Мондый гамәли эшне башкаруны мөмкин булган хәтле күбрәк шәкерттән дә таләп итү.

4. Дәресне йомгаклау.

Дәрестә үткән кагыйдә укытучы тарафыннан кабатланып алына. Шулай ук, укытучы укучылардан сорау-җавап рәвешендә дә үткән дәресне ныгытырга мөмкин.

5. Өйгә эш.

Үткән кагыйдә буенча өй эше бирелә. Өй эше үткән кагыйдәгә Коръән Кәримнән мисаллар китерү һәм кыска сүрәләрне дәфтәргә күчереп, үткән кагыйдәләрне билгеләп чыгудан гыйбарәт.

**Тема: “Әл-Ихлас” сүрәсе**

**Максатлары:**

1) “Әл-Ихлас” сүрәсендә булган тәҗвид кагыйдәләрен тикшереп чыгу.

2) “Әл-Ихлас” сүрәсен хатасыз укуга ирештерү һәм ятлатыру.

3) Укучыларда “әл-Ихлас” сүрәсенең иңү сәбәбен белүгә ирештерү.

4) “Әл-Ихлас” сүрәсенең тәфсирен (мәгънәләрен) аңлауга ирештерү.

***Өйгә бирелгән эш.***

Укучылар дәрескә “әл-Ихлас” сүрәсен тәфсир дәфтәрләренә күчереп киләләр. Күчергәндә, һәр аятьне һәм аятьтәге һәр сүзне аерым язып килү.

Дәрес барышы

Тактага “әл-Ихлас” сүрәсе язылган бит элеп куелган. Һәр укучының өстәлендә Коръән мосхафы, тәфсир дәфтәре, карандаш һәм ручка. Укытучы өстәлендә магнитофон (яисә компьютер) һәм Коръән яздырылган кассета (яисә CD).

***1. Яңа теманы аңлату***

Дәреснең 1 нче өлеше.

Укытучы: Бүген без сезнең белән “әл-Ихлас” сүрәсен үтәрбез. Башта без ул сүрәне тыңлап һәм укып алыйк.

Укытучы магнитофонда (яисә компьютерда) Коръән яздырылган кассета (яисә CD) куя. Укучылар аны мосхафтан карап тыңлыйлар. Соңыннан укытучы сүрәне укып чыкканнан соң, укучылардан бергәләп укуларын таләп итә. Сүрәне шундый рәвештә укып бетергәннән соң берике укучыдан сүрәне укып чыгуларын сорый.

Соңыннан сүрәдәге тәҗвид кагыйдәләре карап үтәлә. Укытучы тәҗвид кагыйдәләрен укучылардан әйтеп бирүен таләп итәргә мөмкин яисә үзе кайбер кагыйдәләргә игътибарларын юнәлтергә мөмкин.

Укучылар аятьләрдәге тәҗвид кагыйдәләрен дәфтәрләренә билгеләп чыгалар.

Дәреснең 2 нче өлеше: "әл-Ихлас" сүрәсенең иңү сәбәбе

Укытучы: Бер көнне кораеш мөшрикләре Пәйгамбәребез с.г.в.с. янына килеп сорадылар: "Раббың турында безгә сөйләп бир әле. Ул нәрсәдән ясалган: алтыннанмы, бронзаданмы, көмештәнме яки тимердәнме?" Шуларга җавап итеп шушы сүрә иңдерелә. Аның исеме "әл-Ихлас". Ихлас дигән сүз нәрсәне аңлата?

Укучы: "Ихлас" сүзе эчкерсезлек дигәнне аңлата.

Укытучы: Әйе, татар теле аңлатмалы сүзлегендә килгәнчә, ихлас – ул күңел чынлыгы, сафлыгы, турылык, эчкерсезлек дигәнне аңлата. Ихласлык үз эченә өч мәгънәне ала: 1) Аллаһы Тәгаләгә хезмәт итүдә ихласлык; 2) Аллаһ ризалыгы өчен гамәлләр кылуда ихласлык; 3) Аллаһы Тәгаләгә калебнең ихласлыгы.

Шул хакта укучылар белән диалог.

Укучылар "Ихлас" сүзенең мәгънәсен дәфтәрләренә язып алалар.

Дәреснең 3 нче өлеше: Сүрәнең тәфсире, мәгънәләре

1) بسم الله الرحمن الرحيم .قُلْ هُوَ اللَّهُ أَحَدٌ

قُلْ Әйт (Әй, Мөхәммәд с.г.в.с.)

هُوَ اللَّهُ Аллаһ – Ул

أَحَدٌ Берәү генә

"Әйт (Әй, Мөхәммәд с.г.в.с.): "Аллаһы Тәгалә – Ул берәү генә". Монда Аллаһы Тәгаләнең берлеге сан ягыннан түгел, ә Аның Затына, сыйфатларына һәм фигылләренә охшаш һичбер нәрсәнең булмавы һәм Аңа тиң булмавы, шәрикләре (иптәшләре) юклыгы мәгънәсендә.

Шул хакта укучылар белән диалог.

2) اللَّهُ الصَّمَدُ

اللَّهُ الصَّمَدُ Аллаһ – Ул мәңге (һичбер нәрсәгә мохтаҗ түгел)

"Аллаһ – Ул мәңге (һичбер нәрсәгә мохтаҗ түгел)". Аллаһы

Тәгалә мәңге, ягъни Ул һәрвакыт булган һәм һәрвакыт булачак. Аллаһы Тәгаләнең һичбер нәрсәгә, һичбер мәхлукка ихтыяҗы юк, бәлки һәр мәхлукның хаҗәтен үтәүчедер. Аллаһ безнең ихтыяҗларыбызны канәгатьләндерүе өчен, без Аңа мөрәҗәгать итәбез, ләкин Аллаһы Тәгаләнең бер нәрсәгә дә ихтыяҗы юк.

Шул хакта укучылар белән диалог.

3) لَمْ يَلِدْ وَلَمْ يُولَدْ

| | |
|---|---|
| لَمْ يَلِدْ | Һич кемне тудырмады |
| وَلَمْ يُولَدْ | Һәм һич кемнән тудырылмады |

“Һич кемне тудырмады һәм һич кемнән тудырылмады”. Аллаһы Тәгалә һәрвакыт булган һәм Ул бер кемнән дә тумаган, чөнки Аның бу эшләргә ихтыяҗы юк. Бу аять нәсараларга да җавап, чөнки алар Гайсә г.с. не Аллаһның улы дип әйтәләр.

Шул хакта укучылар белән диалог.

4) وَلَمْ يَكُنْ لَهُ كُفُوًا أَحَدٌ

| | |
|---|---|
| وَلَمْ يَكُنْ لَهُ | Һәм Аңа (Аллаһка) булмады |
| كُفُوًا | Тиңдәш |
| أَحَدٌ | Һичбер кем |

“Һәм Аңа (Аллаһка) һичбер кем тиңдәш булмады”. Аллаһы Тәгаләгә тиңдәш Зат юк, чөнки Ул бөтен нәрсәне: Җирне, күкне, хайваннарны, бөҗәкләрне, кош-кортларны бар иткән. Аллаһы Тәгаләне күз алдына да китерү мөмкин түгел.

Укучылар аятьләрнең мәгънәләрен дәфтәрләренә язып алалар.

Дәреснең 4 нче өлеше: “әл-Ихлас” сүрәсенең өстенлекләре

“Әл-Ихлас” сүрәсе үзе бик кыска сүрә булса да, үзенә Аллаһы Тәгаләне тану гыйлемен алган. Хәдистә бу сүрә Коръәннең өчтән бере дип килә. Шул сәбәпле, бу сүрәне өч тапкыр укыган кеше Коръәннең бөтенесен укып чыккан савапка ирешкән шикелле булыр. Ләкин, бу Коръәнне укымасаң да була дигән сүз түгел. Кайбер галимнәр “әл-Ихлас” сүрәсе – Ислам диненең яртысы” дип әйтәләр.

Пәйгамбәребез с.г.в.с. бу сүрәне иртә һәм кич укырга, ә йокы алдыннан “әл-Фәләк” һәм “ән-Нәс” сүрәләре белән бергә укыганнан соң бөтен тәнне сыпырып чыгарга һәм шулай өч тапкыр эшләргә кушкан.

Бер вакытны Пәйгамбәребез с.г.в.с. сугышларның берсенә бер сәхабәне җибәрә. Ул намазда “әл-Фәтиха” сүрәсеннән соң һәрвакыт “әл-Ихлас” сүрәсен укый торган булган, хәтта өченче һәм дүртенче рәкәгатьләрдән соң. Калган сәхабәләр моңа аптырап Пәйгамбәребез с.г.в.с. нән шуның хакта “Шулай ярыймы?” дип сорадылар. Пәйгамбәребез с.г.в.с. әйтте: “Сез аның үзеннән сорагыз”. Алар сорагач ул әйтте: “Мин ул сүрәне бик яратам, чөнки анда Аллаһы Тәгаләнең сыйфатлары бар”. Шуннан соң Аллаһы Тәгаләдән вәхи килә: “Ул бу сүрәне яратканы өчен Мин дә аны яраттым” дип.

Укучылар “әл-Ихлас” сүрәсенең өстенлекләрен дәфтәрләренә язып чыгалар.

***2. Дәресне йомгаклау.***

Дәреснең ахырында “Ихлас” сүрәсен укучылар бергәләп укып чыгалар. Аның иңү сәбәбе, тәфсире һәм өстенлекләре кыскача кабатланып алына.

3. Өйгә эш.

Укытучы укучыларга “әл-Ихлас” сүрәсен ятларга, иңү сәбәбен, тәфсирен (мәгънәләрен) һәм өстенлекләрен өйрәнергә куша.

# 2. ИСЛАМ ГАКЫЙДӘСЕ (ИМАН) ДӘРЕСЛӘРЕ

2.1 Ислам гакыйдәсенең аңлатмасы, рөкеннәре, кешегә һәм җәмгыяткә булган тәэсире
2.2 Кешедә иман тәрбияләүдә Коръән Кәримдәге һәм Пәйгамбәребез с.г.в.с. сөннәтендәге методлар
2.3 Иман тәрбияләүдәге нигезләр
2.4 Ислам гакыйдәсен укыту максатлары
2.5 Ислам гакыйдәсен укыту методлары

## 2.1 Ислам гакыйдәсенең аңлатмасы, рөкеннәре, кешегә һәм җәмгыяткә булган тәэсире

Гакыйдә сүзе «бәйләм», «нык булу», «чыдамлы» дигән мәгънәгә ия. Әмма шәригатьтә ул түбәндәгечә аңлатыла: «Гакыйдә – ул Мөхәммәд с.г.в.с. китергән диндә катгый дип беленгән нәрсәләрне тел белән әйтеп, күңел (калеб) белән тәсдыйк итү (хак, дөрес дип тану)». Башка сүз белән әйткәндә гакыйдә – ул Галәм, Кеше, Тереклек, аларның барыннан да элегрәк булган Яратучысы, бу тормыштан соң булачак яңа тормыш, алар арасында бәйләнеш булуы хакындагы гомуми фикер (караш). Гакыйдә өстенә Ислам дине төзелгән һәм ул аның рухи нигезе булып тора.

Ислам гакыйдәсенең рөкеннәре (хакыйкатьләре):

1. “Иләһият”: үз эченә Аллаһы Тәгаләгә, Аның исем һәм сыйфатларына иман китерүне ала.

2. “Пәйгамбәрлек”: үз эченә пәйгамбәрләргә һәм күктән иңдерелгән Китапларга иман китерүне ала.

3. “Яшерен Галәм”: үз эченә бездән яшерен булган Галәмне; үлем, кабергә керүдән алып Кыямәт көне башланганчыга хәтле булган Бәрзах тормышын; Кыямәт көнен, Җәннәт, Җәһәннәм һ.б. ала.

Кешенең үз тирәсендәге нәрсәләрне хисси дәлилләр белән игътикад итүе, акъли дәлилләр белән игътикад итүгә алып бара. Йолдызлар, кояш белән ай, төн белән көн, күкләр һәм җир, үсемлекләр, хайваннар һәм кеше һ.б. шушы Галәмдәге бар нәрсәләр белән Идарә итүче, Хикмәтле, Мәңге булучы Яратучысы бар икәненә катгый дәлил булып торалар.

Гакыйдәнең кешенең тормышына булган тәэсире:

1. Кешене фикерләрендә, әхлагында, яшәү рәвешендә, гамәлләрендә, тормыштагы үлчәүләрендә Ислам шәхесе буларак формалаштыра.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

قُلْ إِنَّ صَلَاتِي وَنُسُكِي وَمَحْيَايَ وَمَمَاتِي لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ

**“Әйт: “Укыган намазым, бугазлаган корбаным, тормышым һәм үлемем – барысы да галәмнәрнең Раббысы Аллаһ өчендер”.**

*(Әл-Әнгәм, 6/162).*

2. Аллаһы Тәгалә тарафыннан булган методларны һәм кануннарны кабул итүе.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

أَمْ لَهُمْ شُرَكَاءُ شَرَعُوا لَهُمْ مِنَ الدِّينِ مَا لَمْ يَأْذَنْ بِهِ اللَّهُ

**“Дөнья малы өчен гамәл кылучы бидгатьләрнең Аллаһтан башка тагын бер Аллаһлары бармы? Аллаһ рөхсәтеннән башка Коръәнгә вә сөннәт-рәсүлгә хилаф шәригать төзеделәр”.**

*(Әш-Шура, 42/21).*

3. Мөселман кешесе Өстен һәм Куәтле булучы Аллаһы Тәгалә белән элемтәдә булганы, Аңа иман китергәне сәбәпле һәрвакыт үзенең абруен саклый һәм кимсетүне инкяр итә.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَلِلَّهِ الْعِزَّةُ وَلِرَسُولِهِ وَلِلْمُؤْمِنِينَ

**“Куәт һәм өстенлек Аллаһка, Аның рәсүленә һәм мөэминнәргә”.** *(Әл-Мунафикун, 63/8).*

4. Мөселман кешесе барча фикерләргә, халәтләргә, вакыйгаларга һәм кыйммәтләргә Ислам гакыйдәсе аша карый.

5. Мөселман бөтен хәлләрдә һәм шартларда адашмый, югалмый, чөнки гакыйдә аны туры юлга юнәлдерә.

6. Тормыштагы максатлары Аллаһы Тәгаләне разый итүгә юнәлгән, гамәлләрен, яшәү рәвешен Аллаһның шәригатенә буйсынуны кыла.

7. Акылын төрле хорафатлардан, адашулардан, ялган нәрсәләрдән имин кыла.

Гакыйдәнең җәмгыятькә булган тәэсире:

1. Җәмгыятьнең бердәм булып үсүе. Раббыбыз бер, Рәсүлебез бер, Коръән бер, Кыйблабыз бер, максатларыбыз бер. Шуңа күрә Ислам өммәте бербөтен булырга тиеш.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

إِنَّ هَذِهِ أُمَّتُكُمْ أُمَّةً وَاحِدَةً وَأَنَا رَبُّكُمْ فَاعْبُدُونِ

**“Тәхкыйк, шушы сезнең Ислам өммәтегез бердер вә Мин сезнең Раббыгыз, Миңа гына гыйбадәт кылыгыз!”**

*(Әл-Әнбия, 21/92).*

2. Пакь-чиста, хезмәттәшлек итүче һәм үзара ярдәмләшүче җәмгыять булып үсүе. Ислам гакыйдәсе яхшылык һәм тәкъвалыкка этәрә, начарлык һәм дошманлыктан тыя, шәхесләрнең калебләренә тел һәм гамәл белән яхшылык эшләүне һәм итагатъ итүне яраттыра.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَلْتَكُنْ مِنكُمْ أُمَّةٌ يَدْعُونَ إِلَى الْخَيْرِ وَيَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَيَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنْكَرِ وَأُوْلَئِكَ هُمُ الْمُفْلِحُونَ

**“Сезләрдән арагызда шәригатьне яхшы белгән кешеләр, әлбәттә, булсын! Алар сезне хәерле эшләргә чакырырлар, башка яхшы эшләрне кылырга әмер бирерләр һәм фәхеш эшләрдән тыярлар. Әнә шундый кешеләр булган җәмәгать һәлак булудан котылып, өстенлек табучыдыр”.** *(Әли Гыймран, 3/104).*

3. Ислам диненең, гакыйдәсенең бөтен кешеләр өчен булуы, бер җир яисә кешеләрнең бер төркеме өчен генә түгеллеге, аерым заман һәм урын белән генә чикләнмәгән булуы.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَمَا أَرْسَلْنَاكَ إِلَّا رَحْمَةً لِلْعَالَمِينَ

**"Ий Мөхәммәд г-м, Без сине галәмнәргә рәхмәт өчен генә җибәрдек".** *(Әл-Әнбия, 21/107).*

## 2.2 Кешедә иман тәрбияләүдә Коръән Кәримдәге һәм Пәйгамбәребез с.г.в.с. сөннәтендәге методлар

1. Гакыйдәне аңлатканда укыта торган темага карата Коръән Кәрим аятьләрен китерү, Коръән Кәрим китергән методларга иярү, кешедә һәм хайваннарда, органик һәм органик булмаган, тереклек һәм үлем һ.б. нәрсәләрдәге табигый күренешләргә нигезләү.

2. Коръән Кәримдә Аллаһы Тәгаләнең барлыгын һәм Аның Яралтучы булуын аңлатуда, Аңа хас булган тулы сыйфатларны бәян итүдә кешедәге, тереклектәге һәм галәмдәге галәмәтләрен китерү методын кулану.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

فَلْيَنظُرِ الْإِنسَانُ مِمَّ خُلِقَ خُلِقَ مِن مَاءٍ دَافِقٍ يَخْرُجُ مِن بَيْنِ الصُّلْبِ وَالتَّرَائِبِ إِنَّهُ عَلَى رَجْعِهِ لَقَادِرٌ

**"Адәм баласы үзенә карасын нәрсәдән халык кылынды? Халык кылынды ятакка коелган судан. Ул су чыгадыр ирнең арка сөякләре арасыннан вә хатынның күкрәк сөякләре арасыннан. Ул – Аллаһ үлгән кешене тергезергә, әлбәттә, кадирдер".**

*(Әт-Тарик, 86/5-8).*

وَفِي الْأَرْضِ آيَاتٌ لِلْمُوقِنِينَ وَفِي أَنفُسِكُمْ أَفَلَا تُبْصِرُونَ

**“Җирдә дә ышанучы гакыллы кешеләр өчен галәмәтләр бардыр. Дәхи үзегезнең төзелешегездә дә галәмәтләр бардыр, шуларны күрмисезме?”** *(Әз-Зәрият, 51/20-21).*

3. Гакыйдәне аңлатканда Коръән Кәрим методлары белән шатландыру һәм куркыту.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَمِنْ آيَاتِهِ يُرِيكُم الْبَرْقَ خَوْفًا وَطَمَعًا وَيُنَزِّلُ من السَّمَاءِ مَاءً

**“Дәхи Аллаһның могҗизасыннандыр сезгә яшенне күрсәтүе, яшеннән куркып, яңгырны өмет иткәнегез хәлдә. Һәм күктән яңгыр иңдереп үлгән җирне тергезүе. Аллаһның бу эшеңдә дә гакыллы кешеләргә дәлил бар”.** *(Әр-Рум, 30/24).*

4. Коръән Кәрим кыйссалары, кешенең күңеленә тәэсир итүче гыйбрәт һәм нәсыйхәтләр, газап һәм интегүләр теләмәү (мәсәлән “Әһлел-Кәһф”, “Әсхәбүл-Үхдүд”).

5. Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең тормыш юлы гакыйдәне торгызудагы тәэсире зур булганы сәбәпле, аның сирасы белән бәйле нәсыйхәтләр, Аллаһы Тәгаләнең мөэминнәрне яклавы, аларга ярдәм бирүе һ.б. хакында сөйләү кирәк. Иманны тәрбияләүдә Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең тормыш юлына нигезләнгән методлар түбәндәгеләр:

1) Кыйссалар белән тәрбияләү;
2) гомум мисаллар китерү белән тәрбияләү;
3) әңгәмә белән тәрбияләү;
4) үрнәк алырлык мисаллар белән тәрбияләү;
5) күнегүләр һәм гамәлләр белән тәрбияләү;
6) гыйбрәтләр һәм нәсыйхәтләр белән тәрбияләү;
7) кызыктыру һәм куркыту белән тәрбияләү.

## 2.3 Иман тәрбияләүдәге нигезләр

Гакыйдә акыл, вөҗдан (ярсучанлык, кичерешләр) һәм гамәл кылу тарафларына нигезләнә. Шулар бер урында җыелса гына мөселман шәхесе барлыкка килә.

Беренчесе: акыл тарафы. Башлангыч сыйныф укучыларына гомум рәвештә хисле нәрсәләргә иярү хас була, абстракт яисә фикерләүгә нигезләнгән нәрсәләр аларга бик күп тәэсир итми. Шуны истә тотып, Ислам тәрбиясе укытучысы балаларны алар хис иткән һәм күзәтеп торган нәрсәләргә, Галәмдә булган гаҗәеп нәрсәләргә, Аллаһы Тәгалә бар иткән мәхлукатларга, аларга ачык һәм яшерен булган нигъмәтләре белән тулыландырган нәрсәләргә юнәлдерергә тиеш. Шушы бар ителгән нәрсәләр (кешеләр, хайваннар, үсемлекләр, йолдызлар, табигать күренешләре) аларга ишарә итүче Коръән Кәрим аятьләре белән бәйле. Боларны күзәтеп торучы да дәлил китерә ала, шуның белән Аллаһы Тәгалә хакында шикләнүгә урын калмый.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

إِنَّ فِي خَلْقِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَاخْتِلَافِ اللَّيْلِ وَالنَّهَارِ وَالْفُلْكِ الَّتِي تَجْرِي فِي الْبَحْرِ
بِمَا يَنفَعُ النَّاسَ وَمَا أَنزَلَ اللَّهُ مِن السَّمَاءِ مِنْ مَاءٍ فَأَحْيَا بِهِ الْأَرْضَ بَعْدَ مَوْتِهَا وَبَثَّ فِيهَا مِنْ
كُلِّ دَابَّةٍ وَتَصْرِيفِ الرِّيَاحِ وَالسَّحَابِ الْمُسَخَّرِ بَيْنَ السَّمَاءِ وَالْأَرْضِ لَآيَاتٍ لِقَوْمٍ يَعْقِلُونَ

**“Җир һәм күкләрнең төзелешендә, төн белән көннең берберсенә каршы булуларында, кешеләргә кирәк нәрсәләрне күтәреп диңгезләрдә корабларның йөрүендә, күктән яңгыр яудырып, Аллаһы Тәгаләнең үлгән җирне тергезүендә, җир өстендә һәртөрле хайваннарны халык кылуында, җилне һәм җир белән күк арасында болытны йөртүендә, әлбәттә, Аллаһның барлыгына һәм берлегенә иман китерү өчен шиксез ачык дәлилләр бар”.** *(Әл-Бәкара, 2/164).*

Төп һәм урта белем бирү баскычларында укучылар абстракт акыл дәлилләре белән исбат итүгә кадир булалар, шул сәбәпле монда акыл, фикерләүгә нигезләнгән дәлилләр китерергә мөмкин.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَضَرَبَ لَنَا مَثَلًا وَنَسِيَ خَلْقَهُ قَالَ مَنْ يُحْيِ الْعِظَامَ وَهِيَ رَمِيمٌ قُلْ يُحْيِيهَا الَّذِي أَنشَأَهَا أَوَّلَ مَرَّةٍ وَهُوَ بِكُلِّ خَلْقٍ عَلِيمٌ الَّذِي جَعَلَ لَكُمْ مِنَ الشَّجَرِ الْأَخْضَرِ نَارًا فَإِذَا أَنْتُمْ مِنْهُ تُوقِدُونَ أَوَلَيْسَ الَّذِي خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ بِقَادِرٍ عَلَى أَن يَخْلُقَ مِثْلَهُمْ بَلَى وَهُوَ الْخَلَّاقُ الْعَلِيمُ

**“Үзенең бер тамчы судан халык кылынганлыгын онытып, кипкән сөяк белән Безгә мисал итеп, бу сөяк череп беткәч, моны кем тергезә алыр, дип. Син аларга әйт: “Бу сөякне әүвәл мәртәбәдә кем юктан бар кылган булса, шул зат тергезер, дип. Ул – Аллаһ барча мәхлукның хәлен белүче. Ул – Аллаһ сезнең өчен яшел агачта ут бар кылды, сез ул агачны сугып ут яндырасыз, яшел һәм сулы агачтан ут чыгарган Аллаһ мәетләрне тергезергә, әлбәттә, кадирдер. Җир вә күкләрне яраткан Аллаһ, кешеләр кеби кечкенә нәрсәләрне халык кылырга кадир түгелме? Әлбәттә кадир, вә Ул Яратучы һәм Белүчедер”.**

*(Йәсин, 36/78-81).*

Икенчесе: вөҗдан (кичерешләр, ярсулык) тарафы.

Күңелгә ошау, күңелне җәлеп итү ул - шәхеснең белгән нәрсәгә карата тотрыклы омтылуының артуы яисә аның хакында, көннәрнең үтүе һәм вакыйгаларның кабатлануы белән, тотрыклылык артуы.

Акылга нигезләнгән дәлилләр аерым бер үзләре генә кешедә гакыйдәне төзүдә җитәрлек түгел, кешенең күңеленә гакыйдәне беркетү өчен, аның хисләрен һәм аларны күңелдә уяту якларын да истә тоту кирәк. Аллаһы Тәгалә кешенең Яратучысы һәм Ул кешегә, аны камил

кылу һәм башка мәхлүкатлардан аеру өчен, акыл бирде, хисләр һәм кичерешләр (ярсулык) белән кылды.

Коръән Кәримдә зекер ителгән кешенең кичерешләре түбәндәгеләр: теләк, курку, өмет, сөю, күрә алмау хисе, Аллаһы Тәгаләгә булган итагатьлек (буйсынучанлык) һәм басынкылык (тирән ихтирам), Аллаһы Тәгаләне мактау һәм олуглау, кимчелек нәрсәләрдән һәм гөнаһ эшләүдән качу.

Аллаһы Тәгалә курку мәсъәләсендә болай диде:

يَاأَيُّهَا النَّاسُ اتَّقُوا رَبَّكُمْ إِنَّ زَلْزَلَةَ السَّاعَةِ شَيْءٌ عَظِيمٌ يَوْمَ تَرَوْنَهَا تَذْهَلُ كُلُّ مُرْضِعَةٍ عَمَّا أَرْضَعَتْ وَتَضَعُ كُلُّ ذَاتِ حَمْلٍ حَمْلَهَا وَتَرَى النَّاسَ سُكَارَى وَمَا هُمْ بِسُكَارَى وَلَكِنَّ عَذَابَ اللَّهِ شَدِيدٌ

**“Ий кешеләр, Раббыгыздан куркыгыз, Аңа гөнаһлы булудан сакланыгыз! Дөреслектә Кыямәт зилзиләсе олугъ куркыныч эштер. Ул көнне күргән һәр имезүче хатын имезә торган баласын онытыр, вә һәр йөкле хатын йөген вакытсыз төшерер, вә ул көндә кешеләрне исерек күрерсең, алар хәмер эчеп исерек түгел, ләкин Аллаһ газабы катыдыр, куркып гакыллары китәр”.** *(Әл-Хаҗ, 22/1-2).*

Аллаһы Тәгалә теләк-курку һәм Аллаһы затын тирән ихтирам итүне бергә кылды:

إِنَّهُمْ كَانُوا يُسَارِعُونَ فِي الْخَيْرَاتِ وَيَدْعُونَنَا رَغَبًا وَرَهَبًا وَكَانُوا لَنَا خَاشِعِينَ

**“Безнең хозурымызда булган савапка кызыгып һәм куркып дога кылалар иде, һәм Бездән даим куркучы булдылар”.**

*(Әл-Әнбия, 21/90).*

Аллаһы Тәгалә гайбәт сөйләүне, чирканыч рәвештә, кешенең итен ашау белән тиңли:

أَيُحِبُّ أَحَدُكُمْ أَنْ يَأْكُلَ لَحْمَ أَخِيهِ مَيْتًا فَكَرِهْتُمُوهُ وَاتَّقُوا اللَّهَ إِنَّ اللَّهَ تَوَّابٌ رَحِيمٌ

**“Сезнең берәрегез үлгән кардәшенең итен ашауны сөярме? Сез, әлбәттә, аны мәкруһ күрдегез, гайбәт сөйләүне дә шулай**

**мәкруһ күрегез! Аллаһтан куркыгыз, гайбәт эшләреннән тәүбә итегез! Шиксез Аллаһ тәүбә итеп төзәлгән кешеләрне Гафу итүче вә Рәхимле”.** *(Әл-Хуҗурат, 49/12).*

Гакыйдәнең күңел-калебләрдә нык урнашу өчен, укытучыга Коръән Кәримдәге кешегә хас булган хисләрне сөйләүче аятьләргә ишарә итү, аларны ачыклау кирәк. Нәтиҗәдә, укучыларның тотышларына, яшәү рәвешләренә көн саен, тормышта булган бөтен эшләрдә дә дөрес юлга юнәлтү була, чөнки өйдәге, урамдагы тормыш, мәктәптәге көндәлек тормыш, аралашу, дин, гарәп теле дәресләре, хисап, татар теле, рус теле, тарих һ.б. дәресләр укучыларның калебләрендә нык урнашкан гакыйдәгә нигезләнгән. Ислам тәрбиясе бердәм булу сәбәпле, теоретик мәглүматларны урнаштыру җиңел була, чөнки ул укучыларның үз-үзләрен тотышлары, яшәү рәвешләре, тормышларында булган вакыйгалар һәм проблемалар белән нык бәйләнештә тора.

Өченчесе: гамәл тарафлары.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә иман белән изге гамәлне бергә тоташтырып әйтте:

إِنَّ الَّذِينَ آمَنُوا وَعَمِلُوا الصَّالِحَاتِ كَانَتْ لَهُمْ جَنَّاتُ الْفِرْدَوْسِ نُزُلًا خَالِدِينَ فِيهَا لَا

يَبْغُونَ عَنْهَا حِوَلًا

**“Дөреслектә, иман китереп Коръән юлы белән изге гамәлләр кылган хак мөэминнәргә Фирдәүс Җәннәте иңә торган кунак йорты булыр. Ул Җәннәттә мәңге булганнары хәлдә аннан башка урынга күчүне теләмәсләр”.** *(Әл-Кәһф, 18/107-108).*

Гакыйдә – ул аңа шәригать нигезләнә торган фундамент. Шәригать гакыйдәсез килми, гакыйдәдән (иманнан) изге гамәл туган шикелле. Алар икесе ике нәрсә булса да, берберсе белән нык бәйләнештә.

Ислам гакыйдәсен һәм аның нигезләре үз эченә Аллаһы Тәгаләгә, Аның фәрештәләренә, китапларына, пәйгамбәрләргә, Ахирәт көненә, тәкъдирнең яхшысы да

яманы да Аллаһтан икәненә, үлгәннән соң янә терелүгә иман китерүне ала. Ислам гакыйдәсен гамәли рәвештә үтәү - ул укучыларның күңелләрендә гакыйдәнең нык урнашуына алып бару һәм башка Ислам тәрбиясе дәресләре белән гамәли яктан бәйле булуы (Коръән Кәрим, гыйбадәт, әхлак, сира, хәдис), тормышта Аллаһы Тәгалә өчен шәригать хөкемнәрен үтәү.

Иманның нык һәм төзек булуы, рухи бөеклеккә менүе өчен һәм кешенең шуның белән Аллаһы Тәгалә вәгъдә иткән мәрхәмәте һәм мәңге бетмәс нигъмәтләренә ирешүе өчен, кешегә өстеңдәге бурычларын үтәү һәм изге гамәлләрне кылу кирәк. Күңелдә генә булган, ә гамәлләрдә үзенең чагылышын тапмаган иман җимеш бирми торган агачка охшап кала. Калебләребездә кабынган иман нуры сүнмәсен, ә көчәйсен өчен гыйбадәт кылу кирәк. Әгәр кеше, иманга кергән нәрсәләрне күңеле белән генә кабул итеп, Аллаһы Тәгалә кушканнарын үтәмәсә, тыйганнарыннан тыелмаса, Аллаһы Тәгаләгә булган ихласлык, чын күңелдән бирелгәнлек һәм тугрылык, Аллаһы Тәгалә белән кеше арасындагы булган элемтә тора-бара көчсезләнеп, бөтенләй юкка чыгарга мөмкин. Бу гамәлләре белән кеше Аллаһы Тәгаләнең ачуына дучар булырга һәм газап ителергә мөмкин. Менә шул сәбәпле дә, гыйбадәт итү һәм изге гамәлләрне башкару кешенең иманын көчле һәм какшамас кыла, Тәмуг утыннан котылуга һәм Аллаһы Тәгалә вәгъдә кылган нигъмәтләргә лаек булуга ярдәм итәләр.

Ислам тәрбиясен алып баручы укытучыга бигрәк тә, мәктәп (мәчет) укытучыларының бөтенесенә, эшләүче һәр хезмәткәргә, гомум рәвештә укучыларга сүздә, гамәлдә яхшы үрнәк күрсәтү тиеш була. (Ислам тәрбиясе дәресләреннән алганнарны калеб һәм гамәлләрендә нык урнашып, калган тормышларында да дәвам итеп, тагы да яхшыртулары, башкаларга да үрнәк булып, Аллаһы Тәгаләнең әманәтен аларга ирештерүләре өчен).

## 2.4 Ислам гакыйдәсен укыту максатлары

Аерым максатлар һәрбер дәрескә, темасына карап, куела:

1) Укучыларның күңелләренә дөрес Ислам гакыйдәсен урнаштыру, укучының сәламәт гакыйдә белән үсүе өчен Аллаһы Тәгалә Бер, Аннан башка һичнинди иләһ юк, тулы сыйфатлар белән сыйфатланган, күркәм исемнәр белән исемләнгән, бөтен кимчелек сыйфатлардан пакъ булган, дип иман китерүе.

2) Аллаһы Тәгаләнең Затындагы, мәхлүкатларындагы Олуг Иләһлык тарафларын аңлату.

3) Укучыларның күңелләрен хорафатлардан, хаталы фикерләрдән арындырып, Аллаһы Тәгаләгә, Аның әмерләрен үтәүгә һәм тыйганнарыннан ерак торуны күңелләрендә урнаштыру.

4) Иманның калган рөкеннәренә иман китерү: Рәсүлләрне җибәргән икәненә, Аның фәрештәләренә, күктән иңгән Китапларына, Ахирәт тормышына, кабердәге хәлләргә, Кыямәт көненә һәм анда булачак хисап, гамәл дәфтәрләрен бирү, савап яисә гөнаһ язылу, Сират күперен кичү, Җәннәттәге нигъмәтләр, Җәһәннәмдәге газаплар, тәкъдирнең яхшысы да яманы да Аллаһтан икәненә, үлгәннән соң янә терелүгә.

5) Коръән Кәримдә булган нәрсәләр белән нык тоташу, Пәйгамбәр с.г.в.с. нең сүзләре, гамәлләре белән яшәргә тырышу.

6) Исламны сөю, көчле хис һәм тирән вөҗдан белән аны олуглау, аннан канәгать булу, укучыларның шик һәм шөбһәләрен бетерү.

## 2.5 Ислам гакыйдәсен укыту методлары

1. Гакыйдәне укытудагы гомум нигезләр.

а) Укучының дәрес барышында уңай халәттә булуы: укучыларга юнәлеш бирү, тәэсирләндерү, сораулар кую,

тикшерүгә күңелләрен салу, мөмкин булган хәтле нәсыйхәт бирү, уку, сөйләү;

ә) укытучының дәресне үз эченә икенче дәрәҗәдәге төрле фикерләрне алган гомум фикер белән алып баруы (ягъни, дәрес темасының төп фикерен карап чыгуы, соңыннан аларны өлешләп тикшерүе, ә дәреснең ахырында тирән мәсъәләләргә керешүе);

б) гакыйдә дәресләрендә матди һәм иҗтимагый нигезләрне куллануы;

в) гакыйдәне Коръән Кәрим, Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең сөннәте һәм тормышы, сәхабәләрнең тормышы, укучыларның яшәешләре белән бәйләве.

2. Гакыйдә дәресенең барыш адымнары.

а) Укытучы дәрескә кадәр уку китабына мөрәҗәгать итүе. Дәрестәге теманы тирәнрәк һәм киңрәк бирүе өчен мәктәптә (мәчеттә) укытыла торган китаптан тыш өстәмә китапларга да мөрәҗәгать итсә яхшырак була. Дәрес темасын аңлатканда, укучылар теманың өлешләре белән танышулары, яшәгән мохиттәге вакыйгалар хакында фикерләүләре өчен уңышлы була.

ә) Кереш: дәреснең максатын, темасын билгеләү, укучыларда темага карата кызыксыну уяту, аңа булган ихтыяҗларын хисләндерү, шул хакта фикерләрен белү. Ул түбәндәге юлларның берсе белән тормышка ашырыла:

- әүвәлге дәрестә (дәресләрдә) үткән темаларны искә төшерү (әгәр дәреснең темасы ул тема (темалар) белән бәйле булса);

- дәреснең темасын ача торган проблема (сорау) кую;

- дәрес темасын берәр дини мөнәсәбәт яисә табигать күренеше яки җәмгыятьтәге (халык арасындагы) берәр күренеш белән бәйләү.

б) Укучылар белән дәрес темасын һәм аның чикләрен билгеләүгә җиткәч, укытучы тикшерүне өлешләргә бүлә яисә теманы кечкенә темаларга бүлеп, сорау һәм җавап

юлы белән кечерәйтә, һәрбер өлешкә туры килгән исем биреп, аларны сыйныф тактасына язып куя (план кебек).

в) Дәрес темасына туры килгән Коръән Кәрим аятьләре, Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең хәдис-шәрифләре яисә Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең тормыш юлы һәм табигатьтәге төрле хәлләр күзәтеп торган нәрсәләрне китерә (галәмдәге күренешләр яисә җәмгыятьтәге вакыйгалар һ.б.).

г) Укучыларга төрле сораулар биреп, мөгаллим дәрес темасын аңлау дәрәҗәләрен тикшерә.

д) Дәреслектә билгеләнгән теманы укыганнан соң андагы мәгънәләргә, аерым сүзләргә һәм гыйбарәләргә аңлатма бирелсә яхшы була.

## Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр:

1. Гакыйдә сүзнең телдәге һәм шәригатьтәге аңлатмаларын китерегез.

2. Ислам гакыйдәсенең рөкеннәре (хакыйкатьләре) нидән гыйбарәт? Шуларны, аңлатмалары белән, әйтеп чыгыгыз.

3. Гакыйдәнең кешенең һәм җәмгыятьнең тормышына булган тәэсире нинди була? Аларны аңлатып бирегез.

4. Кешедә иман тәрбияләүдә Коръән Кәримдәге һәм Пәйгамбәребез с.г.в.с. сөннәтендәге методлар нинди ул? Шул методлдарны китерегез.

5. Иманны тәрбияләүдәге акыл, вөҗдан һәм гамәл тарафларындагы нигезләрне әйтеп чыгыгыз.

6. Ислам гакыйдәсен укыту максатлары һәм методлары нидән гыйбарәт? Шуларны санап чыгыгыз.

## Кушымталар

***Кереш бүлек***

1. Ислам нигезләре. Гакыйдәнең аңлатмасы. Гакыйдәнең рөкеннәре. Гакыйдәнең әһәмияте һәм аның кеше тормышына тәэсире.

2. Фитрый иман. Иман һәм Ислам.

3. Иман кәлимәләре (сүзләре): «Кәлимәтү тайибәтүн»; «Кәлимәтү шәһадәти»; «Кәлимәтү тәүхид»; «Кәлимәтү раддил-күфри»; «Кәлимәтү истигъфар»; «Кәлимәтү тәмҗид»; «Иман мүҗмәл»; «Иман муфәссал».

***Төп бүлек***

1. Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләгә иман китерү:

- Аллаһы Тәгаләнең барлыгына иман китерү;
- Аллаһы Тәгаләнең исем-сыйфатларына иман китерү.

2. Фәрештәләргә иман китерү:

а) Фәрештәләргә иман китерү – гакыйдә нигезләренең бер өлеше; ә) фәрештәләрнең хакыйкате һәм сыйфатлары; б) фәрештәләрнең төрләре.

- Җеннәрнең барлыгына иман китерү; җеннәрнең хакыйкате.

3. Пәйгамбәрләргә (нәби һәм рәсүлләргә) иман китерү:

а) Нәби һәм рәсүлнең аермасы;

ә) пәйгамбәрләрнең вазифалары;

б) Мөхәммәд с.г.в.с. нең Пәйгамбәр икәнлегенә һәм аннан әүвәл җибәрелгән пәйгамбәрләргә иман китерү;

в) пәйгамбәрләрнең саннары һәм исемнәре;

г) пәйгамбәрләрнең сыйфатлары.

4. Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләнең Китапларына иман китерү:

а) Коръән Кәримгә иман китерү;

ә) Коръән Кәримнән әүвәл иңгән Иләһи Китапларга иман китерү;

б) Коръәннең үзеннән әүвәлге Китаплардан аермалары.

5. Ахирәт көненә иман китерү: Ахирәт көненә иман китерү – гакыйдә нигезләренең бер өлеше; үлем; кабердә сорау алыну һәм андагы хәлләр (газап яки нигъмәт); Ахирәт көне галәмәтләре; Ахирәт көненең башлануы; Бәгыс; Мәхшәр мәйданы; Әл-Хауз; Мизан; Сыйрат; Җәннәт һәм Җәһәннәм.

6. Тәкъдиргә иман китерү.

7. Олуг гөнаһлар. Гөнаһның иманга тәэсире. Гөнаһның җәзасын бетерүче сәбәпләр (Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән).

8. Кешенең бу дөньяда яшәвенең максаты.

*Гакыйдә дәресен уздыру үрнәге*

**Тема: Аллаһыны ярату**[19]

**Максат: Аллаһының барлыгына һәм берлегенә ышандыру.**

***Дәрес барышы***

***I. Өйгә бирелгән эшне тикшерү.***

Үзбәя.

***II. Уку мәсъәләсен кую.***

Мин сезгә татар шагыйре Габдулла Тукайның бер шигырен укыйм.

Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң Аның, һәрчак таян син Аллага!
Йә, Аллаһ, күрсәт, диген, ошбу җиһанда якты юл;
Ул – Рәхимле, әткәң-әнкәңнән дә күп Шәфкатьле Ул!

Төркемнәрдә тикшерегез

- Бу шигырьдә кем турында сүз бара?
- Аллаһы Тәгаләбез турында.
- Шагыйрь Аның нинди сыйфатларын билгеләп үтә?
- Рәхмәтенең киңлеген, Рәхимлелеген.

[19] Дәреснең үрнәге алынды: Казыйханов В. Иман дәресләре. Мәктәп балалары өчен уку әсбабы. 1 нче кисәк. Казан: «Дом печати" нәшрияты, 2003. 13-17 битләр.

- Димәк, бүгенге дәрестә сүз кем турында барачак?

- Аллаһы Тәгалә турында.

***III. Уку мәсьәләсен чишү.***

1 нче бирем.

- Кем Ул Аллаһы Тәгалә?

- Без күргән һәм күрмәгән, без белгән һәм белмәгән, без ишеткән һәм ишетмәгән барлык мәхлукатны, барлык затларны юктан Бар итүче.

Үзбәя.

2 нче бирем.

- Югарыда укылган шигырьдә шагыйрь Аллаһыны әтиәнидән дә өстенрәк, "күп Шәфкатьлерәк" дип раслый. Ни өчен?

- Һәр кеше өчен әти-әнисе иң күркәм, иң кадерле, иң хөрмәтле зат санала. Шулай булса да, аларны да дөньяга китерүче Зат бар, Ул – Аллаһыбыз.

- Димәк, Аннан да өстенрәк берәр нәрсә бармы дөньяда?

- Юк, әлбәттә.

Үзбәя.

3 нче бирем.

- Түбәндәге хәдисне ничек аңлыйсыз?

"Кем Аллаһыдан курыкмый, шуның теле хата сөйләүдән котыла алмый (гайбәт сата, үзен мактый, башкаларны хурлый, кимсетә, рәнҗетә һ.б.); кем Аллаһ каршына килеп басачагыннан (хисап бирү өчен) курыкмый, шуның күңеле хәрам белән шөбһәдән котыла алмый (ярамаган эшләр – исерү, тәмәке тарту, кешеләр турында ялган сөйләү һ.б.); кем халыктан күңелен өзми, шул комсызлыктан котыла алмый (халык алдында үзен җаваплы тотмаганның нәфесе чамасыз була); кем үз гамәленә сакчы була алмый, шул риядан котыла алмый (кем эшләнәсе эшләрен уйлап бетерми, шул икейөзлелек күрсәтә, берне сөйли, икенчене эшли һ.б.); кем күңелен бөтен тотуда Аллаһының ярдәменә таянмый, шул көнчелектән котыла алмый (нәфесен тыя,

акылын өстен чыгара алмый һ.б.); кем белеме һәм гамәле белән үзеннән өстен торганнарга карамый, шул минминлектән котыла алмый (кеше фикере белән хисаплашмый торган кеше уңышка ирешә алмый, ул тормыштан артта кала, кешеләр андыйлар белән аралашмыйлар, читләшәләр һ.б.)".

Үзбәя.

4 нче бирем.

- Аллаһы Тәгалә бар кешегә мәрхәмәтлеме?

- Әйе, ләкин кайбер кешеләр Аның мәрхәмәтеннән мәхрүм булачак.

- Алар кемнәр?

- Кем Аңа гыйбадәт кылмый, ураза тотмый, зәкят бирми, көче җитеп тә хаҗга бармый һәм башка игелекле эшләрне эшләми шуларны Аллаһ Ахирәт көнендә газапка тартырга мөмкин.

Үзбәя.

5 нче бирем.

- Безнең Аллаһы Тәгаләгә карата нинди бурычларыбыз бар?

а) Аллаһының Барлыгына һәм Берлегенә ышану;

б) Аллаһ кушкан эшләрне эшләү;

в) Аллаһ тыйган эшләрдән тыелу;

г) Аллаһ биргән хисапсыз нигъмәтләргә шөкрана кылу;

д) Аллаһыны һәр нәрсәдән өстен күреп, Аны сөю хисен күңелгә урнаштыру;

е) Аллаһыга чын күңелдән гыйбадәт кылу;

ж) Аллаһыга карата һәрвакыт тәрбияле, әдәпле булу; Аның күркәм исемнәрен хөрмәт белән искә алу.

Үзбәя.

6 нче бирем.

- Әгәр түбәндәгеләргә акылың белән дә, күңелең белән дә инансаң, син Аллаһыны таныйсың, Аның Барлыгына да Берлегенә дә ышанасың:

1. Аллаһы Тәгалә Бар һәм Бер, Үзеннән башкага һич мохтаҗ түгел. Аның һич мисалы, охшашы һәм тиңдәше юк, Ул бөтен кимчелек сыйфатлардан пакъ. Мәңге терек, әүвәле һәм ахыры юк, дип.

2. Аллаһ безнең кебек җан белән түгел, бәлки Үзенә генә хас сыйфат белән Теректер.

3. Аллаһ безнең кебек акыл, зиһен һәм өйрәнеп түгел, бәлки Затына хас сыйфат белән кирәк зур, кирәк кечкенә булсын, җирдә һәм күктә булган нәрсәләрнең һәркайсын Белә.

4. Галәмдәге бөтен нәрсә Аллаһының Кодрәте белән бар булган, Аның һәрнәрсәгә көче җитә, Ул һичкемнең ярдәменә мохтаҗ түгел.

5. Аллаһ безнең кебек гәүдә кодрәте белән түгел, бәлки Үзенең Затына хас сыйфат белән Көчле.

6. Аллаһ безнең кебек колак белән түгел, бәлки Затына хас сыйфат белән кирәк каты, кирәк акрын булсын, һәр авызны Ишетә.

7. Аллаһ һәрнәрсәне, кирәк яктыда, кирәк караңгыда булсын, кирәк эре, кирәк вак булсын, һәммәсен дә безнең кебек күз белән түгел, бәлки Затына хас сыйфат белән Күреп тора.

8. Аллаһ һәрнәрсәне Үзенең ихтыяры, Үзенең теләве белән бар кыла һәм Үзенең теләве белән юк итә.

9. Аллаһы Тәгаләнең сөйләве безнең кебек тел белән түгел, бәлки Үзенең Затына хас сыйфат белән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмгә иңдерелгән Коръән Аллаһы Тәгаләнең сүзе һәм башка пәйгамбәрләргә иңдерелгән китаплар да Аның сүзләре.

Үзбәя.

7 нче бирем.

- Аллаһыга нинди исемнәр белән мөрәҗәгать итү дөрес була икән?

- Аллаһы Тәгаләнең 99 гүзәл исеме бар, шуларның кайсы белән мөрәҗәгать итсәгез дә, Ул Ишетә.

Үзбәя.

8 нче бирем.

- Дөньяда яшәүнең мәгънәсе нидә?
- Аллаһыны тану һәм Ул кушканнарны үтәүдә.
- Аллаһыны ярату төшенчәсен ничек аңлыйсыз?
- Аңа буйсыну.

Үзбәя.

***IV. Дәресне йомгаклау, укучыларның эчке кичерешләре белән танышу.***

Дәрестә сүз кем турында барды? Дәрестә нинди фикерне үзләштердегез?

Дәрес өчен үзбәя.

***V. Өйгә эш.***

Дәреснең эчтәлеген әти-әниләрегезгә сөйләп бирегез.

*Гакыйдә дәресе үрнәге*

***Коръән һәм кешелек тарихы (дәрес эшкәртмәсе)***[20]

Бу дөньяда кешене Кеше итеп яшәтүче бер көч бар, ул көчнең исеме - Иман. Иман - ул Аллаһы Тәгаләгә ышану һәм шул ышану аша мәңгелек бәхеткә ирешү.

Хәзерге җәмгыятьтә барлыкка килгән әхлаксызлык, наркомания, эчкечелек кебек проблемаларның төп сәбәбе - кешеләрдә иманның җитешмәвеннән. Һәр гамәле өчен Аллаһ каршында җавап тотачагына ышанган кеше начар эшләрдән тыела, яхшылыклар кылырга тырыша. Ә иманлы шәхесне тәрбияләү балачактан ук башланган очракта гына яхшы нәтиҗәләр бирә. Кызганыч ки, республикабыз мәктәпләрендә Ислам дине дәресләре укытуга игътибар бирелми. Әлеге бушлыкны тутыруга, ягъни, укучыларның Ислам турындагы мәгълүматка булган ихтыяҗын

[20] Мөхәммәтшина Алсу Вәгыйз кызы. Коръән һәм кешелек тарихы (дәрес эшкәртмәсе). Дәүләт тарих, архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы “Казан Кремле.” Татарстан Республикасы Милли музее. Казан, 2002.

канәгатьләндерүгә мәчетләр дә үз өлешләрен кертә алалар.

Бу дәрес эшкәртмәсе урта һәм югары сыйныф укучыларының дини күзаллауларын киңәйтү, Ислам дине турында булган мәгълүматларын билгеле бер тәртипкә салуда ярдәмлек буларак тәкъдим ителә.

Файдаланыла торган китаплар - Коръән һәм аның тәфсирләре.

Дәрес ярымуен рәвешендә уза: укучылар укытучы ярдәме белән, Коръәндәге хәбәрләргә нигезләнеп, кешелек тарихы схемасын төзиләр. Схеманы төзү барышында аларга галәм, табигать, беренче кешенең барлыкка килүе, элек яшәгән кавемнәр, кеше үлгәннән соңгы тормыш турында мәгълүмат бирелә, «пәйгамбәр», «фәрештә», «Илаһи Китап», «Кыямәт көне» кебек төшенчәләр аңлатыла.

Дәрес ахырында, төзелгән схемага карап, укучыларның үзләренә нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирелә.

Схема төзү өчен кирәкле әсбаплар:

1) 1,5 м х 0,60 см зурлыгында ак кәгазь белән тышланган планшет. Аның уртасына горизонталь сызык сызылган.

2) 7,0 см х 5,0 см зурлыгында картоннан кисеп ясалган 18 карточка:

«Адәм галәйһиссәләм», «Хава радыйАллаһү гәнһү», «Җәбраил галәйһиссәләм», «Уң як фәрештә», «Сул як фәрештә», «Иблис», «Идрис галәйһиссәләм», «Шис галәйһиссәләм», «Нух галәйһиссәләм», «һуд галәйһиссәләм», «Салих галәйһиссәләм», «Ибраһим галәйһиссәләм», «Лут галәйһиссәләм», «Муса галәйһиссәләм», «Давыт галәйһиссәләм», «Гайсә галәйһиссәләм», «Мөхәммәд галәйһиссәләм», «Без».

3) 11 см х 8 см зурлыгында 3 карточка: «Кыямәт көне», «Җәннәт» (яшел төскә буялган), «Җәһәннәм» (кызыл төскә буялган).

4) Картоннан 2 ук - берсе яшел, берсе кызыл төстә.

5) Картоннан кояш, ай, йолдыз, кораб рәсемнәре.

6) 2,5 см х 7,5 см зурлыгында 3 карточка: «акыл», «ихтыяр», «инстинктлар» дип язылган.

7) 11,0см х 15,0 см зурлыгында 14 карточка, аларга Коръәннән аятьләр язылган (аятьләрнең эчтәлеге текстта бирелә).

8) 4,0 см х 4,0 см зурлыгында «сухуф» дип язылган 4 карточка.

9) 5,0 см х 5,0 см зурлыгында 4 карточка: «Тәүрат», «Зәбур», «Инҗил», «Коръән». Әлеге карточкаларны китап рәвешендә ясау тагын да отышлырак.

Дәрес темасы буенча тәкъдим ителгән әдәбият белән танышу Ислам динен тирәнрәк өйрәнергә мөмкинлек бирә.

***Дәреснең барышы***

Аудитория алдында өстәл һәм планшет. Өстәлдә Коръән һәм аның тәфсирләре; планшет вертикаль рәвештә урнаштырылган. Укучылар планшет янына иркен чыгып йөри алырлык итеп урындыкларга урнашалар.

Алып баручы: Кадерле дуслар!

Сезгә тарих дәресләреннән мәгълүм: Идел буе Болгар дәүләтен төзеп яшәгән борынгы бабаларыбыз 922нче елда рәсми рәвештә Ислам динен кабул итәләр. 1100 ел буе әбибабаларыбыз яшәеш - көнкүрешләрен Ислам шәригате кануннары буенча алып барганнар, һәрбер мөселман өенең иң түрендә кадерләп саклана торган китап - Коръәни Кәрим булган.

Ни өчен соң халкыбыз нәкъ менә Ислам динен сайлаган, Коръәнне Изге Китап дип зурлаган? Әйдәгез, болгар мөселманнары кебек фикер йөртергә тырышып карыйк. Алар, әлбәттә, үзләрен әйләндереп алган табигатьне, тереклекне, иксез-чиксез галәм киңлекләрен күзәткәннәр һәм күргәннәр: бу дөньяда бер нәрсә дә мәңгелек түгел - үсемлекләр үсәләр, күпмедер вакыт узгач, корыйлар, череп, таркалып юкка чыгалар. Кешеләр һәм башка тере организмнар да туалар, яшиләр һәм үләләр. Хәтта таулар

да җимерелеп тигезлеккә әйләнәләр. Шулай ук без яши торган Җир планетасы һәм галәм да мәңгелек түгел (күк йөзендә яңа йолдызлар кабына, кайберләре сүнеп югала).

Шулай итеп, кеше, галәм, тереклекнең башлангыч һәм бетү нокталары бар. Көнкүрештә файдалана торган әйберләргә кеше дә башлангыч бирә ала, ягъни, барлыкка китерә (мәсәлән, эш кораллары ясый, йортлар төзи, ипи пешерә, киемнәр тегә һ.б.).

Ә менә галәмгә, табигатькә һәм тереклеккә башлангыч бирү өчен (барлыкка китерү өчен) чиксез көчкә ия булырга кирәк. Ә андый көчкә ия зат берәү генә, ул - Аллаһы Тәгалә. Аллаһ аларга башлангыч биреп кенә калмый, ә искиткеч тәртип белән яшәтә дә.

Мөгаен, менә шуларның барсын да күреп фикерләгәннән соң, болгарлар Аллаһы Тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә ышанганнардыр һәм үзләренең гыйбадәтләрен бары тик Аллаһыга гына багышлаганнардыр. Бу инде Ислам динен кабул итүне, мөселман булуны аңлата.

Ислам үзәкләреннән Болгар җирләренә китерелгән, мөселманнарның изге Китабы Коръәнне укып, болгар бабаларыбыз дөнья, яшәеш, дин турында зур гыйлемнәргә ия булганнар. Чөнки Коръәндә дөньяның яралтылуы, беренче кеше барлыкка килүдән алып, бу фани дөньяның бетүенә һәм аннан соңгы тормышка кадәр мәгълүмат бар. Үзе барлыкка китерүче булганга, Аллаһка әлеге вакыйгалар яхшы мәгълүм.

Коръән ул үзе гарәп телендәге Китап, ләкин аның сүрә-аятьләренең мәгънәләре төрле телләргә, шул исәптән татар һәм рус телләренә дә тәрҗемә ителгән (Коръәннең татар һәм рус телләрендәге тәфсирләрен күрсәтү).

Бүген без бергәләп каршыбызда торган шушы ак планшетта Аллаһы Тәгалә Коръән аша безгә җиткергән хәбәрләр буенча кешелек тарихы схемасын төзербез. Аны төзи башлаганчы, мин сезнең һәрберегезгә карточкалар

таратам, ә сез анда язылганнарны игътибар белән укыгыз. Вакыты җиткәч, сезгә ул карточкаларның кайберләрен шушы планшетка беркетергә, кайберләрен кычкырып укырга кирәк булыр (Алып баручы үзендә дә берничә карточка калдыра).

Ә хәзер, әйдәгез, схеманы төзи башлыйбыз.

Күз алдына да китерү авыр: бик күп миллион еллар элек кешеләр дә, Җир дә, кояш та, йолдызлар да әле булмыйча, алар урынын менә шушы ак планшет кебек бушлык кына алып торган. Бары тик бер зат кына һәрвакыт булган, бар һәм булачак - Ул - Аллаһы Тәгалә. Абсолют акылга һәм абсолют көчкә ия булган Аллаһ көннәрдән бер көнне Җирне һәм галәмне барлыкка китерә. Бу турыда ул Коръәннең күп кенә аятьләрендә безгә хәбәр итә. (Бер укучы «Каф» сүренең 38 нче аятен һәм «Фуссиләт» сүрәсенең 9-12 нче аятьләрен укый: «Без Җирне вә күкләрне вә аларның араларында булган нәрсәләрне алты көндә төзедек, һәм безгә мәшәкать вә авырлык ирешмәде». («Каф»/38). Син аларга әйт: «Сез ике көндә Җирне төзеп тәмам иткән Аллаһыга иман китермисезме? Вә Аңа тиңдәшләр кыласызмы? Аллаһ - галәмнәрнең Раббысыдыр. Вә Ул Җир өстенә зур-зур таулар кылды вә ул җирнең файдаларын күп кылды, вә төгәл дүрт көн эчендә һәркемнең ихтыяҗынча ризыклар тәкъдир итте. Соңрак күкне халык кылырга теләде, ул вакытта күк төтен иде; һәм Җиргә, күкләргә әмер итте: «Теләсәгез дә, теләмәсәгез дә, Миңа буйсыныгыз!» Алар әйттеләр: «Теләп, үз ихтыярыбыз белән буйсынабыз!». Шулай итеп, аларны ике көндә җиде кат күк рәвешендә яралтты вә һәр күккә үз вазыйфасын йөкләде, һәм Без якын галәмне йолдызлар белән бизәдек вә саклау белән тәэмин иттек. Бу гамәлләр Җиңелмәс, Кодрәтле Аллаһның тәкъдире». («Фуссиләт»/ 9-12).

Укучылар кояш, ай һәм йолдызлар сурәтләнгән карточкаларны планшетның өске өлешенә пластилин яки башка җайланма белән ябыштыралар.

Алып баручы: Коръәндәге әлеге хәбәрләрне бүгенге фән тулысынча раслады: элек бар нәрсә газ хәлендә булган, фәкать аннары гына газ мөхитендәге атом һәм төш реакцияләре нәтиҗәсендә, кайнар плазма суынганнан соң төрле формалар алган. Безнең Кояш системасы да шул бүленү нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Билгеле булганча, Җирдә 100 дән артык химик элемент бар, аларның күбесе Кояшта да, Айда да очрый. Моннан инде, Коръәндә әйтелгәнчә, дөньядагы бар нәрсәнең дә башлангычы бер дигән фикер аңлашыла.

Ә кешелек дөньясы үзенең башлангычын беренче кешедән - Адәмнән алган. (Алып баручы планшетның сул ягына уртага «Адәм» г.с. дип язылган карточканы беркетә).

«Бу турында «Әл-Хиҗр» сүрәсенең 28 нче, «Әл-Бәкара» сүрәсенең 30-39 нче аятьләрендә әйтелә.

(Алып баручы Коръән тәфсиреннән әлеге аятьләрне укый: «Аллаһ фәрештәләргә әйтте: «Мин яңгырап торган (фаянс кебек) балчыктан, аңа рәвеш биреп, бер кеше яралтам. Аңа рәвеш биреп, Үземнән җан өргәч, сез аңа сәҗдә итәрсез». Фәрештәләр барысы да шундук сәҗдә иттеләр» (Әл-Хиҗр/28). Раббың фәрештәләргә әйтте: «Мин Җиргә Адәмне башлык, хуҗа итеп куячакмын. Аллаһ Адәмгә дөньядагы бөтен исемнәрне өйрәтте». (Әл- Бәкара, 30-31).

Алып баручы: Бу мәсьәләдә дә фән һәм дин бер-берсен куәтлиләр. Кешенең килеп чыгуын ачыклау максатыннан фәнни тикшеренүләр үткәргән галимнәрнең күпчелеге бер кешедән бөтен кешелек ыруы килеп чыккан, дигән фикергә килделәр.

Аллаһы Тәгалә Адәмгә иптәш, ярдәмче, күңелен ял иттерүче итеп беренче хатын-кызны, ягъни Хаваны барлыкка китерә.

(Бер укучы планшетка «Хава р.г.» дигән карточканы беркетә, икенче укучы «Рум» сүрәсенең 30нчы аятен укый: «Аллаһның кодрәтенә дәлилдер сезнең өчен Аллаһның

үзегездән хатыннар яратмаклыгы, чөнки Хава Адәмнең кабыргасыннан халык ителде, ул хатыннар белән дус булып бергә яшәвегез өчен»).

Алып баручы: Аллаһы Тәгалә Адәм белән Хавага файдаланырга бөтен Җир шарын тапшыра. Шулай ук, Ул кешеләргә инстинктлар (шул исәптән бик әһәмиятле булган табыну инстинкты да), акыл һәм ихтыяр бирә.

(Алып баручы әлеге сүзләр язылган карточкаларны «Адәм г.с.» һәм «Хава р.г.» дип язылган карточкалар өстенә беркетә). Бу урында укучылар белән «инстинкт», «акыл», «ихтыяр» төшенчәләре турында әңгәмә үткәрү урынлы).

Алып баручы: Бу дөнья беренче кешеләр өчен әле яңа урын булганлыктан, алар Җирдә ничек дөрес итеп яшәргә кирәклеген белмәгәннәр. Ләкин Мәрхәмәтле, Рәхимле Аллаһ кешеләрне билгесезлектә калдырмаган, Адәм аркылы, аларга хак юлны күрсәтүче, дөрес яшәргә өйрәтүче хәбәрләрен җибәргән һәм акылларын эшләтеп уйларга - фикерләргә, ихтыярларын файдаланып әлеге күрсәтмәләрне үтәргә чакырган.

Аллаһы Тәгаләдән хәбәрләр кабул итеп аларны башка кешеләргә җиткерүчеләрне пәйгамбәрләр дип атыйлар.

Димәк, Адәм беренче кеше генә түгел беренче пәйгамбәр дә булган.

Аллаһтан хәбәрләр пәйгамбәрләргә ничек килеп ирешә соң?

Бу дөньяда кеше акылы аңлатып бирә алмый торган бик күп серләр, могҗизалар бар. Шуларның берсе - кеше күзенә күренми торган затлар - фәрештәләрнең булуы. Алар нурдан яралтылганнар һәм яшәү рәвешләре дә кешеләрнекеннән нык аерыла. Алар һәрвакыт Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылу һәм Аның әмерләрен үтәү белән мәшгульләр. Һәрбер төр фәрештәләрнең галәмдә үз эшләре бар. Ә менә Җәбраил исемле фәрештәнең төп эше - Аллаһының хәбәрләрен пәйгамбәрләргә тапшыру.

Менә шушы фәрештә Адәм г.с. гә Аллаһы Тәгаләдән 21 бит (ягъни, «сәхифә», «сухуф») хәбәр алып килә.

(Берукучы «Җәбраил г.с.» дигән карточканы планшетның югары өлешенә, икенчесе, «сухуф» дип язылганын, «Адәм г.с.» карточкасы өстенә беркетәләр).

Алып баручы: Пәйгамбәрнең төп вазыйфасы - Аллаһ җибәргән хәбәрләргә нигезләнеп, кешеләргә Аллаһының берлеген, барлык галәмнең Хуҗасы икәнлеген, Аңа гына гыйбадәт кылырга, Аның әмерләрен үтәргә кирәклеген төшендерү; барлык кешеләрнең дә Аллаһ каршына кире кайтачакларын, Аның әмерләрен үтәүчеләргә күп нигъмәтләр - бүләкләр, ә үтәмәүчеләргә каты җәзалар булачагын аңлату.

Аллаһы Тәгалә кешенең уң һәм сул якларына Үзенең әмерләрен үтәвен - үтәмәвен исәпкә алып баручы фәрештәләр билгеләгән. Коръәннең «Каф» сүрәсе, 17 нче аятендә бу турыда әйтелгән.

(Бер укучы әлеге аятьне укый: «Адәмнең уң ягында һәм сул ягында гамәлләрен язып баручы ике фәрештә бар». Икенче укучы «Адәм г.с.» карточкасының уң һәм сул якларына «уң як фәрештә», «сул як фәрештә» дип язылган карточкалар беркетә).

Алып баручы: Югарыда искә алынган затлардан тыш, Аллаһы Тәгалә җеннәрне һәм Иблисне уттан барлыкка китерә. Ләкин үзенең әмерләрен үтәмәгән өчен Аллаһ Иблисне Үзеннән ерагайта. Шуннан соң, Иблис, үзенә җеннәрдән команда туплый һәм кешеләрне Аллаһ күрсәткән туры юлдан тайпылдырырга тырыша, гөнаһлы эшләр кылырга котырта.

(Бер укучы «Иблис» дип язылган карточканы «Адәм г.с.» карточкасының аскы ягына беркетә. Икенче укучы «Пәрдә» сүрәсенең 12 нче аятен укый: «Аллыһы Тәгалә әйтте: «Әй, Иблис! Мин сиңа Адәмгә сәҗдә кылырга әмер иткәч, сине сәҗдә кылудан нәрсә тыйды?» Иблис әйтте:

«Мин аңардан өстенрәк, чөнки мине уттан яралттың, ә Адәмне - балчыктан. Адәм аркасында мине ерагайтканга күрә, әлбәттә, бәндәләреңне алдап аздырыр өчен туры юлың өстендә утырачакмын»).

Алып баручы: Шулай итеп, Адәм белән Хава Җир планетасында яши башлыйлар. Алардан балалар туып, әкренләп, кешеләрнең саны арта бара.

Күргәнебезчә, һәр кеше каршында ике генә юл бар: берсе - Аллаһ әмерләрен үтәп яшәү, икенчесе - Аллаһ сүзләрен ишетергә теләмичә Иблис коткысына бирелеп яшәү.

(Алып баручы планшетка «Адәм г.с.» карточкасының уң ягына ике ук беркетә: яшел төстәге ук - уртадагы сызыктан өскә, кызыл ук - аска беркетелә).

Алып баручы: Адәм г.с. нең тыңлаучан нәселләре дөрес юлдан бара, әмма пәйгамбәр өйрәтүләреннән баш тарта башлаганнары да була. Кайберәүләр кояшка, айга, йолдызларга, икенче берәүләр үзләре таштан сыннар ясап аларга табына башлыйлар. Төрле-төрле гөнаһлы гореф - гадәтләр барлыкка килә.

Адәм г.с. нең нәселләре бөтен җир шарына сибелгән һәм төрле кавемннәр барлыкка килгән дәвер була бу. Шушы стадиядә Аллаһы Тәгалә кешеләр арасында пәйгамбәрләр үстерә башлый һәм алар аша Китаплар җибәрәп, онытылган сабаклар турында кешелек дөньясының исенә төшереп тора.

Ислам галимнәре әйтүе буенча, Җир шарына барлыгы 124 меңгә якын пәйгамбәр килеп киткән. Шуларның 25-е Коръәндә исемнәре белән әйтелгән. Адәм г.с. не без инде искә алдык. Шулай ук Идрис г.с. белән Шис г.с. не дә Аллаһ пәйгамбәрләр итеп сайлый һәм аларга «сухуфлар» (30 һәм 29 бит) җибәрә.

(Укучылар яки алып баручы «Идрис г.с.» һәм «Шис г.с.» дип язылган карточкаларны уртадагы линия буйлап уң якка таба, ә «сухуф» дип язылган 2 карточканы аларның өске ягына урнаштыралар).

Алып баручы: Пәйгамбәрләрне кайбер халыклар «ялганчы» дип атыйлар, аларга ышанмыйлар һәм үзләренчә яшәүне дәвам итәләр. Андый кавемнәргә Аллаһ җәза җибәрә. Мәсәлән, Нух г.с. үзенең кавемен күп еллар иманга өнди, ләкин алар кабул итмиләр һәм шунлыктан Аллаһның җәзасына дучар булалар.

(Укучыларның берсе «Нух г.с.» дигән карточканы планшетка урнаштыра, икенчесе «Әграф» сүрәсенең 59, 64 аятьләрен укый: «Үз халкына Нухны илче итеп җибәрдек. Ул әйтте: «Аллаһка гыйбадәт кылыгыз! Аннан башка Илаһ юк! Мин сезгә газап килүеннән куркам!» Алар аны ялганчыга чыгардылар. Ләкин без аны һәм аның белән бер көймәдә булганнарны коткардык. Аятьләребезне ялганга чыгарырга маташканнарны суга батырдык. Чөнки алар күңел күзләре сукыр бер халык иде»).

Алып баручы: Күргәнебезчә, әлеге кавем су астында кала, бары тик Нух пәйгамбәргә ияргәннәр генә алдан ясалып куелган зур көймәгә (буе -120 м, иңе -30 м, биеклеге -30 м) утырып исән калалар. Шулай ук Җир шарында ул вакытта яшәгән хайваннардан да корабка берәр пар алына. Су кимегәч, исән калганнар җирдә яңадан тормыш башлап җибәрәләр.

(Бер укучы кораб рәсемен «Нух г.с.» карточкасының өске ягына беркетә).

Алып баручы: Гәд һәм сәмуд кавеме дә үзләренә җибәрелгән пәйгамбәрләр Һуд г.с. һәм Салих г.с. нең иманга чакыруларын кабул итмәгәнгә җәзага дучар булалар.

(Ике укучы «Һуд г.с.» һәм «Салих г.с.» карточкаларын планшетка ябыштыралар).

Алып баручы: Коръәни Кәримдә Аллаһының пәйгамбәре Ибраһим г.с. турында да күп сөйләнә.

(Бер укучы «Ибраһим г.с.» дигән карточканы планшетка беркетә, икенчесе «Пәйгамбәрләр» сүрәсенең 51-54 аятьләрен укый: «Әлегрәк без Ибраһимга туры юлны күрсәттек. Шул вакыт ул атасына һәм кавеменә: «Сез нинди таш сыннарга

табынасыз?» - диде. Алар: «Без ата - бабаларыбызның шуларга табынганнарын күреп үстек», - диделәр! Ибраһим әйтте: «Аталарыгыз да, үзегез дә ялгыш саташу юлында. Сезнең Раббыгыз күкләрнең һәм дә Җирнең Хуҗасы, аларны яралтучы - Аллаһ»).

Алып баручы: Ибраһим г.с. гә дә, Аллаһ, үзенең кавеменә җиткерсен өчен кануннар, «сухуф» (10 бит) җибәрә.

(Алып баручы «Ибраһим г.с.» карточкасының өске ягына «сухуф» дигәнен беркетә).

Алып баручы: Аны юлдан язган кавеме учак ягып утка ыргыта. Ләкин шул вакыт могҗиза була - ут, үзенең яндыру, пешерү үзлеген югалта һәм пәйгамбәр ялкынланып янган учактан исән - сау чыга.

Аллаһы Тәгалә дөрес юлда булганнарга һәрвакыт ярдәм итә.

Ибраһим г.с. нең туганы Лут г.с. дә күрше кавемгә пәйгамбәр итеп җибәрелә. Аның кавеме моңа кадәр күрелмәгән зур гөнаһ - гомосексуализм белән шөгыльләнә һәм пәйгамбәр кисәтүләренә колак салмый. Шуның өчен Аллаһ аларны Җир йөзеннән юк итә.

(Бер укучы «Лут г.с.» дигән карточканы планшетка беркетә, икенчесе «Әл-Әграф» сүрәсенең 80 нче аятен укый: «Лутны үз халкына җибәрдек. Ул әйтте: «Сездән элек яшәгән кавемнәр дә эшләмәгән гөнаһны эшлисезме?» Халкы әйтте: «Лутны илдән куарга кирәк». Без Лутны һәм аңа ышанганнарны коткардык. Калганнарның өсләренә таш яңгыры яудырып һәлак иттек»).

Алып баручы: Вакытлар узган саен Җирдә кешеләр күбәя, зур дәүләтләр барлыкка килә. Аллаһы Тәгалә Үзенең кайбер пәйгамбәрләренә сухуфлар гына түгел, зур Китаплар җибәрә. Шундыйлардан, Муса г.с. гә үзенең кавеменә җиткерү өчен Тәүрат (Тора) иңдерелә.

(Бер укучы «Муса г.с.» дигән, икенчесе «Тәүрат» дигән карточканы планшетка беркетәләр, алып баручы Коръән

тәфсиреннән «Маидә» сүрәсенең 44 нче аятен укый: «Без иңдердек Тәүратны - анын эчендә һидәят дәлилләре, белем яктылыгы бар. Коръән иңгәнче әүвәлге пәйгамбәрләр аның белән хөкем итәрләр»).

Алып баручы: Ә Давыт г.с. Аллаһы Тәгаләдән Зәбурны (Псалтырь Давида) кабул итеп ала.

(Укучылар «Давыт г.с.», «Зәбур» дигән карточкаларны схемага урнаштыралар, ә берсе «Ниса» сүрәсенең 163 нче аятен укый: «Һәм Без Давыдка Зәбур бирдек»),

Алып баручы: Аллаһыдан Гайсә г.с. гә иңгән Китапның исеме «Инҗил» (Евангелие).

(Укучылар «Гайсә г.с.», «Инҗил» дигән карточкаларны планшетка беркетәләр, берсе «Әл-Маидә» сүрәсенең 46 нчы аятен укый: «Мәрьям углы Гайсәне әүвәлге пәйгамбәрләр эзенә иярттек, үзеннән элек иңдерелгән Тәүратны дөресләгән хәлдә һәм аңа Инҗилне бирдек, анда һидаять һәм нур, һәм ул Инҗил элек иңдерелгән Тәүратны дөресләп килде һәм тәкъвалыларга һидаять һәм вәгазь итеп»).

Алып баручы: Аллаһының барлык Китаплары да шул чор ихтыяҗларыннан чыгып җибәрелгәннәр. Асылда бу Китапларның мәгънәләре бер үк – бер Аллаһыны гына Иләһә дип тану һәм Аңа гына гыйбадәт кылу. Алар бары тик хокук нормалары һәм гыйбадәт формалары белән генә аерылалар.

Ләкин без тормышыбызны, эш-гамәлләребезне әлеге Китаплар буенча корырга тиеш түгелбез. Ни өчен?

Беренчедән, алар аерым кавемнәргә генә җибәрелгәннәр.

Икенчедән, әлеге Китапларның пәйгамбәрләргә иңдерелгән төп нөсхәләре югалган. Аларны, гасырлар узганнан соң, дин белгечләре исләрендә калганча язып чыкканнар, кайбер намуссыз галимнәр хәтта хаклыкны яшереп үзгәрешләр керткәннәр. Хәзер инде бу Китаплардагы сүзләрнең кайсы кеше сүзе, ә кайсы Аллаһ сүзе икәнлеген белеп булмый.

Шул сәбәпле, кайбер халыклар хәтта диннең нигезе булган

Аллаһының берлегеннән читкә тайпылганнар. Мәсәлән, христианнар Гайсә пәйгамбәрне илаһилаштырганнар, иконаларга гыйбадәт кылалар.

Кешелек дөньясы менә шулай хак дингә сусаган бер дәвердә Гарәбстанда бөтен дөнья халыклары өчен бер Пәйгамбәр үстерелә.

Ул - пәйгамбәрләр чылбырын тәмамлаучы иң соңгы рәсүл - Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вәсәлләм. Нәкъ менә аның аша Аллаһы Тәгалә безнең эраның 7 нче гасырында кешелек дөньясына Үзенең иң соңгы Китабын - Коръәни Кәримне җиткерә.

(Укучылар «Мөхәммәд галәйһиссәләм», «Коръән» дип язылган карточкаларны схемага урнаштыралар, бер укучы «Маидә» сүрәсенең 48 нче аятен укый: «Әй, Мөхәммәд г.с. Без сиңа хаклык белән Коръәнне иңдердек, әүвәлге Китапларның хөкемнәрен дөресләгән хәлдә».)

Алып баручы: Коръәннең алда әйтелгән Китаплардан нинди аермасы бар соң?

1) Коръән аерым кавемгә түгел, ә дөньяда яшәүче барлык кешеләр өчен, ягъни, һәр заманга, һәр дәүләткә, һәр милләткә яраклы итеп иңдерелде.

2) Коръән элек иңдерелгән Китапларны дөресләп, аларда килгән аерым яхшы гамәлләрнең һәм өстенлекләрнең бөтенесен Үзенә җыйды һәм кеше бәхете өчен кирәк булган барлык Иләһи күрсәтмәләрне үз эченә алып килде.

3) Аллаһы Тәгалә Коръәнне кешеләрнең үзгәртүеннән Кыямәт көненә хәтле сакларга вәгъдә бирде.

4) Коръәни Кәрим Аллаһыдан иңгән Китапларның иң соңгысы. Кешелек дөньясына инде Кыямәт көненә кадәр Аллаһтан Китаплар иңдерелмәячәк.

Схемабызны алга таба дәвам итеп, анда хәзерге чорны һәм үзебезне дә билгеләп куйыйк.

(Бер укучы «без» дигән карточканы планшетка беркетә).

Алып баручы: Укучылар, сез ничек уйлыйсыз, схеманы

тагын да дәвам итәргә мөмкинме? Без бит киләчәк турында белмибез. Әйе, без белмибез, ләкин Аллаһы Тәгалә белә, һәм Ул безгә үзенең Китабы Коръәни Кәримдә бу дөньядагы тормышның билгеле бер көндә бетәчәге, бөтен кешеләр дә үлеп, яңадан тереләчәге һәм Үзенең каршына килеп басачагы турында хәбәр итә. Бу көн Кыямәт көне дип атала. Ул көндә һәр кешенең бу дөньяда кылган гамәлләре турында ике ягындагы фәрештәсе язып барган китаплары Аллаһ каршына куелып, шул китаплар нигезендә Ул һәркемне хөкем итәчәк.

(Бер укучы «Кыямәт көне» дигән карточканы схемага урнаштыра, икенчесе «Әл-Бәкара» сүрәсенең 281 нче аятен укый: «Хөкемгә Аллаһыга кайтачак дәһшәтле Кыямәт көненнән куркыгыз! Ул көндә һәрбер кеше кылган савабы һәм гөнаһы өчен тиешле җәзаны алыр. Ул көндә кешеләр савапларын киметеп яки гөнаһларын арттырып золым ителмәсләр»).

Алып баручы: Кем Аллаһы Тәгаләне танымыйча, Аның әмерләрен үтәмичә яши, ул кеше җәһәннәмгә – газаплар һәм ут эченә җибәрелә.

(Бер укучы «Җәһәннәм» дип язылган кызыл төстәге карточканы планшетның уң ягына аскы өлешкә беркетә, икенчесе «Ниса» сүресенең 56 нчы аятен укый: «Безнең Китабыбызга ышанмаучыларны, имансызларны утка салырбыз. Тиреләре утта янып беткәч, аларның тәннәренә яңадан тире үстерербез, каты газапны татысыннар өчен. Аллаһ Бөек һәм Хаким»).

Алып баручы: Ә кем үз тормышын Бер Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кылып, Аллаһ әмерләрен үтәп үткәргән - ул мәңгелек рәхәттә яшәү өчен Җәннәткә җибәрелә.

(Бер укучы «Җәннәт» дип язылган яшел төстәге карточканы схеманың уң ягына өске өлешкә урнаштыра, икенчесе «Мәгарә» сүрәсенең 31 нче аятен укый: «Иманлылар һәм изге гамәлләр кылучылар өчен җәннәт әзерләнгән. Бак-

чалар, алар астыннан елгалар агар. Алар анда алтыннан булган беләзекләр һәм атластан, парчадан булган яшел киемнәр киярләр, йомшак диваннарда утырырлар»).

Алып баручы: Аллаһынын кешеләргә җиткергән әмерләрен белү өчен Ислам дине турында китаплар укырга, Коръән тәфсирен, хәдисләрне (Мөхәммәд г.с. нең әйткән сүзләре) өйрәнергә кирәк һәм, әлбәттә, аларны үтәү тиешле. Аллаһы Тәгалә кешеләрне туганнан алып үлгәнче гыйлем җыярга чакыра.

Менә без сезнең белән кешелек тарихының схемасын төзедек. Әйдәгез, хәзер шушы схемага карап кайбер сорауларга җавап бирергә тырышып карыйк.

1) Кешене һәм дөньяны барлыкка китерүче кем?

2) Аллаһы Тәгаләнең барлыгын без кайдан беләбез? (Аллаһының барлыгы Ул яралткан нәрсәләргә – кеше, табигать, галәм – карап беленә. Алар барысы да камил рәвештә төзелгән).

3) Кемнәр алар пәйгамбәрләр? Аларны нәрсә берләштерә?

4) Кешене үлгәннән соң нинди вакыйгалар көтә?

5) Кешенең бу дөньяда яшәвенең мәгънәсе нәрсәдә? (Яшәүнең мәгънәсе – мәңгелек тормышка әзерләнү).

Барыбызга да бу дөньядагы тормышыбызның мәгънәсен аңлап, аны ахирәттә мәңгелек бәхеткә ирешерлек итеп үткәрергә язсын иде, дигән теләк белән бүгенге дәресебезне тәмамлыйбыз.

# 3. ГЫЙБАДӘТ (ФИКҺ) ДӘРЕСЛӘРЕ

3.1 Фикһның һәм гыйбадәтнең аңлатмасы
3.2 Гыйбадәтнең шәхес һәм җәмгыятькә булган тәэсире
3.3 Гыйбадәтне укыту методлары

## 3.1 Фикһның һәм гыйбадәтнең аңлатмасы

"Фикһ" сүзенең телдәге мәгънәсе: «аңлау, «төшенү». Шәригатьтәге мәгънәсе: «Тәфсыйли дәлилләрдән (Коръән һәм хәдистән) чыгарып алынган гамәлләргә кагылышлы шәригать хөкемнәрен белү». Гамәли хөкем дигәндә – тормышта кулланыла торган хөкемнәр күз алдында тотыла, ә шәригать хөкемнәре дигәндә – хөкемнәрне һәм аларның дәрәҗәсен (фарыз, важиб, сөннәт һ.б.) белү күз алдында тотыла.

Шәригать белән фикһ арасындагы аерма: «Шәригать» төшенчәсе үз эченә бөтен шәригать хөкемнәрен (гакыйдә, гыйбадәт, мөгәмәләт, әхлак) ала, ә «фикһ» төшенчәсе үз эченә гамәли хөкемнәрне генә (гыйбадәт, мөгамәләт) ала.

Пәйгамбәр с.г.в.с.: «Кемгә Аллаһы Тәгалә яхшылык тели, ул аны диндә фәкыйһ итә», - диде (ягъни дин хөкемнәрен белүче итә).

Фикһ кешенең Раббысы Аллаһы Тәгалә, үз-үзе һәм башка кешеләр белән булган мөгамәләләрне тәртипкә салучы гамәли кануннардан гыйбарәт. Фикһ түбәндәге өлешләрдән тора:

1) «Әл-Гибәдә» (гыйбадәт хөкемнәре) – кешенең Раббысы Аллаһы Тәгалә белән бәйләнешен тәртипкә салучы хөкемнәр: намаз, ураза тоту, зәкят түләү, хаҗ кылу, нәзер, антлар.

2) «Әл-Мөгәмәлә» (мөгәмәләт хөкемнәре) – кешенең башка кешеләр белән булган бәйләнешен тәртипкә салучы хөкемнәр: 1- «Әхвәл әш-шәхсия» (шәхеснең халәтләре) – туганнан алып вафат булуына кадәр кешенең халәтен аңлатучы

хөкемнәр: никах, талак, нәселнең дәвамы, нәфәка бирү, имезү, мирас, вәсыять; 2- «Әл-Мәлия» (малга кагылышлы хөкемнәре) – кешеләрнең мал белән бәйле булган мөгәмәлә итүләрен тәртипкә салучы хөкемнәр (сату-алу, бүләкләү, аренда, залог, ширкәтләр, мудараба, җаваплылыкны үз өстенә алу, вәкиллек итү, йөк, бушлай куллану һ.б.), милек белән бәйле мәсъәләләр (җир эшкәртү, ташландык җирләр, малны законсыз тартып алу, хәбәрсез югалганнар, вакыф һ.б.); 3- «Әл-Гүкүбәт» (җинаять хөкемнәре) – җинаять кылу һәм җәза бирү белән бәйле хөкемнәр.

3) «Әл-Султания» (дәүләт хөкемнәре) – хөкүмәтнең төзелеше, ватандашларының дәүләт белән бәйләнешләре белән бәйле шәригать хөкемнәре.

4) «Әд-Дүәлия» (дәүләтара хөкемнәр) – дәүләт ара булган бәйләнешләрне тәртипкә салучы хөкемнәр.

Фикһның үзенчәлекләре: 1) Фикһның чыганагы вәхи аркылы Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелгән Коръән Кәрим һәм Сөннәт булып, Аллаһы Тәгалә ялгыз бер Үзе Кануннар чыгаручы булуы; 2) Ислам шәригатенең бөтен кешелек өчен иңдерелүе, ә аерым бер халык өчен генә түгел: «Без сине барча дөнья кешеләренә пәйгамбәр итеп җибәрдек» (әл-Сабә сүрәсе, 34/28); 3) Аллаһы Тәгалә Ислам динен үзгәртүдән Үзе саклый: «Дөреслектә Без Коръәнне үзебез иңдердек һәм үзгәрүдән аны үзебез сакларбыз» (Әл-Хиҗр сүрәсе, 15/9); 4) фикһның дөньяви һәм ахирәви булуы: фикһның дөнья тереклегендәге проблемаларны, шулай ук, кешенең Раббысы, үз-үзе һәм башка кешеләр белән бәйле проблемаларны хәл итүен алуы; кешенең дөньяда ачык рәвештә кылган гамәлләре өчен дә (мәсәлән, малны законсыз тартып алу), калебендә яшерелгән начар гамәлләре өчен дә (мәсәлән, көнчелек, саранлык, начарлык кылу нияте) Ахирәттә җәза алуы; 5) фикһның гакыйдә һәм әхлак белән тыгыз элемтәдә булуы; 6) фикһның мәңге һәм үзгәрмәс булуы.

Сөнниләр фикһта дүрт мәзһәбнең берсенә иярәләр: 1) Хәнәфи мәзһәбе: аңа нигез салучы Имам Әгъзәм Әбү Хәнифә ән-Нугмән бин Сәбит (80/699-150/7671); 2) мәлики мәзһәбе: нигез салучы Имам Мәлик бин Әнәс (93/713 - 179/795); 3) шәфигый мәзһәбе: нигез салучы Имам Мөхәммәд бин Идрис әш-Шәфигый (150/767 - 204/820); 4) хәнбәли мәзһәбе: нигез салучы Имам Әхмәд бин Хәнбәл әш-Шәйбәни (164/780 - 241/855)[21].

Югарыда китерелгәннән аңлашыла: гыйбадәт хөкемнәре фикһның бер өлеше булып тора. Ислам диненең нигезләре бишәү: Беренчесе – ике шәһадәт китерү: "Әшһәдү әл-лә иләһә илла-Лаһү вә әшһәдү әннә Мүхәммәдәр-Расүлү-Лаһ" (Мәгънәсе: "Аллаһтан башка һичбер иләһ юк һәм Мөхәммәд с.г.в.с. Аллаһның Рәсүле дип шәһадәт китердем"), икенчесе – көнгә биш тапкыр намаз уку; өченчесе – Рамазан аенда ураза тоту; дүртенчесе – зәкят бирү; бишенчесе – хаҗ кылу.

Гыйбадәт сүзенең телдәге мәгънәсе: буйсыну, итагать итү, тынычлану. Гыйбадәтнең шәригатьтәге мәгънәсе: Аллаһы Тәгаләне сөю һәм Аңа тәмам рәвештә буйсыну. Гыйбадәт сүзе үз эченә, Аллаһы Тәгалә яраткан һәм разый булган, яшерен һәм ачык булган, бөтен сүзләрне һәм гамәлләрне ала: намаз, зәкят, дөрес сүз, әманәтне саклау, ата-анага буйсыну һ.б.

Гыйбадәтнең максаты – Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алу һәм Аңа итагать итүгә ирешү.

Аллаһы Тәгалә әйтте:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ

**"Кеше илә җенне халык кылмадым, мәгәр Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен генә халык кылдым. Мин кешеләрдән һич ризык теләмим, ягъни сорамыйм, дәхи Мине ризыкландырулары да сорамыйм".** *(Әз-Зәрият, 51/56-57).*

[21] Валиуллин К.Х. Хозяйственное право в Исламе. Учебное пособие. Казань: ГБУ «Центр исламоведческих исследований» АН РТ, 2012. Стр. 14-16.

Гыйбадәт ул һәрбер эшнең нигезе булып тора, һәрбер эшнең максаты. Һәм ул колларына карата Аллаһы Тәгаләнең хакы, дөнья һәм Ахирәттә уңышка ирешүләренә яисә бәхетсезлеккә дучар булуларына юл, ансыз һичбер мәхлук һәм һичбер сәламәт калеб булмый.

Гыйбадәт ике төрдән тора:

1) Махсус гыйбадәт: үз эченә фарыз (тиеш) булучы дини нәрсәләрне ала – намаз, ураза, зәкят, хаҗ һ.б.

2) Гомуми гыйбадәт: Аллаһы Тәгаләгә калебе, фикерләре, гамәлләре, теле, ишетүе, күрүе, җаны, малы белән гыйбадәт итүе. Мәсәлән: файдалы гыйлем алу, ашау, эчү, йоклау һ.б.

## 3.2 Гыйбадәтнең шәхес һәм җәмгыяткә булган тәэсире

1. Кешенең күңелендә иманның (гакыйдәнең) ныгуы. Гыйбадәт – кешене Аллаһы Тәгаләнең барлыгына фикере белән канәгать булу баскычыннан, Аллаһы Тәгаләне разый итә торган нәрсәләрне гамәл итүгә алып баручы алым (юл) булып тора.

2. Кешене тәрбия итүе, пакълавы һәм дөрес булган яшәү рәвешенә юнәлдерүе.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

قَدْ أَفْلَحَ مَنْ تَزَكَّى وَذَكَرَ اسْمَ رَبِّهِ فَصَلَّى

**“Ширектән һәм хәрам эшләрдән үзен пакьләгән һәм саклаган кеше, тәхкыйк, өстенлек тапты. Вә ул кеше Раббысын зекер итеп намаз укыды”.** *(Әл-Әгъләә, 87/14-15).*

3. Гыйбадәт нигезендә кешедә түбәндәгеләрне тәрбия итү:

- эзлекле (бер-бер артлы) күтәренке көчне арттыру, Аллаһы Тәгаләнең көч-кодрәтеннән алынуы сәбәпле;

- үз-үзеңә тугрылыклы булуга китерү, Аллаһы Тәгалә белән тугрылыклы булуы сәбәпле;

- калебенең тыныч булуына алып бару.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

الَّذِينَ آمَنُوا وَتَطْمَئِنُّ قُلُوبُهُمْ بِذِكْرِ اللَّهِ أَلَا بِذِكْرِ اللَّهِ تَطْمَئِنُّ الْقُلُوبُ

**"Ул туры юлга күндерелгән кешеләр Аллаһка һәм Коръәнгә ышанырлар да, Аллаһ зекере вә Коръән вәгазе белән күңелләре карар табар, рәхәтләнер! Әлбәттә, Аллаһ зекере вә Коръән вәгазе белән генә күңелләр карар табарлар".** *(Әр-Рагд, 13/28).*

4. Әхлакның ныгуы, артуы һәм аны үзгәрүдән, түбәнгә төшүдән саклавы. Намаз - кешене фәхишәлек һәм начарлыктан саклый.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَأَقِمْ الصَّلَاةَ إِنَّ الصَّلَاةَ تَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنْكَرِ

**"Ий Мухәммәд г-м, намаз укыгыл, тәхкыйк намаз, фәхеш эштән дә ярамаган эшләрдән укучыны тыя".**

*(Әл-Гәнкәбүт, 29/45).*

5. Зәкят - җәмгыять кешеләре арасында кызгану, теләктәшлек һәм берләшүне булдыра. Ураза - мәшәкатьләргә сабыр итүгә күнегү, ихтыяр көчлелеге, фәкыйрь һәм зәгыйфьләрнең хәлен аңлау, байлык ратуны һәм саранлык тойгысын җиңү.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَالْمُؤْمِنُونَ وَالْمُؤْمِنَاتُ بَعْضُهُمْ أَوْلِيَاءُ بَعْضٍ يَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَيَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ

وَيُقِيمُونَ الصَّلَاةَ وَيُؤْتُونَ الزَّكَاةَ وَيُطِيعُونَ اللَّهَ وَرَسُولَهُ أُولَئِكَ سَيَرْحَمُهُمُ اللَّهُ إِنَّ اللَّهَ عَزِيزٌ

حَكِيمٌ

**"Мөэмин ирләр вә мөэминә хатыннар бер-берсенә дуслар вә ярдәмчеләр: алар кешеләрне яхшылыкка өндәрләр һәм начарлыклардан тыярлар, намазларын вакытында үтәп,**

**зәкятләрен бирерләр вә һәр эштә Аллаһка һәм Аның рәсүленә итагать итәрләр, шундый кешеләргә Аллаһ тиз рәхмәт кылыр, тәхкыйк Аллаһ – Өстен булучы, Хәким”.** *(Әт-Тәүбә, 9/71).*

## 3.3 Гыйбадәтне укыту методлары

Әгәр без намаз, зәкят, хаҗ, ураза хакындагы дини китапларны карап чыксак, алар хакындагы мәгълүмат үз эченә түбәндәге 4 якны ала:

1) телдәге һәм шәригатьтәге аңлатмасын;

2) әһәмиятен, өстенлекләрен, башкаруының әҗерен һәм калдыруның хөкемен;

3) аларны башкару рәвешләрен һәм алар хакындагы аятьләрнең аңлатмаларын;

4) аның хикмәтен (максатларын һәм файдаларын).

Кайбер тәкъдимнәр: 1- Гыйбадәт дәресләрен укытканда шушы дүрт якны да үтү бик мөһим. 2- Беренчесенә һәм икенчесенә, кереш өлеше буларак, артык күп вакыт сарыф итү кирәк түгел. 3- Өченчесе исә, укытуның төп өлеше булып, төгәл аңлатып бирүгә мохтаҗ була; бу өлешне укытканда фәкыйһ галимнәрнең фикерләренә тирән кереп китү кирәк түгел, алар арасындагы каршылыклы фикерләргә тукталмаска; киресенчә, мөгаллимгә аларны башкару рәвешләрен аңлаешлы аңлатып бирү кирәк. 4- Дүртенчесе исә, иң әһәмиятлесе була, чөнки ул гыйбадәт итүнең рухи, тәэсир итүче өлеше. 5- Гыйбадәт дәресләрен гамәли рәвештә алып бару бик мөһим.

Намаз дәресләре

Намаз укытуның максатлары (аерым максатлар һәрбер дәрескә, темасына карап, куела):

1) Рухи максатлар: 1- намазга әзерләнү (тәһәрәтләнү, киемне пакълау, урынны сайлау); 2- азанны тыңлау; 3- Аллаһы Тәгалә каршына хушуг халәтендә басу, Аңа ихлас дога белән мөрәҗәгать итү; 4- “Әл-Фәтихә” сүрәсен һ.б.

сүрәләрне уку; 5- калебнең Аллаһы Тәгалә белән тоташуы, тәкбир әйтү, тәсбих әйтү, рукүг, сәҗдә кылу; 6- Аллаһы Тәгалә белән сөйләшүдә ышанычлы булу, күңелнең риза булуы, калебнең рәхәтлек кичерүе һ.б. Боларның барчасы көненә биш тапкыр кабатланып, намаз укучының рухына, калебенең рәхәтлек кичерүенә, үзеннән риза булуына, Раббысы белән элемтәдә булуына бик зур тәэсире бар.

2) Игътикадый максатлар: 1- күңелендә гакыйдәне ныгыту; 2- Аллаһы Тәгалә белән элемтәгә керү, нәтиҗәдә намаз укучының Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт итүе һәм Аннан гына ярдәм соравы.

3) Иҗтимагый максатлар: 1- мөселманнарның иҗтимагый элемтәләрен ныгыту: намаз укучы намазында Аллаһы Тәгаләгә, берлек санында түгел, ә күплек санында дога кыла: (إِيَّاكَ نَعْبُدُ وَإِيَّاكَ نَسْتَعِينُ - "Әй Раббыбыз! Сиңа гына гыйбадәт кылабыз"), (اهْدِنَا الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ - "Әй Раббыбыз! Безне туры юлга күндер!"); 2- тынычлыкны ярату һәм аңа карата гамәл кылу (намаз укучының догасында тынычлыкның мәгънәсен ныгыта һәм намазның ахырында да аны ныгыта, тормышында тынычлыкның әһәмиятен искәртеп); 3- тәртип булдыруны ныгыта: көненә биш вакыт намаз укуында; 4- имамга итагать итү һәм аңа карата әдәп саклау; 5- Аллаһы Тәгалә каршында бертигез булуыбыз.

4) Әхлакый максатлар: 1- әхлакның ныгуы, артуы һәм аны үзгәрүдән, түбәнгә төшүдән саклавы, чөнки намаз - кешене фәхишәлек һәм начарлыктан саклый; 2- Аллаһы Тәгалә белән элемтәгә керүенә горур булуы; 3- Аллаһы Тәгалә белән туры сүзле булу, нәтиҗәдә кешеләр белән дә туры сүзле булу; 4- Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылу һәм тугры булу.

5) Тәрбияви максатлар: 1- дөнья мәшәкатьләреннән арынып, Аллаһы Тәгаләгә үзеңне багышлау белән фикернең саф һәм күңелнең эчкерсез (ихлас) булуы; 2- намазда укыганына һәм хәрәкәт иткәннәренә игътибарын юнәлтү; 3-

кылган хаталардан, гөнаһлардан Аллаһы Тәгаләгә тәүбә итү; 4- ихтыяр көчен һәм тырышлыгын ныгыту.

6) Сәламәтлек максатлары: 1- даими пакълык һәм чисталык саклау (тәһәрәтле һәм госелле булу аркылы); 2- укучының намаздагы хәрәкәтләре сәламәтлек һәм куәтлеккә булган тәэсире.

Зәкят дәресләре

Зәкятнең телдәге мәгънәсе – «чистарту, үсү», шәригатьтәге мәгънәсе – "Шәригать рөхсәт иткән юллар белән малга ия булып һәм шул малның күләме нисабына тулып, шул малдан акчалата яки малның бер өлешен мохтаҗ мөселманга риясыз (аның өчен бернәрсә сорамыйча) бирү".

Зәкят - Исламның бер терәге һәм ул фарыз гамәлләрдән санала. Зәкят – Ислам иктисадый системасының олуг бер нигезе булып тора. Һәм аның кешегә тәэсир итүенең әһәмияте дә бик зур.

Зәкят укытуның максатлары (аерым максатлар һәрбер дәрескә, темасына карап, куела):

1) Рухи максатлары: 1- нәфесне саранлыктан чистарту; 2- рухны катылыктан чистарту; 3- фәкыйрьләрнең хакын бирү белән намусыңны чистарту; 4- Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алу һәм савапка ирешү белән шат булу.

2) Игътикадый максатлар: 1- Аллаһы Тәгаләгә итагать итүгә күнегү; 2- сәдака һәм бүләк бирү белән итагать итүдән канәгатьлек кичерү; 3- малның Аллаһы Тәгаләнең милкендә калуы; 4- кеше Аллаһы Тәгаләнең малына карата сак булырга тиешлеге.

3) Икътисадый максатлар: 1- мөселманнар арасында фәкыйрьлекне бетерү; 2- күмәк (уртак) тәэмин итү (гарантияләү) һәм иҗтимагый теләктәшлек; 3- байларның зәкят бирүләре тиеш булуы; 4- малның җәмгыятьтә әйләнеп йөрүе; 5- икътисадый иминлек.

4) Әхлакый максатлар: 1- яхшы-хәерле нәрсәләрне башкаруга гамәли күнегү; 2- байлар һәм фәкыйрьләр арасында

бер-берсенә карата сөюне көчәйтү; 3- кешене азат итү һәм аның намусын гарантияләү.

5) Тәрбияви максатлар: 1- кешелеккә гамәл кылу; 2- хәерле эшләрне кечерәйтүнең булмавы; 3- хәерне бирү һәм алу әдәбе; 4- кешенең калебендәге һәм акылындагы урыны.

## Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр:

1. “Фикһ” сүзенең телдәге һәм шәригатьтәге аңлатмасын сөйләгез. Шәригать белән фикһ арасында нинди аерма бар? Шуны әйтеп бирегез.
2. Фикһның өлешләре, үзенчәлекләре нидән гыйбарәт? Мәзһәбләргә нигез салучыларның исемнәрен китерегез.
3. Гыйбадәт сүзенең телдәге һәм шәригатьтәге мәгънәсен әйтеп бирегез.
4. Гыйбадәтнең максатларын санап чыгыгыз. Аның нинди төрләре бар?
5. Гыйбадәтнең шәхес һәм җәмгыятькә булган тәэсирен сөйләп бирегез.
6. Гыйбадәтне укытуда нинди методлар кулланыла? Шуларны әйтеп чыгыгыз.
7. Намаз һәм зәкят укытуның максатлары нидән гыйбарәт? Аларны китерегез.

## Кушымталар

*Гыйбадәт (фикһ) дәресләрен алып баруга якынча программа үрнәге*

1. Ислам дине буенча гамәл кылу: фарыз; ваҗиб; сөннәт; мөстәхәб; мөбах; хәрам; мәкруһ; мөстәкрәһ; балигъ һәм гакыйл; гыйбадәт кылу. Сөнниләрнең фикһтагы мәзһәбләре. Әбү Ханифә мәзһәбе. Әбү Ханифәнең тормыш юлы. Хәнәфи мәзһәбенең мәшһүр галимнәре. Ислам диненең 5 терәге.

2. Пакълык:

- пакълыкның фазыйләтләре, пакълыкның динебездәге урыны; тәннең, киемнең, намаз укый торган урынның пакълыгы;
- истинжа кылу рәвеше; хаҗәткә баруның әдәпләре;
- тәһәрәт алу рәвеше; таһәрәтнең фарызлары; таһәрәтнең сөннәтләре; таһәрәтнең мөстәхәбләре; таһәрәтнең мәкруһлары; таһәрәтнең мөфәсидләре, ягъни боза торган эшләре;
- читекләргә мәсех кылу; җәбирә, ягъни җәрәхәт өстендәге повязкага мәсех кылу;
- госелне алу рәвеше; госелнең фарызлары; алына торган вакытлары; госелнең сөннәтләре; госелнең сәбәпләре; сахибе гозер;
- тәяммумны алу рәвеше; тәяммумның фарызлары; тәяммумның сөннәтләре; тәяммумның мөфәсидләре, ягъни боза торган эшләре;
- нәҗесләр: җиңел нәҗес; авыр нәҗес; нәҗесләрдән пакъләү; бәдрәфкә керү вә бәдрәфтән чыгу әдәбе, хаҗәтне үтәү әдәбе (егетләргә ир кеше, кызларга хатын-кыз аерым рәвештә аңлата);
- пакъланыр өчен дөрес булган сулар; суга нәҗес төшсә; кешеләрдән соң калган су; хайваннар эчкән суның хөкеме;

- ир-егетләрнең һәм хатын-кызларның гаурәт җирләре; гаурәт җирләрен каплап йөрү тиешлеге;

- хәез; нифас; истихаза.

3. Намаз китабы:

- намазның фарызлыгы; намаз укымаучыга Кыямәт көнендәге җәзалар; көненә биш тапкыр укыла торган намазларның исемнәре;

- намазның вакытлары; намаз укырга ярамый торган вакытлар;

- Кыйбланың аңлатмасы; ничек табарга, компас белән табу, сахрада яисә урманда Кыйбланы табу;

- ният; азан һәм камәт: нинди гамәлләргә кирәкме, малайларга әйттерү, азанны тыңлау әдәбе; камәтнең азаннан булган аермалары; азанның мөстәхәбләре; азан догасы (ятлаттыру).

- намазның зикерләре: намаз эчендә һәм соңында укылачак зикерләр: сәнә, әгүзе, сүрәи Фатиха, кыска сүрәләр, рукүгъ тәсбихе, тәсмиг, тәхмид, сәҗдә тәсбихе, тәшәһһөд, салават, дога аяте, сәлам, сәлам догасы (ятлаттыру); Күнүт догасы (ятлату);

- ике, өч һәм дүрт рәкәгатьле намазларны уку рәвеше;

- хатынлар намазы (хатынларның ирләр намазыннан 8 җирдәге аермасы);

- намаздан соң укылачак тәсбих һәм догалар;

- авыру кешенең намазы;

- намаздагы гамәлләр: намазның шартлары (тышындагы фарызлары); рөкенләре (эчендәге фарызлары); намазның важиблары (кайберләрен); намазның сөннәтләре (кайберләрен); намазның мөстәхәбләре (кайберләрен); намазның мәкруһлары (кайберләрен); намазның мөфәсидләре, ягъни намазны боза торган эшләре; намазда мөбах булган эшләр;

- намазны җәмәгать белән укуның өстенлекләре; имам белән моктәдинең намазларын укулары; ирләр, сабыйлар,

хатынлар бер имамга оесалар сафларга ничек басулары; берничә кеше арасында намазны җәмәгать белән уку өчен имамны сайлау рәвеше; кемгә имам булу мәкруһ;

- мөдрик һәм мәсбук: имам намазны укый башлагач килеп җитешкән кешенең хөкеме; мөдрик кемгә дип әйтелә; мәсбук кемгә дип әйтелә; мәсбук намазын ничек тәмамлар.

- мәсҗид вә җамигъ: мәчеткә керү алдыннан һәм чыкканда дога; мәчеттә үзеңне тоту әдәбе; иртә намазын уку өчен мәчеткә кергәндә имам фарызын укыса нинди хөкем бар; өйлә намазын уку өчен мәчеткә кергәндә имам фарызын укыса нинди хөкем бар; хатынларның намазны мәчеткә барып уку хөкеме;

- намазның казасы: намазны казага калдыру мәсъәләсе;

- сәҗдәи сәһү: аңлатмасы; эшләү рәвеше; намазда саташу: 4-рәкәгатьле намазда ялгышып, әүвәлге кагъдәгә утырмыйча, кыямга тора башласа; 4-рәкәгатьле намазда ялгышып 5-че рәкәгатьне укый башласа; намаз эчендә ничә рәкәгать укыганын онытса; бу хәл 2-3 мәртәбә кабатланса; 4-рәкәгатьле намазда, ике рәкәгать укыгач, ялгышып сәлам бирсә;

- сәҗдәи тиләвәт;

- мокыйм вә мөсафир: кемгә әйтелә; кайчан кеше мөсафир исеменә керә; мөсафирның өч хөкеме.

- җомга намазын, гайд намазларын, тәравих намазын уку рәвешләре;

- җәназа: үлем хәлендәге кеше; кешенең вафат булуы; мәетне юу; мәеткә кәфенлек киертү (бу темаларны гомум рәвештә аңлату); җәназа намазы; озату вә кабергә күмү; каберләрне зиярат кылу һәм дога кылу;

- нәфел намазлары;

- хаҗәт намазы; истиска намазы; тәүбә намазы; хәвеф намазы; көсуф намазы; хөсуф намазы; сәфәр намазы; шөкер намазы; ишракъ намазы; зоха намазы; әүвәбин намазы; тәһәҗҗөд намазы; һәвел намазы; мәсҗид намазы; истихарә намазы.

4. Саум (рузә) китабы.

Рамазан ае, Кадер кичәсе; рузә тотуның фарызлыгы; рузәнең фарызлары; рузә тотуга ният кыйлу; сәхәр тору, ифтар кылу һәм догасы; рузәле кешегә сөннәт булган эшләр; рузә вакытында мәкруһ булган эшләр; рузәле кешегә дөрес булган эшләр; рузәне бозучы эшләр; үз ихтияры белән яисә хаталык белән рузәсен бозган кешенең хөкеме, кайсы гамәлләрне эшләгән кешенең рузәсе бозылмый; кемгә рузә тоту фарыз түгел; рузәне каза кыйлу; игътикяф; нәфел рузәләр тоту.

5. Зәкят китабы.

Зәкятнең телдәге һәм шәригатьтәге аңлатмасы; кемгә зәкят бирү фарыз була; нәрсәдән зәкят бирелми; кемгә зәкят бирү фарыз булмый; алтын һәм көмештән зәкят бирү; сәүдәдән зәкят; хайваннардан зәкят; уңыштан зәкят (гошер); зәкят бирелә торган кешеләр; фитра садәкасы; фидия; садәка; зәкят җыючыны билгеләү.

6. Хаҗ китабы.

Аңлатмасы; хаҗ кылу кемгә фарыз була; әл-ихрам; Мәккәи Мөкәррәмгә бару; Тәваф кылу; Сәгыя кылу; Мина; Гарәфәт тавы; Мөздәлифә; Минада таш ату; Тәвафи зият; Тәвафи садр.

Корбан бугазлау, нинди хайваннар корбанлыкка ярый, корбан ите кемгә өләшенә.

*Фикһ (гыйбадәт) дәресен уздыру үрнәге*

**Тема: Хаҗ кылу**

**Максатлар:**

1) Хаҗ кылу – олуг гыйбадәтләрдән санала икәнлеген аңлату.

2) Хаҗ кылуның аңлатмасын җиткерү; хаҗ кылуның кемгә фарыз икәнлеген төшендерү.

3) Ихрамны кию тәртибен һәм ихрамлы кешегә нинди гамәлләр тыелганын аңлату.

***Дәрес барышы***

Тактага Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләренең рәсемнәре (фотолары), Исламның биш нигезләре (шәһадәтәин, намаз, ураза, зәкят, хаҗ) плакаты, хаҗ күренешләре, хаҗга кагылышлы аятьләр куелган.

***1. Үткәннәрне кабатлау***

Укытучы элек үткән темаларны искә төшерүләре өчен укучылар арасында, сорау-җавап рәвешендә, әңгәмә үткәрә.

***2. Яңа теманы аңлату***

Дәреснең 1 нче өлеше: хаҗның аңлатмасы һәм кемгә фарыз булуы

Ислам динендә балигъ һәм гакыйл булган мөэмин кешегә фарыз булган олуг гыйбадәтләрнең бишенчесе – гомерендә бер мәртәбә Мәккәи Мөкәррамә шәһәренә барып, Хаҗ кылу.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَ لِلَّهِ عَلَي النَّاسِ حَجُّ الْبَيْتِ مَنِ اسْتَطَاعَ أِلَيْهِ سَبِيلاً

**«Аллаһыга карата – кешеләр өстендә Йортка хаҗ кылу тиешле – аңа юл тотарга хәлләре җитүчеләргә».**

*(Әли Гыймран, 3/97).*

Хаҗ – ул мәгълүм эшләрне башкару өчен, мәгълүм вакытта (һиҗри елының 8-12 Зөлхиҗҗәдә) һәм мәгълүм җирләргә (Мәккәи Мөкәррәмә һәм аның тирәсе) бару.

Хаҗ кылу фарыз: мөселман кешегә; акылы булганга; балигъ яшенә җитүчегә; азат кешегә; юл чыгымнарын күтәрә алучыга; өйдә калган гаиләсенә яшәргә җитәрлек малы калучыга; хатын-кызга мәхрамы булу (мәхрамсыз хаҗ кылу - гөнаһлы, ләкин хаҗ кылуы дөрес була); юлларның имин булуы (талаучылардан, йогышлы авырулардан һ.б.).

Шул хакта укучылар белән диалог.

Укучылар хаҗның аңлатмасын һәм кемгә фарыз булуын дәфтәрләренә язып алалар.

Дәреснең 2 нче өлеше: ихрам кию

Ихрам кию фарыз гамәлгә керә. Ул изар (киң алъяпкыч) һәм рида (киң җәймә) исемле тукымаларыннан тора. Ихрам «мәйкат» дигән җирләрнең берсендә туктап киелә. Ул җирләр барлыгы бишәү һәм алар хаҗиларның кайсы яклардан килүләренә карап билгеләнә: 1. Мәдинә ягыннан килүчеләргә – «Зуль-Хәлиф»; 2. Гыйрак ягыннан – «Зату Гыйрак»; 3. Сүрия һәм Ливан ягыннан – «Әл-Җүхфа»; 4. Нәҗд ягыннан – «Карн»; 5. Йәмән ягыннан – «Ялумлум». Ихрам мәйкаттан соң киелсә, корбан чалу тиеш була.

Ихрам кию тәртибе: мыеклар кыскартыла, тырнаклар киселә, гадәттә киелә торган киемнәр салына; госел кылына; ихрам киелә; башын каплаган килеш 2 рәкәгать намаз укыу; баш киемен салып ният кылу: أَللَّهُمَّ أَنِّي أُرِيدُ الْحَجَّ فَيَسِّرْهُ لِي وَ تَقَبَّلْهُ مِنِّي «Әй, Аллаһ! Хаҗ кылуны ният кылам, җиңеләйт миңа аны һәм аны миннән кабул ит»; соңыннан тәлбия укыла (Аллаһы Тәгаләгә сәлам): لَبَّيْكَ اَللَّهُمَّ لَبَّيْكَ. لَبَّيْكَ لاَ شَرِيكَ لَكَ لَبَّيْكَ أَنَّ الْحَمْدَ وَ النِّعْمَةَ لَكَ وَ الْمُلْكَ لاَ شَرِيكَ لَكَ «Мин Синең алдыңда, Әй Аллаһ, Синең алдыңда. Сиңа һич тиндәш юк. Тәхкыйк, барча мактау һәм барча нигъмәт Синең өчен һәм Хуҗа булу. Сиңа һич тиндәш юк».

Шушы сүзләрне әйтү белән, кеше ихрамлы була («мөхрим») һәм аңа түбәндәгеләрне эшләү тыела: 1) әдәпсез сүзләр сөйләү, кеше белән низагълашу; 2) якынлык кылу, теләк белән хатыннарның тәненә кул тидерү; 3) гөнаһ эшләр кылу; 4) киек хайваннарны һәм кошларны үтерү, аларны аулау, аучыга ярдәм итү; 5) энә белән тегелгән һәм тән шәкеле булган кием кию; 6) перчатка кию һәм тубыкны каплаган аяк киеме кию (читек, итек, кәвеш шикелле); 7) башка кию, йөзне каплау; 8) хуш исле майлар сөртү; 9) чәч һәм тырнак кисү; 10) госел алганда сабын яисә шампунь куллану. Бу эшләрнең берсен генә булса да эшләгән кеше корбан чала яки сәдака бирә (кылган эшенә карап).

Хатын-кыз ихрам кими, ә үз киеме белән, башы капланган көенчә кала, ләкин бите ачык була. Алар энә белән

тегелгән киемнәрне дә кияләр, талбияне кычкырып укымыйлар, ихрамнан чыкканда чәчләрен кыскартмыйлар. Әгәр хатын-кыз хәйз вакытенда булса, госел кыла, ният кыла, әмма намаз укымый. Мәккәгә килгәч, хәез вакыты беткәнен көтә, соңыннан госел алып, тәваф кыла.

Шул хакта укучылар белән диалог.

Укытучы укучыларга ихрамны үз киеме өстенә киеп күрсәтә һәм укучылар да ихрамны үз киемнәре өстенә киеп карыйлар.

Укучылар мәйкат урыннарын, ихрамны кию тәртибен һәм ихрамлы кешегә эшләргә тыелганнарны дәфтәрләренә язып алалар.

***3. Дәресне йомгаклау.***

Дәрес ахырында укытучы хаҗ кылуның олуг гыйбадәт икәнен, аңлатмасын, кемгә фарыз икәнлеген кыскача кабатлап үтә. Шулай ук, ихрамны кию тәртибен һәм ихрамлы кешегә нинди гамәлләр тыелганын кыскача кабатлый. Сораулар биреп дәрестә үткән теманы үзләштерүләрен тикшерә.

***4. Өйгә эш.***

Укытучы өйгә дәрестә үткәннәрне өйрәнергә куша. Шулай ук, хаҗ белән бәйле күренешләр буенча (мәсәлән, Кәгъбәтулла) рәсем ясап килергә әйтә.

# 4. ХӘДИС ДӘРЕСЛӘРЕ

4.1 Хәдиснең аңлатмасы
4.2 Хәдис укытуның максатлары
4.3 Хәдис укытуның үзенчәлекләре
4.4 Хәдис укытуның нигезләре
4.5 Дәреснең этаплары

## 4.1 Хәдиснең аңлатмасы

Хәдиснең шәригатьтәге мәгънәсе: Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. нең сүзләре, эшләре, тик торулары (тыймаганнары) һәм сыйфатлары. Бу гыйлемнең фәзыйләте бик зур һәм ул Ислам шәригатенең икенче чыганагы булып тора.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

يَاأَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا أَطِيعُوا اللَّهَ وَأَطِيعُوا الرَّسُولَ وَأُوْلِي الْأَمْرِ مِنكُمْ فَإِنْ تَنَازَعْتُمْ فِي شَيْءٍ

فَرُدُّوهُ إِلَى اللَّهِ وَالرَّسُولِ إِنْ كُنتُمْ تُؤْمِنُونَ بِاللَّهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ ذَلِكَ خَيْرٌ وَأَحْسَنُ تَأْوِيلًا

**“Әй иман китергәннәр! Аллаһка итагать итегез, һәм рәсүлгә итагать итегез! Шулай ук үзегездән булган хуҗаларыгызга да итагать итегез! Әгәр бер дини мәсьәләдә бәхәсләшсәгез, ул мәсьәләне Аллаһ китабы Коръәнгә һәм рәсүлнең гамәленә кайтарыгыз! Әгәр Аллаһка һәм Ахирәт көненә ышансагыз. Бу хәерле дә, нәтиҗәле дә булачак”.** *(“Ән-Ниса”, 4/59).*

وَأَطِيعُوا اللَّهَ وَالرَّسُولَ لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ

**“Аллаһка вә рәсүлгә итагать итегез, шаять Аллаһтан рәхмәт кылынырсыз”.** *(Әли Гыймран, 3/132).*

Пәйгамбәребез с.г.в.с. тарафыннан башкарылган эшләр 2 төркемгә бүленә: 1) Табигатенә хас гамәлләр: басып торуы, утыруы, ашавы, эчүе (мәсәлән, Пәйгамбәр с.г.в.с. күбрәк сөтле ашны ярата иде, зур адым белән иелеп йөри иде һ.б.).

Боларның Пәйгамбәр с.г.в.с. өчен дә, аның өммәте өчен дә мөбах (эшләгән кеше дә, эшләмәгән кеше дә саваплы да, гөнаһлы да булмый) икәнлеге турында бернинди каршылык юк.

2) Болардан башка гамәлләр. Алар ике төрле була: 1- Пәйгамбәр буларак үзенә генә хас булып, башка кешеләрнең аларга иярүе дөрес булмаган гамәлләр (мәсәлән, рузаны ифтар кылмыйча 2 көн тоташ тотуы, ягъни бүген иртә белән ашамыйча, иртәгә ахшамда гына авызны ачуы; никахта 4 хатыннан артык никахлануы һ.б.). 2- Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең үзенә генә хас булмыйча, башка кешеләрнең дә аларга иярергә дөрес булган гамәлләр. Бу гамәлләр шәригать хөкемнәрен ачыклап бирү өчен булса, аларга бернинди каршылыксыз иярелә. Пәйгамбәр с.г.в.с. бу гамәлләрне үзенең ачык хәдисләре белән аңлатты:

صَلُّوا كَمَا رَأَيْتُمُونِي أُصَلِّي

***“Ничек намаз укыганымны күргән булсагыз, шулай намаз укыгыз”.***

Бу хәдис Пәйгамбәр с.г.в.с. нең эшләгән эшләренә иярергә кирәклекне күрсәтә. Кайвакыт Пәйгамбәр с.г.в.с. шәригать хөкемнәрен гамәлләре белән ачыклады, мәсәлән, каракның кулын беләзек сөягенә тоташкан урыны тирәсеннән кисү белән Аллаһы Тәгаләнең “каракларның кулларын кисегез” дигән аятен аңлатып бирде.

Пәйгамбәр с.г.в.с. күрсәткән бу гамәлләрнең важиб, мандуб яки мөбах икәнлеген югарыдагы кайсы аятькә аңлатма булып торган булса аның хөкеменә иярелә. Әмма Пәйгамбәр с.г.в.с. нең савап өмет итеп, ягъни Аллаһка якынрак булуны максат итеп эшләгән кайбер гамәлләре бар. Алар мандуб хөкеменә керә – эшләгән кеше савапка ирешә, эшләмәгән кеше гөнаһлы булмый (мәсәлән, нәфел намазларын уку). Әгәр Пәйгамбәр с.г.в.с. нең гамәлләрендә Аллаһка якын булу максатында эшләнгән икәнлеге

күренмәсә, бу гамәлләр бөтенесе мөбах хөкеменә керә – эшләгән кеше дә, эшләмәгән кеше дә саваплы да, гөнаһлы да булмый (мәсәлән, утыру, йөрү, ятып тору).

Пәйгамбәребез с.г.в.с нең сөннәте ул Ислам диненә карата гамәли программа. Аллаһы Тәгаләнең күп кенә хөкемнәрнең башкару тәртибен сөннәттән генә белү мөмкин (мәсәлән, намаз укуны, зәкят бирүне, хаҗ кылу рәвешен, рузә тотуны һ.б.), чөнки Коръән Кәримдә алар гомум рәвештә килеп, тәфсилле рәвештә (җентекләп) алар хакында сөннәттә килә.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَأَنزَلْنَا إِلَيْكَ الذِّكْرَ لِتُبَيِّنَ لِلنَّاسِ مَا نُزِّلَ إِلَيْهِمْ وَلَعَلَّهُمْ يَتَفَكَّرُونَ

**“(Ий Мөхәммәд с.г.в.м.!) Без сиңа Коръән иңдердек, кешеләр өчен хаслап иңдерелгән шәригать хөкемнәрен өйрәтмәклегең өчен, шаять ишетеп, фикерләп карарлар вә аңлап кабул итәрләр!”** *(Ән-Нәхел, 16/44).*

Пәйгамбәребез с.г.в.с. башта сөннәтне язып алуны тыйган иде, Коръән Кәрим белән буталып китмәве өчен. Шул сәбәпле, сөннәт, язып алынмыйча, күңелләрдә ятлана иде. Ә инде Хуләфәи-Рашидиннар вакытында (Әбү Бәкер, Гомәр, Госман һәм Гали хәлифәлекләре дәверендә) башка җирләрнең Ислам дәүләтенә керүләре, күп сәхабәләрнең вафат булулары, гыйлемнең төрле төбәкләргә таралуы, күп төрле кешеләрнең Исламга керүләре, ялган хәдисләрнең барлыкка килүләре сәбәпле хәдисләрне җыю һәм аларны язып алу башлана.

## 4.2 Хәдис укытуның максатлары

Хәдис укытуның гомуми максатлары:

1) Коръән Кәрим белән хәдис арасындагы аерманы ачыклау;

2) хәдисләрнең мөселманнарның тормышындагы әһәмиятен аңлату;

3) хөкемнәрне чыгарудагы урынын, тормыштагы төрле мәшәкатьләрне савыктырудагы әһәмиятен бәян итү;

4) хәдисләрнең мәгънәләрен дөрес аңлауга, алардан тормыш өчен файда алуга ирештерү;

5) хәдисләрне гарәп телендә дөрес рәвештә укуга ирештерү, аларны ятлаттыру;

6) Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең шәхес буларак күркәм яклырына, әхлагына игътибар иттерү;

7) хәдисләрдәге гыйбарәләрнең матурлыгын (бәләгә), оста сөйләүчәнлеген (ораторлыгын) ачыклау.

Хәдис укытуның аерым максатлары

Аерым максатлар һәрбер дәрескә, темасына карап, куела:

1- Дәрестә өйрәнелә торган хәдиснең мәгънәсен ачыклау;

2- хәдиснең аерым сүзләрен ачыклау;

3- хәдистә булган хөкемнәрне ачыклау;

4- хәдисне дөрес укуга ирештерү;

5- хәдистә килгәне белән гамәл кылуга этәрү.

## 4.3 Хәдис укытуның үзенчәлекләре

1) Укытучының хәдисләрне сайлаганда сахих булганнарын сайлау һәм зәгыйфь булганнарыннан файдаланмау, бу мәсьәләдә укытучының төгәл булуы бик зарур;

2) хәдис Ислам диненең икенче чыганагы икәнлеген һәм Коръән Кәримне аңлатып килүен ассызыклау;

3) хәдисләрнең үзенчәлекләре, дәрәҗәләре, безгә ирешү юллары, хәдис гыйлеменә хас терминнар белән таныштыру;

4) хәдисне укыту тәфсир укытуга якын, фәкать хәдис, Коръән Кәрим шикелле, тиләвәт ителми; шулай ук, гадәттә, хәдис, тәфсир ителүче аятьләргә караганда, кыскарак була.

## 4.4 Хәдис укытуның нигезләре

1- Хәдиснең укытучы тарафыннан укылуы, соңыннан укучыларның дөрес рәвештә укулары;

2- хәдистә зекер ителгән мәгънә һәм хөкемнәрне Коръәндәге мәгънә һәм хөкемнәр белән бәйләү;

3- укучыларны тәрбия итүдә хәдистә килгән барча мөмкинлекләрдән файдалану;

4- хәдисне укытуда барча дини, иҗтимагый һәм тормыштагы мөнәсәбәтләрдән файдалану.

## 4.5 Дәреснең этаплары

1) Дәреснең темасын, әһәмиятен, галимнәрнең аны ачыклаудагы урыннарын аңлату. Теманы кешеләр арасындагы проблемалар белән бәйләп, хәдистә килгәне белән дәвалау юлларын күрсәтү яисә гомум кешеләр арасында таралган проблемалар белән бәйләү (мәсәлән, талак, гаделсезлек, кешеләр арасындагы тигезсезлек) яисә мөгаллимнең дәресне диалог рәвешендә башлап җибәрүе.

2) Соңыннан мөгаллим хәдисне тактага язып куя (яисә аерым биткә язылганын элеп куя), китапта кайсы биттә икәнен әйтә, башта үзе укып чыга, соңыннан шәкертләр белән бергә укып чыга, укудагы хаталарын төзәтә, соңыннан шәкертләр үзләре, мөстәкыль рәвештә, хәдисне укып чыгалар.

3) Хәдистәге төп фикергә аңлатма бирелә, соңыннан башка фикерләренә аңлатма бирелә, югарырак баскычта укучыларга тирәнрәк мәгънәләр дә бирелергә мөмкин. Хәдистә авыррак аңлашыла торган сүзләр булса, аларга аңлатма бирелә. Мөгаллим укучыларның үзләренә дә хәдистәге мәгънәләрне ачыклауга форсат бирә, турыдантуры сорау бирү яки кайберләреннән шәрех бирүне сорау белән.

4) Үткәннәргә нәтиҗә ясала, укучылар бу хәдистән тормышларында нинди файда алуларына игътибар ителәләр, хәдистә зекер ителгәне белән гамәл кылу кирәклеге белән вәгазьләнәләр.

5) Мөгаллим укучыларга сораулар бирү белән дәрестә үткән теманы үзләштерүләрен тикшерә, өй эше бирә.

## Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр:

1. Хәдиснең шәригатьтәге мәгънәсен китерегез. Пәйгамбәребез с.г.в.с. тарафыннан башкарылган эшләренең ике төркеме нинди ул? Шуларны аңлатып бирегез.
2. Хәдис укытуның гомуми һәм аерым максатлары нидән гыйбарәт? Аларны китерегез.
3. Хәдис укытуның үзенчәлекләре һәм нигезләре нинди ул? Шуларны әйтеп чыгыгыз.
4. Хәдис дәресенең этапларын санап чыгыгыз.

## Кушымталар

*Хәдис дәресләрен алып баруга якынча программа үрнәге*

1. Хәдис гыйлеменең аңлатмасы, әһәмияте, үсүе, фән буларак барлыкка килүе.

2. Кабул ителүче хәдисләр; Кодси хәдисләр; Коръән Кәрим белән Кодси хәдисләр арасындагы аерма һәм охшашлык; Хәбәр мөтәватир, мәшһүр хәбәр һәм әхәд хәбәр; Кабул ителүче һәм инкяр ителүче хәдисләр.

3. Мәшһүр хәдис җыентыклары: Сахихи әл-Бохари (صحيح البخارى); Сахих Мүслим (صحيح مسلم); Сунан әт-Тирмизи (سنن الترمذي); Сунан ән-Нәсәи (سنن النسائى); Сунан Әбү Дәүд (سنن ابو داود); Сунан Ибн Мәҗә (سنن ابن ماجه); әл-Мүәтта әл-имам Мәлик (الموطأ الامام مالك); Мүснәд Әхмәд бин Хәнбәл (مسند احمد بن حنبل). Шушы мәшһүр җыентыклар һәм муәлифләре хакында кыскача белешмә бирү.

4. Имам Яхья бин Шәрафеддин Ән-Нававиның “40 хәдис” (الاربعين النووية) исемле китабыннан хәдисләр шәрх итү һәм кайберләрен тулысынча яисә өлешләп ятлату:

1 нче хәдис (бер өлешен ятларга); 2 нче хәдис; 3 нче хәдис (ятларга); 4 нче хәдис; 5 нче хәдис (ятларга); 6 нчы хәдис; 7 нче хәдис (ятларга); 8 нче хәдис; 9 нчы хәдис; 10 нчы хәдис (бер өлешен ятларга); 11 нче хәдис; 12 нче хәдис; 13 нче хәдис (ятларга); 14 нче хәдис; 15 нче хәдис; 16 нчы хәдис; 17 нче хәдис; 19 нчы хәдис (бер өлешен ятларга); 20 нче хәдис.

*Хәдис дәресен уздыру үрнәге*

**Тема:** Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең «Дөреслектә, эшләр ниятләренә карап билгеләнелә» дигән хәдисе:

Әбү Хафс Гомәр ибн Хаттабтан риваять ителә: Мин Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең түбәндәге сүзләрен әйткәнен ишеттем: «Дөреслектә, эшләр ниятләренә карап билгеләнелә.

Дөреслектә, һәрбер кешегә үзе ниятләгән нәрсәсе генә биреләчәк. Аллаһ һәм Аның пәйгамбәренә һиҗрәт кылучы кеше Аллаһка һәм Аның илчесенә һиҗрәт кыла. Әгәр дә дөньядан нәрсә өчен булса да, яки өйләнергә теләгән хатын-кыз өчен һиҗрәт кылса, ул үзе теләгән нәрсәсе өчен һиҗрәт кыла». (Әл-Бохари һәм Мөслим хәдисләр җыентыклары).

**Максатлар:**

1) Хәдисне риваять итүче һәм хәдис җыентыклары хакында белешмә бирү.

2) Хәдиснең әһәмиятен һәм әйтелүенең сәбәбен аңлату.

3) Хәдиснең нәрсәгә юнәлдерелгәнен аңлату.

4) Хәдисне ятлаттыру.

Өйгә бирелгән эш.

Укучыларның дәрестә узачак хәдиснең гарәпчәсен һәм татарча мәгънәсен язып килүләре.

***Дәрес барышы***

Тактага дәрестә узачак хәдиснең гарәпчәсе һәм татарчасы язылган бит элеп куелган. Бохари һәм Мөслим хәдис җыентыклары.

***1. Яңа теманы аңлату***

Дәреснең 1 нче өлеше:

Укытучы: Бүген без сезнең белән «Дөреслектә, эшләр ниятләренә карап билгеләнелә» дигән хәдисне үтәрбез. Башта без ул хәдиснең гарәпчәсен укып алыйк.

Укытучы хәдиснең гарәпчәсен дөрес рәвештә укып чыга. Соңыннан укучылар укытучы артыннан укыйлар. Укытучы укучыларның хәдисне дөрес рәвештә укуларына игътибар итә.

Дәреснең 2 нче өлеше: Хәдисне риваять итүче һәм хәдис җыентыклары хакында белешмә бирү

Укытучы: Хәдис Әбү Хафса Гомәр ибн Хаттабтан риваять ителә. Кем соң ул Гомәр ибн Хаттаб? Безгә бу хакта Шамил сөйләп бирә.

Укучы Шамил: Гомәр ибн Хаттаб сәхабәләрнең олугларыннан, Хүләфәи-Рашидиннарның икенчесе, Җәннәт белән шатландырылган ун сәхабәнең икенчесе. Нәселе Пәйгамәребез с.г.в.с. белән кушыла. Әбү Бәкер, авырткан вакытында, сәхабәләрнең олуглары белән киңәшләшеп, аларның ризалыгы белән Гомәрне хәлифә итәргә вәсыять иткән була. Шул сәбәпле, Әбү Бәкер вафатыннан соң, Гомәр хәлифә була һәм ул "Әмирул-мүъминин" дип атала башлый. Шушы вакытта үзенең бөтен көчен, фикерләрен Ислам файдасына корбан итә.

Укучы: Ә ни өчен аңа Әбү Хафса дип әйтәләр?

Укытучы: Әбү дигәне гарәп телендә "әти" дигәнне аңлата, ягъни Хафсның әтисе. Хафса – ул Гомәрнең кызы һәм Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең хатыны.

Укытучы: Хәдис әл-Бохари һәм Мөслим хәдисләр җыентыкларында китерелә дип әйтелгән. Бу хәдис җыентыклары "Сахих" (гарәпчәдән "дөрес" дип тәрҗемә ителә) дип атала һәм алар хәдис китаплары арасында ин дөрес дип саналалар. Аларның беренчесен Әбү Габдуллаһ Мөхәммәд бин Исмәгыйль әл-Бохари төзегән, ә икенчесен Әбү әл-Хөсәен Мөслим бине әл-Кушайри ән-Нәйсабури төзегән.

Укучылар Гомәр ибн Хаттабның исемен, Хафсаның кем икәнен, "Бохари" һәм "Мөслим" хәдис җыентыклары төзүчеләренең исемнәрен дәфтәрләренә язып алалар.

Дәреснең 3 нче өлеше: Хәдиснең әһәмияте

Бу хәдис диннең нигезе дип атала торган әһәмиятле хәдисләрнең берсе, аның белән диннең күп карарлары бәйләнгән. Бу галимнәрнең түбәндәге сүзләреннән күренә. Әбү Дауд әйткән: «Дөреслектә, эшләр ниятләренә карап билгеләнелә» дигән хәдис Исламның яртысын тәшкил итә, чөнки, дин, яисә ачык булырга мөмкин, ә бу — гамәл, яки яшерен булырга мөмкин, ә бу — ният».

Имам Әхмәд һәм имам әш-Шәфигый әйткәннәр:

«Дөреслектә, эшләр ниятләренә карап билгеләнелә» дигән хәдис диннең өчтән берен тәшкил итә: кеше үзенә нәрсәне булса да йөрәге, теле яки башка әгъзасы ярдәмендә таба ала. Шулай итеп, йөрәктә барлыкка килгән ният өстә әйтеп кителгән өч әгъ-заның берсе булып тора».

Менә шуның өчен галимнәр әлеге хәдисне үзләренең китапларының башларында китерергә яраталар. Моның максаты – гыйлем алырга омтылган кешенең ниятен төзәтеп, гыйлем алуны һәм изге гамәлләр кылуны Аллаһ ризалыгы өчен эшләүгә юнәлдерү.

Шул хакта укучылар белән диалог.

Укучылар Бохари һәм Мөслим хәдис җыентыкларын, аларның төзелешен һәм дәрестә үтелә торган хәдисне карап чыгалар.

Укучылар хәдиснең әһәмияте хакында әйтелгән галимнәрнең сүзләрен дәфтәрләренә язып алалар.

Дәреснең 4 нче өлеше: Хәдиснең әйтелүенең сәбәбе

Әт Табарани үзенең «Әл-мугъҗәмүл-кәбир» китабында хәбәр итә: Ибне Мәсгуд болай дигән: «Безнең арабызда Үммү Кайс исемле хатынга өйләнергә теләгән кеше бар иде. Әмма ул кеше Мәдинәгә күчеп килмәсә, Үммү Кайс аңа кияүгә чыгудан баш тартты. Шуннан соң ул күчеп килде һәм шул хатынга өйләнде. Аннары без аны «Үммү Кайсның мөһәҗире» дип йөртә башладык».

Шул хакта укучылар белән диалог.

Укучылар хәдиснең әйтелүнең сәбәбен дәфтәрләренә язып алалар.

Дәреснең 5 нче өлеше:Хәдиснең нәрсәгә юнәлдергәне

Хәдис кешеләрне түбәндәге нәрсәләргә юнәлдерә:

1. Ниятнең зарури шарт булып торуы. Галимнәрнең фикеренчә, мөэминнәрнең кылган гамәлләре шәригать күзлегеннән бәяләнәчәк һәм алар ният белән эшләнсәләр генә алар файда китерәчәк. Намаз, хаҗ, ураза һ.б. гыйбадәтләрне кылганда ният аларның бер нигезе булып

тора, нияттән башка алар дөрес булмыйлар.

2. Ниятнең вакыт белән бәйле булуы – теге яки бу гыйбадәткә керешкәндә кеше билгеле бер нияткә ия булырга тиеш. Мәсәлән: намазга керешкәндә «Аллаһү әкбәр» дигән сүзләр алдыннан ният кылу яки хаҗ вакытында ихрам хәленә кергәч ният кылу, уразаны тотар алдыннан ниятләү.

3. Ниятнең урыны йөрәктә булуы.

4. Берәр кешенең изге гамәл кылырга теләп тә, авыру, үлем, яки башка сәбәпләр аркасында эшли алмаса, барыбер ул эш өчен әҗер алуы. Әл-Бәйдави әйткән: «Ниятсез кылына торган гамәлләр дөрес булмый, чөнки гамәлсез нияткә әҗер бирелә, ә ниятсез гамәл юкка чыга. Ният гамәлгә карата гәүдәдәге җан кебек: гәүдә җансыз яши алмый, җан да гәүдә булмаса бу дөньяда үзен күрсәтә алмый».

5. Эшләрдә һәм гыйбадәтләрдә эчкерсез булырга юнәлдерүе. Монын ярдәмендә без Ахирәттә – әҗер, ә бу тормышта – ярдәм һәм уңыш алачакбыз.

6. Изге ният, эчкерсезлек һәм Аллаһның ризалыгын табырга омтылу барлык файдалы һәм изге эшебезне гыйбадәткә әверелдерүе.

Шул хакта укучылар белән диалог.

Укучылар хәдиснең нәрсәләргә юнәлдергәнен дәфтәрләренә язып алалар.

***2. Дәресне йомгаклау.***

Дәрес ахырында укытучы Гомәр р.а.г., Бохари һәм Мөслим хәдис җыентыклары, хәдиснең әһәмияте, әйтелүенең сәбәбе, хәдиснең нәрсәгә юнәлдерелгәне хакында кыскача кабатлап үтә. Сораулар биреп дәрестә үткән теманы үзләштерүләрен тикшерә.

***3. Өйгә эш.***

Укытучы өйгә хәдиснең бер өлешен (яисә тулысынча) ятларга һәм дәрестә үткәннәрне өйрәнергә куша.

# 5. СИРА ДӘРЕСЛӘРЕ

5.1 Сираның аңлатмасы
5.2 Сира укытуның максатлары
5.3 Сира укытуның үзенчәлекләре
5.4 Дәреснең этаплары

## 5.1 Сираның аңлатмасы

“Сира” сүзенең телдәге мәгънәсе: кеше шуннан баручы юл һәм халәт. Мөселман галимнәре каршында “сира” дигәндә “Ислам тарихы” дип күздә тотыла.

Сира, хәдисне укытудан аермалы буларак, вакыйгаларны тәфсилле рәвештә (җентекләп) зекер итү белән аерыла. Хәдис исә, хөкемнәрне, әдәпләрне, әхлакне зекер итүдән гыйбарәт. Мисалларны китерүдә хәлләрнең күп булуы сәбәпле, тәрбия итүдә сираның мөмкинчелекләре күбрәк.

Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең шәхеслегенең олуглыгына тәфсилле вакыйгалар ишарә булып торуы сәбәпле, сираның әһәмияте бик зур. Чөнки Пәйгамбәребез с.г.в.с. пәйгамбәрләрнең ахыргысы, аларның мөһере булып тора. Шул сәбәпле, аның сирасына кагылышлы вакыйгаларны белү һәм ятлау бик мөһим.

Мөгаллимнең, укучыларының җир йөзендә иң өстен булган кешенең сирасын өйрәнүләрен даими искәртеп торуы кирәк. Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең шәхеслеге башка олуг шәхесләр белән бер түгел, киресенчә Аллаһы Тәгалә аны өйрәнүне тиеш иткән бердәнбер сира. Укучыларга Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең сирасын өйрәнү тиеш. Сираны өйрәнүнең максаты вакыйгаларны тәфсилле өйрәнү генә түгел, ә аның тормышы күркәм үрнәк булуы өчен.

## 5.2 Сира укытуның максатлары

Сира укытуның гомуми максатлары

1) Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең сирасында иярүгә үрнәк булырлык якларны күрсәтү.

2) Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең сәхабәләрен укытудагы һәм тәрбия итүдәге юлларын һәм дәгъвәт итүенең уңышлы булуының серләрен белү.

3) Ислам батырларының, беренче мөселманнарының тарихтагы мәртәбәле урыннарын күрсәтү.

4) Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең сирасында йорт әһелләре, сәхабәләре белән булган иярүгә үрнәк булырлык мисалларны ачыклау.

5) Сира дәресләренең тәэсирендә укучыларның үз-үзен тотышларын, гамәлләрен яхшы якка үзгәртү.

6) Ислам дәгъвәтен бөтен галәмгә таратудагы мөселманнарның методларын һәм тырышлыкларын ачыклау.

7) Ислам өммәтенең бердәмлеген җимерүче дөрес булмаган тарихи күзаллаулар һәм фикерләрне инкяр итү.

Сира укытуның аерым максатлары

Аерым максатлар һәрбер дәрескә, темасына карап, куела:

1- Укучыларның дәрестә булган теманы дөрес аңлауларын ныгыту.

2- Сира китабында китерелгән аерым сүзләрнең мәгънәсенә төшенү.

3- Сира китабында килгән текстны яхшы укулары.

4- Укучыларны дәрестә үткәнне гамәлдә үтәүләренә юнәлдерү.

## 5.3 Сира укытуның үзенчәлекләре

1) Сираны укытканда сөйләнә торган шәхеснең исеме, кушаматы һәм нәселе, тәрҗемәи хәле, җәмгыятьтәге уры-

ны, кылган гамәлләре хакында да белешмә бирү. Һәм бу мәсъәләдә Ислам куйган чикләрдә башкару: чиктән артык мактамау яисә түбәнсетмәү.

2) Иң беренче төп чыганакларга һәм сира буенча классик әсәрләргә мөрәҗәгать итү (мәсәлән, Ибн Һишәм[22]). Шулай ук, соңгы вакытларда чыккан китаплардан да файдаланырга була. Иң мөһиме – бу чыганакларның дөрес булуы.

3) Сира дәресенең максатына карап, төрле методлар куллану: үгет-нәсихәт бирү, вәгазьләү, күрсәтмәләр, хөкем чыгару максаты белән озын яисә кыска кыйссалар китерү. Кайвакыт берәр вакыйганы анализлау (тикшерү) яисә аның хакта фикерләү яки аны тәнкыйтьләү я бәхәс итү һәм диалог (ике яки берничә кешенең кара-каршы сөйләшүе) рәвешендә булырга мөмкин.

4) Сирадагы вакыйгаларны хәдис-шәрифләрдә һәм Коръән Кәримдә килгәне белән бәйләү.

5) Сирадагы вакыйгаларны хәзерге тормыштагы вакыйгалар белән бәйләү.

6) Сираны үзләштерүне тәэмин итүче чаралардан файдалану: компьютер программалары, видео, CD һ.б.

7) Пәйгамбәребез с.г.в.с. һәм Ислам тарихы белән бәйле булган нәрсәләрнең фотографияләреннән һәм видеоматериаллардан файдалану.

8) Сирадагы вакыйгалардан укучыларның калебләрендә Ислам диненә, Рәсүле с.г.в.с. гә, сәхабәләргә, барча мөселманнарга карата мәхәббәтне үстерүдә файдалану.

## 5.4 Дәреснең этаплары

1) Мөгаллимнең дәресне башлап җибәрү методлары (мөгаллим шуларның берсен сайлап алырга мөмкин): 1-

[22] Ибн Хишам. Жизнеописание Пророка Мухаммада. Рассказанное со слов аль-Баккаи, со слов Ибн Исхака аль-Мутталиби (первая половина VIII века) /Перевод с арабского Н.А.Гайнуллин. М.: Издательский дом «УММА», 2002.

дәрестә карала торган вакыйгаларны зекер итеп, турыдан-туры сирага керүе белән; 2- кыска гына кыйсса укып чыгу, чөнки кыйсса укучыларның күңелләренә нык тәэсир итүче булып тора; 3- укучыларга сораулар бирү белән; 4- әүвәлге дәресне хәзерге дәрес белән бәйләү (мөмкин булса); 5- җәмгыятьтәге берәр проблеманы ачыклау белән; 6- Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең сирасының олуглыгын бәян итү максаты белән, кайбер батырларын зекер итү юлы белән башлап китәргә мөмкин.

2) Укытучы сира дәресенең төп өлешенә күчеп, аны өлешләргә бүлеп, тормыштагы вакыйгалар белән бәйләп, сөйли һәм һәрбер өлештән соң, аңлау дәрәҗәләрен тикшерер өчен, укытучы сораулар бирә.

3) Укытучы укучыларга, өйрәнгәнне истә калдырулары өчен, дәрестәге теманың мөһим якларын ачыклый, сораулар бирә.

4) Дәрес темасын бетергәннән соң түбәндәге эшләрне башкара:

- аңлау дәрәҗәләрен тикшерер өчен укучыларга сораулар бирә;
- укучыларга темага бәйле тәэсир итүче тәрбияви сүзләр әйтә;
- өй эшен бирә.

## Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр:

1. “Сира” сүзенең телдәге мәгънәсен китерегез. Сира хәдистән нәрсә белән аерыла? Сираның әһәмияте нидән гыйбарәт? Шуларны китерегез.
2. Сира укытуның гомуми һәм аерым максатлары нидән гыйбарәт? Шуларны әйтеп чыгыгыз.
3. Сира дәресенең этапларын әйтеп чыгыгыз.

## Кушымталар

*Сира дәресләрен алып баруга якынча программа үрнәге*

***Пәйгамбәрләр кыйссалары***

1. Адәм гәләйһис-сәләм пәйгамбәр
2. Нух гәләйһис-сәләм пәйгамбәр
3. Һүд гәләйһис-сәләм пәйгамәр
4. Ибраһим гәләйһис-сәләм һәм Исмәгыйль гәләйһис-сәләм пәйгамбәрләр
5. Йосыф гәләйһис-сәләм пәйгамбәр
6. Әйюб гәләйһис-сәләм пәйгамбәр
7. Муса гәләйһис-сәләм пәйгамбәр
8. Дауд гәләйһис-сәләм пәйгамбәр
9. Сөләйман гәләйһис-сәләм пәйгамбәр
10. Юнус гәләйһис-сәләм пәйгамбәр
11. Гайсә гәләйһис-сәләм пәйгамбәр

***Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. нең сирасы***

1. Сира фәне. Сираны белүнең әһәмияте. Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең сөннәте.
2. Мөхәммәд с.г.в.с. нең гаиләсе. Фил вакыйгасы. Мөхәммәд с.г.в.с. нең бала чагы. Мөхәммәд с.г.в.с. Әбү Талибның тәрбиясендә. Кәгъбәне төзү.
3. Хәдичәгә өйләнү. Вәхинең иңдерелә башлавы. Исламга өнди башлау. Беренче мөселманнар. Хабәшстанга күчеп китү. Олы кайгы елы. Таифка бару. Мөхәммәд с.г.в.с. нең Мәккәдән Коддуска төнге сәяхәте һәм күккә ашуы.
4. Пәйгамбәр с.г.в.с. нең Мәдинәгә һиҗрәт кылуы (күчеп китүе). Бәдер сугышы. Өхед тавы янындагы сугыш. Худәйбия вакыйгасы. Патшаларга һәм хакимнәргә илчеләр җибәрү. Хайбәр ныгытмасын алу. Аллаһы Тәгалә бүләк иткән гыйбадәт.
5. Мәккәи Мөкәррәмәне фәтех итү. Тәбүк вакыйгасы.

Хушлашу хаҗы. Рәсүлүллаһ с.г.в.с. нең вафаты. Рәсүлүллаһ с.г.в.с. ның сыйфатлары. Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. нең хатыннары.

***Ислам тарихыннан кайбер вакыйгалар***

1. Пәйгамбәребез с.г.в.с. сәхабәләре. Тугры хәлифәләр дәвере (һиҗри белән 11 – 40 еллар/милади белән 631 – 661 еллар). Үмәвия дәүләте (һиҗри белән 41 – 132 еллар /милади 661 – 750 еллар). Габбәсиләр гасыры (һиҗри белән 132-нче ел – 4-нче гасырының уртасы, милади белән 750-950 еллар). Монголлар явы (милади белән 950-1258 еллар). Госманлы дәүләт.

2. Бөек Болгар дәүләте. Ибн Фадлан. Алтын Урда дәүләте. Себер ханлыгы. Әстерхан ханлыгы. Казан ханлыгы.

3. Ислам үсешенә зур өлеш керткән галимнәребез, аларның тормыш юллары һәм әсәрләре (Ш.Мәрҗани, Г.Утыз-Имәни, Курсави, Ризаэтдин бин Фәхреддин, З.Рәсүли, Г.Баруди һ.б.).

*Сира дәресен уздыру үрнәге*

**Тема: Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. нең бала чагы һәм Фил вакыйгасы**

**Максатлар:**

1) Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. нең әтисенең, әнисенең, бабасының һәм сөт анасының исемнәрен, кайсы шәһәрдә һәм кайсы елда туганын сеңдерү.

2) “Фил вакыйгасын” сөйләп, шуның белән тәэсирләндерү.

3) Гарәпләрнең һәм башка халыкларның ул вакыттагы халәтләрен кешеләрнең хәзерге гасырдагы яшәүләре белән чагыштыру.

Укыту әсбабы: Азия, Аурупа һәм Африканың хәзерге сәяси карталары.

Өйгә бирелгән эш: Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. нең бала-чагасы хакында китаплардан укып яисә әти-әниләреннән сораштырып килергә.

***Дәрес барышы***

Тактага Азия, Аурупа һәм Африканың хәзерге сәяси карталары эленгән, Мәккә шәһәренең күренешләре куелган. Укытучы өстәлендә Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең сирасына кагылышлы рәсемле китаплар.

***1. Яңа теманы аңлату***

Дәреснең 1 нче өлеше: Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. нең гаиләсе

Укытучы дәреснең бу өлешен сорау-җавап рәвешендә уздыра.

- Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. әтисенең исеме ничек?
- Габдулла.
- Әнисенең исеме ничек?
- Әминә.
- Бабасының исеме ничек?
- Габдул-Мотталиб.
- Сөт анасының исеме ничек?
- Хәлимә.
- Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. кайсы шәһәрдә туган?
- Мәккә шәһәрендә.
- Кайсы елда туган?
- Милади белән 571 нче елда туган.

Бу китерелгән исемнәр, туган елы һәм шәһәре кат-кат укучылар тарафыннан дөрес рәвештә кабатлана.

Укучылар Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. нең әтисенең, әнисенең, бабасының һәм сөт анасының исемнәрен, кайсы шәһәрдә һәм кайсы елда туганын дәфтәрләренә язып алалар.

Дәреснең 2 нче өлеше: Фил вакыйгасы

Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. нең туган елы “Фил елы” дип атала. Әйдәгез, белик әле, Фил елынданиләр булган икән?

Укытучы Фил вакыйгасын кыйсса рәвешендә кызыклы итеп, китаплардан рәсемнәрне күрсәтеп сөйли.

Кәгъбәтулла Мәккә шәһәрендә урнашкан. Кәгъбәтуллага кешеләр хаҗ кыла торган булганнар. Кешеләр Кәгъбәтуллага түгел, ә монда килеп хаҗ кылсыннар дип, Йәмән патшасы Әбраһа үз җирендә бер гыйбадәтханә салдырта. Ләкин кешеләр Әбраһа салдырган бинага хаҗ кылырга килмиләр. Моңа Әбраһаның бик каты ачуы килә. Ул гаскәр җыя һәм Мәккәгә барып Кәгъбәтулланы җимерергә тели. Гаскәрдә филләр дә була. Ул вакыт өчен филләр булу гаскәрнең бик көчле икәнлеген күрсәткән. Гаскәр Мәккәгә юл тота. Аллаһы Тәгалә шушы Әбраһаның үзен һәм аның гаскәрен һәлак итү өчен, алар өстенә бик күп кошлар җибәрә. Кошларның һәрберсендә өчәр кечкенә таш була: берсе – томшыгында, икесе – аякларында. Кошларның күплегеннән күк кап-кара була, хәтта күк үзе күренми. Әбраһа гаскәре турысына җиткәч, кошлар ташларын ычкындыралар. Бу ташлар эләккән кешеләрнең барчасы да һәлак була. Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә Кәгъбәтулланы җимерелүдән саклый.

Шул хакта укучылар белән диалог.

Укытучы сораулар биреп кыйссаны үзләштерүләрен тикшерә.

Укучылар “Фил елы”, Кәгъбәтулла, Йәмән, “Әбраһа патшасы” сүзләрен дәфтәрләренә язып алалар.

Дәреснең 3 нче өлеше: Мөхәммәд с.г.в.с. нең бала чагы

Пәйгамбәребез с.г.в.с. дөньяга килгәнче үк аның әтисе Габдулла вафат була. Ул туганда әтисенең вафат булганына ике ай үткән була. Әнисе Әминә аны Хәлимә исемле сөт анасына имезергә тапшыра. Хәлимә Мөхәммәд с.г.в.с. не ике ел буена хәләл сөтен имезеп тәрбияли.

Алты яшенә кадәр әнисенең янында була. Бер көнне әнисе белән Мәдинә шәһәренә әнисенең туганнарына кунакка баралар. Шунда әтисенең каберен дә карап китәләр. Кунактан кайткан вакытта, Әбва исемле авылга килеп җиткәч, әнисе авырып китә һәм вафат була. Әнисе бу

дөньядан киткәндә Пәйгамбәребез с.г.в.с. гә нибары 6 яшь кенә була. Бу хәлдән соң ул дәү әтисе Габдул-Мотталибта яши башлый. Ләкин ике елдан соң дәү әтисе дә вафат була. Бу вакытта Пәйгамбәребез с.г.в.с. гә 8 яшь кенә иде.

Укытучы: Хәзер без сезнең белән Пәйгамбәребез с.г.в.с. хакында бер мөнәҗәт өйрәнербез. Мин укыйм, ә сез минем артымнан кабатлагыз:

Мәккә шәһәрендә тудың,
Атаң иде Габдулла,
Анаң иде Әминә,
Йә Мөхәммәд Мостафа!

Атаң-анаң вафаты
Сине ятим калдырды,
Сине Аллаһ үстерде,
Йә Мөхәммәд Мостафа!

Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең бала чагы хакында укучылар белән диалог.

Укучылар мөнәҗәтне дәфтәрләренә язып алалар яисә аерым битләрдә язылганы таратыла.

***2. Дәресне йомгаклау.***

Дәрес ахырында укытучы Пәйгамбәр с.г.в.с. нең туган елын һәм үскән җирен, гаиләсен, туачак елда булган “Фил вакыйгасын”, балачак вакыты хакында кыскача кабатлап үтә. Сораулар биреп дәрестә үткән теманы үзләштерүләрен тикшерә.

***3. Өйгә эш.***

Укытучы өйгә дәрестә булганнарны өйдәгеләргә сөйләргә һәм картадан Мәккә шәһәрен күрсәтергә, дәрестә үткән мөнәҗәтне ятлап килергә куша.

# 6. ӘХЛАК ДӘРЕСЛӘРЕ

6.1 Әхлакның аңлатмасы
6.2 Әхлакның Ислам динендәге урыны
6.3 Кешенең ихтыяри тотышының төрләре
6.4 Әхлакның төп нигезләре
6.5 Ислам әхлагының көнбатыш этикетыннан булган аермасы
6.6 Әхлакны укытуның максатлары
6.7 Әхлак дәресләрен укыту методлары

## 6.1 Әхлакның аңлатмасы

“Әхлак” сүзе гарәп телендә “хульк”, “хулүк” (ягъни “холык”) сүзләренең күплек саны булса да, ул һәрвакыт берлек санында кулланган.

Имам Газали (һиҗри белән 505, милади белән 1111 елда вафат) “әхлак” сүзенә түбәндәге аңлатма бирә: “Кешедә булган ниндидер бер “комитет” булып, аның аркасында гамәлләр, һичбер мәҗбүрләүсез һәм алдан уйланмыйча, җиңеллек һәм рәхәтлек белән башкарылуы”[23].

Холык – ул кешенең үз тотышы һәм башкалар белән булган тотышы белән идарә итүче һәм тотрыклы (үзгәрми торган) сыйфаты, аермасы юк: ул тумыштан салынганмы әллә тормышта тупланганмы. Холык күркәм яисә бозык була һәм ул кылган гамәлләрнең төп нигезе булып тора. Кешенең холыгы күркәм булса, кылган гамәлләре дә күркәм була, бозык булса, кылган гамәлләре дә бозык була. Ләкин холыкның беленүенә киртә булучы сәбәпләр дә булырга мөмкин. Ислам дине күркәм әхлакка чакыра, бозык булганыннан тыя.

Күркәм холык ул – кешедә нык урнашкан, тумыштан

[23] Чагрыджи М. Мусульманская нравственность /Перевод с турецкого Г.Р.Ахметьяновой. Казань: Российский исламский университет, 2010. 8 бит.

салынган яисә тормышта тупланган булып, кешене үз ихтыяры белән, акыл ияләре каршында күркәм дип саналган гамәлләрне кылуга теләк тудыручы сыйфат. Мәсәлән, намуслы, юмарт, ярдәмчел булу, дөреслекне яклау, эчкерсезлек, кунакчыллык, ата-анага игелекле булу, сабырлык, шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек дигән нәрсәләрне эшләү. Ул шушы күркәм сыйфатларга ия була, гәрчә алар кешеләр арасында киң таралмаса да. Һәм хәйлә, гайбәт, яманлау, тәкәбберлек дигән нәрсәләрдән ерак була, гәрчә бу сыйфатлар кешеләр арасында киң таралса да.

Бозык холык ул – кешедә нык урнашкан, тумыштан салынган яисә тормышта тупланган булып, кешене үз ихтыяры белән, акыл ияләре каршында бозык дип саналган, гамәлләрне кылуга теләк тудыручы сыйфат. Мәсәлән, кабәхатлек, начарлык, ялганлау, хыянәт итү, мәкерлелек, көнчелек дигән нәрсәләрне эшләү. Ул шушы бозык сыйфатларга ия була, гәрчә алар кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә каршы килсә дә. Һәм әманәтле, тырыш, гадел булу, вәгъдәдә тору, шөкер итү, олыларга хөрмәт белән карау дигән нәрсәләрдән ерак була, гәрчә бу сыйфатлар кешеләр арасында киң таралса да.

## 6.2 Әхлакның Ислам динендәге урыны

Ислам дине – Аллаһы Тәгалә тарафыннан Рәсүле Мөхәммәд с.г.в.с. аркылы кешеләргә иңдерелгән ахыргы дин.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

الْيَوْمَ أَكْمَلْتُ لَكُمْ دِينَكُمْ وَأَتْمَمْتُ عَلَيْكُمْ نِعْمَتِي وَرَضِيتُ لَكُمُ الْإِسْلَامَ دِينًا

**«Бүген Мин сезнең өчен динегезне тулыландырдым һәм сезнең өчен Үземнең нигъмәтемне тәмамладым һәм Исламны сезгә дин итү белән разый булдым».** *(«Әл-Маидә», 5/3).*

Ислам дине үз эченә өч төрле хөкемнәрне ала: 1) Гакыйдә

хөкемнәрен; 2) әхлакый яисә тәрбияви хөкемнәрен; 3) гамәли (фикһ) хөкемнәрен.

Гакыйдә хөкемнәре – иман китерү тиеш булган хөкемнәр булып, балиг булучы һәм акылга ия булучы кеше аларны дөрес дип танырга һәм аларга иман китерергә тиеш. Ислам гакыйдәсе үз эченә Аллаһы Тәгаләгә, Аның Фәрештәләренә, Пәйгамбәрләренә, Китапларына, Ахирәт көненә, Тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһы Тәгаләдән булуына һәм үлгәннән соң янә терелүгә иман китерүне ала.

Әхләкый яисә тәрбияви хөкемнәр – кеше камил шәхескә әйләнүе өчен алар белән бизәнелергә яисә алардан читләшергә тиешле хөкемнәр булып, кешегә өстен (мәсәлән: дөрес сүзле, килешүгә тугрылыклы булу, сабыр булу) һәм начар сыйфатларны (мәсәлән: ялганлау, хыянәт итү, мәкерлелек) аңлатып бирү белән бәйле.

Гамәли (фикһ) хөкемнәре – кешеләрнең төрле проблемаларының чишелеш юлларын күрсәтүче хөкемнәр булып, кешеләрнең гамәлләре белән бәйле. Мәсәлән, гыйбадәт хөкемнәре (намаз уку, Рамазан аенда ураза тоту, хаҗ кылу, зәкят чыгару), мөгамәләт хөкемнәре (никах, сәүдә, аренда, бүләк итү, саклауга биреп тору һ.б.), җинаять хөкемнәре (зина кылу, хәмер эчү, риба).

Аллаһы Тәгалә тарафыннан барча пәйгамбәрләргә дә гакыйдә һәм әхлакый хөкемнәр бер төсле иңдерелгән булса да, әмма гамәли хөкемнәр бер төсле иңдерелмәгән, ә яшәгән халыкларның заманына, урынына, тормышларына туры китереп иңдерелгән.

## 6.3 Кешенең ихтыяри тотышының төрләре

1- Кешенең күркәм яисә бозык холыгыннан килеп чыккан гамәлләр: юмартлыгыннан бүләк бирүе, саранлыктан хәерне бирүдән баш тартуы, куркак булу сәбәпле качып

китүе, шәфкатьлек йөзеннән сәдака бирүе, хаклыкны яратучан булуы сәбәпле дөресен сөйләве, тәкәбберлек сәбәпле ярдәм сорауны инкяр итүе, сабыр булуы сәбәпле дәшмәве, гадел булуы сәбәпле үзенә җаваплыкны алуы һ.б.

2- Табигый тойгылар һәм хаҗәтләрне канәгатьләндерүдән килеп чыккан гамәлләр: ашыйсы килү сәбәпле ризык ашавы, эчәсе килгәндә эчүе, йокысы килгәндә йоклавы, ризыкка табигый ихтияҗы булу сәбәпле аны кәсеп итүе, мөбах булучы уеннар уйнап ял итүе һ.б.

3- Берәр фикергә өстенлек бирү өчен ихтыяри канәгатьләндерүдән килеп чыккан гамәлләр: мәсәлән, берәр гамәлдә нинди булса да мәнфәгать яисә файданы күрүе сәбәпле, шуны тормышка ашыру өчен юнәлүе, фикере дөресме яисә хаталымы икәненә карамастан (көндәлектә кәсеп белән шөгыльләнүчеләрнең гамәлләре күбесе булганы шикелле). Бу гамәлләрнең кайберләре табигый тойгыларны канәгатьләндерү теләгеннән килеп чыккан, кайберләре әхлакый теләкләрдән килеп чыккан, кайберләре башкадан килеп чыкканнар.

4- Шәхси һәм иҗтимагый әдәптән килеп чыккан гамәлләр: ашау һәм эчү, кием кию, йөрү, утыру әдәпләре, чисталык һәм пөхтәлек, тән һәм нәфислек белән бәйле әдәпләр: чәчне тарау, паклау һәм кистерү, тырнакларны кисү һ.б. Бу әдәпләрнең кайберләре күркәм холыкның тәэсирендә булыр, ә кайберләре бозык холыкның тәэсирендә булыр.

5- Аллаһы Тәгаләнең әмер һәм тыюларына яисә башка нәрсәләргә итагать итүдән килеп чыккан гамәлләр: бу гамәлләрнең кайберләре әхлак белән бәйле яисә гыйбадәт белән бәйле яки кешеләргә файда һәм игелек (рәхәтлек) китерү белән бәйле. Бу төргә шәригатьтәге әмер һәм тыюлар, дәүләттәге әмер һәм тыюлар (канунунар) һ.б. әмер һәм тыюлар керә.

6- Гореф-гадәтләрдән килеп чыккан гамәлләр: кайвакыт

алар әхлакый нормалардан яисә табигый тойгылардан килеп чыккан булалар яки бурычларга бәйле булалар я иҗтимагый тарафлардан һ.б.

7- Җәмгыятьтәге гамәлләргә тәкълид итүче (иярүче) гамәлләр: бу гамәлләр кайвакыт күркәм булалар, ә кайвакыт бозык.

## 6.4 Әхлакның төп нигезләре[24]

1- Әхлак ул кешенең тотышы һәм гамәлләре генә түгел, ә ул рухи сыйфатларының җыелмасы булып, кылган гамәлләренең чыганагы була. Әхлак ул кешене гамәлләрне башкарырга мәҗбүр итүче нәрсә. Димәк, югары әхлакле гамәлләр – ул кешедәге сыйфатларының нәтиҗәсе.

2- Әхлак тәрбиялелекнең, күркәм сыйфатларның булуы хакында гына белгертми, чөнки ул үз эченә күркәм дә, тискәре дә сыйфатларны ала. Шул сәбәпле, үзендә күркәм сыйфатларны үстергән кешегә күркәм әхлаклы, ә начар сыйфатларга ия булучы кешегә бозык әхлаклы диләр. Бу күзлектән караганда, әхлаксыз кешеләр юк. Ләкин, шуңа карамастан, күркәм әхлаклы кешеләрне әхлаклы диләр, ә бозык кешеләрне әхлаксыз дип атыйлар.

3- Әхлак ул кешенең кыска вакытлы халәте түгел, ә тумыштан салынган яисә тормышта тупланган сыйфатлардан һәм сәләтләрдән гыйбарәт.

4- Әхлак кешегә табигый рәвештә, үз ихтияры белән, җиңеллек һәм рәхәтлек белән вазифаларын башкарырга мөмкинчелек бирә. Бу мәсъәләгә Ислам дине аерата игътибар иттерә.

5- Югары әхлаклы булуга ирешү өчен күркәм сыйфатларның гадәткә керүе бик мөһим. Шул сәбәпле, галимнәр кешегә әхлакый тәрбия бирүгә, белем алуга зур

[24] Чагрыджи М. Мусульманская нравственность /Перевод с турецкого Г.Р.Ахметьяновой. Казань: Российский исламский университет, 2010. 8-10 битләр.

әһәмият бирә торган булганнар. Белем алу дигәндә, үз эченә әхлакка керә торган белемнәрне үзләштерү, үз-үзеңне тәрбия итү (монысы аерата әһәмиятле), үз өстеңдә эшләү, начар гадәтләрне бетерүне, әмер ителгән нәрсәләрне башкаруны һәм тыйганнардан ераклашуны гадәтләндерүне ала.

## 6.5 Ислам әхлагының көнбатыш этикетыннан булган аермасы

1) Этикет сүзе французча "ун этикет" сүзеннән килеп чыккан булып, җентекләп әзерләнәгән кагыйдәләр җыелмасы дигәнне аңлата һәм ул патша сарайларында гамәлгә ашырыла торган булган. Исламдагы әхлак исә, үз эченә, патшалар сараендагы кагыйдәләрне генә түгел, ә гадидән алып бик катлаулы иҗтимагый хәлләргә кадәрге булган үзара мөнәсәбәтләрне колачлый.

2) Көнбатыш этикетының төп максаты (дворяннар даирәсеннән гади кешеләр даирәсенә таралганнан соң да) – иң югары сыйныфны саклау. Ислам әхлагының чын максаты исә, аның дини характерда булуы: Ислам әхлагы Аллаһы Тәгаләне даими рәвештә исенә төшереп торырга тиешлегеннән килеп чыга һәм алар кешегә гадел һәм намуслы эш итәргә булышалар.

3) Ислам әдәбенең иң төп нигезләренең берсе – әхлаклылык – милләт көченең нигезе; шулай ук бозыклык һәм әхлаксызлык – милләтнең таркалуының, түбән тәгәрәвенең төп нигезе.

4) Көнбатыш "этикеты" Ауропада патша сарайларындагы кешеләр һәм аристократлар арасында аралашу кагыйдәләрен саклау өчен эшләнгән. Барлык сыйныфлар арасында тарала башлау белән этикетның әһәмияте кимегән. Бүгенге көнгәчә төрле төркемнәрдә этикет төрлечә. "Югары җәмгыять" әгъзалары ярлыракларныкы-

на караганда катлаулырак һәм катгыйрак этикет формаларын тоталар. Бу сыйнфый системадан килеп чыга һәм шуңа хезмәт тә итә.

Ислам әдәбе исә, кешеләрне сыйныфларга бүлү өчен һәм билгеле бер байлар төркеме өчен яисә башка төркемнәрне буйсындыру һәм кул астында тоту хакына хакимият кешеләре өчен эшләнмәгән. Ислам барлык мөселман җәмгыятенең әдәпне саклавына зур әһәмият бирә һәм ул бу гадәтләрне бер төркемнең өстенлеген яки аның сагы итеп карамый. Исламда җәмгыятьнең төрле катлаулары өчен төрле гадәтләр юк, ул аларны аерып карамый. Ислам әдәбенең максаты – мөселман җәмгыятен бердәм итү.

5) Көнбатыш этикеты үз-үзеңне билгеле бер тоту кагыйдәләреннән гыйбарәт булып, кешенең тышкы яктан булган тотышына гына игътибар итә.

Ислам динендә исә, кешенең тотышы иман, тугрылык һәм күркәм әхлак белән нык бәйләнештә тора. Үзара җаваплылык тоеп, күркәм җәмгыять төзү өчен бу дөньяда иман да, игелекле эшләр дә кирәк. Ә Ахирәттә иман һәм игелекле эшләр Җәннәткә керү өчен кирәкле шартлар булып торалар, чөнки имансыз кылган гамәл, нинди генә дәрәҗәдә яхшы булып күренсә дә, Аллаһы Тәгалә каршында кабул булмый.

## 6.6 Әхлакны укытуның максатлары

1) Укучыларның күңелләрендә Аллаһы Тәгаләгә карата сөю орлыкларын чәчү.

2) Әхлаксызлыкка төшүне хурлык дип санаучы һәм гыйлем алуны сөюче күркәм шәхес булдыру.

3) Мөселман кардәшен һәм башка кешеләрне яратучы шәхесне булдыру.

4) Күркәм әхлак белән зиннәтләнүләре өчен, укучыларга Ислам динендәге әхлакый нормаларны аңлату һәм аның тарафларын ачыклау.

5) Укучыларга бу дөнья тереклеге – имтихан йорты икәнлеген аңлату.

Аллаһы Тәгалә кешене бу дөньяда төрле сынаулар белән сыный.

Аллаһы Тәгалә әйтә:

تَبَارَكَ الَّذِي بِيَدِهِ الْمُلْكُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ الَّذِي خَلَقَ الْمَوْتَ وَالْحَيَاةَ لِيَبْلُوَكُمْ أَيُّكُمْ أَحْسَنُ عَمَلًا وَهُوَ الْعَزِيزُ الْغَفُورُ

**«Аның кулында ике дөньяның патшалыгы булган Аллаһ мүбарәк вә олугъ булды, Ул Аллаһ һәрнәрсәгә көче җитүчедер. Ул үлемне һәм тереклекне халык кылды, йөкләмәләр йөкләп сезне сынамак өчен, кайсыларыгыз яхшырак гамәлле икәнлеген белмәк өчен. Ул һәрнәрсәдән өстен вә ярлыкаучы».**

*(Әл-Мүлк, 67/1-2).*

Кешенең, дөнья тереклегендә сынала икәнлеген, алдан искәртеп кую кирәк. Кешенең акылын, калебен җиңүче нәрсәләр һәм дөнья тереклегендәге сынауны бозучы нәрсәләр бар: шәһвәтләр, кичектергесез эшләр, комсызлык (акчага хирыслык), үз-үзен ярату, башкалар өстеннән идарә итү теләге. Шул сәбәпле, шушы нәрсәләрдән файдаланып шайтан вәсвәсә кылырга мөмкин икәнлеге хакында кешене алдан искәртү һәм шуларны аңлату тиеш була.

6) Ислам әхлагы “Зарар кылма һәм зарар кылырга да тырышма” кагыйдәсенә нигезләнгән икәнен бәян итү. Бу кагыйдәдән ике хөкем чыгарыла:

Беренчедән: Кеше башлап зарар кылырга тиеш түгел, ягъни кешенең үзенә яки аның малына зарар китермәскә тиеш, чөнки зарар кылу – золым, ә золымлык итү (җәберләү, изү) – хәрам. Мәсәлән: күршеләргә кояш төшми торган итеп биек койма кору.

Икенчедән: Зарарга каршы зарар кылырга ярамый, чөнки зарар күрүче суд аркылы компенсация алырга тиеш. Мәсәлән: берәү икенче кешенең малын һәлак итсә, ул да

теге кешенең малын һәлак итәргә тиеш түгел, ә суд аркылы компенсация алырга тиеш. Зарарга зарар белән кайтару бары тик җинаятьчегә җәза бирүдә каралган, анысы да кешеләрне җинаять кылудан тыю өчен генә.

7) Укучыларда әхлак тәҗрибәсе булдыру. Яхшыны яманнан, яманны яхшыдан аера белү тәҗрибәсен кешедә яшьтән үк тәрбияләргә кирәк. Ул аны көндәлек тормышы, эше, эшчәнлеге, башкаларга мөнәсәбәте белән ныгыта гына бара. Бала чакта барлыкка килгән әхлак нормалары кешене җитлеккән, олыгайган чорына кадәр озата бара.

## 6.7 Әхлак дәресләрен укыту методлары

1) Укучыларның тотышларын үзгәртүнең ике ягы бар: А) Турыдан-туры булган үзгәртү: укытучының укучының хаталарына игътибар итүе һәм Ислам ысуллары белән аларны үзгәртергә тырышуы. Ләкин, бу ысуллар укучының абруен түбәнсетмәскә, кардәшләре каршында дәрәҗәсен төшермәскә тиеш. Шулай ук, бу ысуллар укучыларның үз хаталарын үзләре аңлап, аларны үз теләкләре белән үзгәртергә омтылыш булдырырга тырышырга кирәк һәм ул мәҗбүрләүгә нигезләнмәскә тиеш. Б) Турыдан-туры булмаган үзгәртү: укытучының күркәм мисалы белән.

Шушы ике очракта да элек яшәгән яхшы, изге кешеләрнең тормышларыннан яисә булган вакыйгалардан кыйссалар китерү белән күркәм әхлак тәрбияләү.

2) Әхлак тәрбиясе әхлак дәресендә генә түгел, ә бөтен укыту-тәрбия процессында укытучы-тәрбиячеләр тарафыннан тиешле шартлар тудыру һәм оештыру белән башкарыла – алар шәкертләрнең укуы, хезмәте, ялы, уены һәм һәртөрле эшчәнлеге дәвамында әхлак мөнәсәбәтләрен тиешле якка юнәлтә.

3) Әхлак дәресләрендә вәгазь сөйләү һәм нәсыйхәт бирү белән генә чикләнмәү, ә тормыштагы вакыйгалар белән дә бәйләү.

4) Сүзне ныгытыр өчен Коръән Кәримнән һәм сөннәттән дәлилләр китерү.

5) Хәләл һәм хәрам хакында сүз алып барганда Ислам кануннарының хикмәтләрен дә бәян итү, укучыларның калебләре тыныч булуы, акыллары яктыруы, Аллаһы Тәгаләнең хикмәтен тирән аңлаулары өчен. Пәйгамбәребез с.г.в.с. әйтте: “Бер галим шәйтанга карата, мең гыйбадәт кылучыга караганда, көчлерәк булыр”. (Ибн Мәҗә хәдисләр җыентыгында).

6) Югары әхлак сыйфатларны тәрбияләүдә билгеле бер эзлеклелек (ягъни, берсе артыннан икенчесе ялганып баруы) һәм билгеле бер максатка буйсындырылган булырга тиеш.

## Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр:

1. “Әхлак” сүзенә Имам Газали нинди аңлатма бирә? Шуны китерегез.
2. Холык нәрсә ул? Күркәм холык һәм бозык холык нәрсәне аңлата? Шуларны аңлатып бирегез.
3. Әхлакның төп нигезләре нидән гыйбарәт? Шуларны санап чыгыгыз.
4. Әхлакны укытуның максатларын китерегез.
5. Әхлак дәресләрен укытуның методлары нидән гыйбарәт? Шуларны әйтеп чыгыгыз.

## Кушымталар

*Әхлак дәресләрен алып баруга якынча программа үрнәге*

***Кереш***

1. Әхлакның аңлатмасы һәм әһәмияте.
2. Әхлакның иман, гыйбадәт һәм шәригатьнең башка тармаклары белән нык бәйләнештә булуы.

***Мөселманның күркәм холыклары***

1. Тугрылык
2. Мәрхәмәтлек һәм йомшак күңеллелек
3. Ярдәмләшү һәм юмартлык
4. Әдәп һәм хая
5. Шөкер итү
6. Тырышлык
7. Сабырлык
8. Әманәт

***Ямьсез холыклар***

1. Гайбәт
2. Ифтира (яла ягу) һәм бөһтан
3. Сүз йөртү
4. Ялган сөйләү
5. Тәкәбберлек
6. Исраф
7. Көнчелек (хөседлек)
8. Урлау
9. Кеше үтерү
10. Исерткеч (хәмер) эчү
11. Отышлы уеннар уйнау
12. Зина кылу

***Мөселманның әхлакый вазифалары***

Аллаһы Тәгаләгә карата вазифалар

Пәйгамбәребез с.г.в.с. гә карата вазифалар

Үзебезгә карата булган вазифалар
Әти-әнинең балаларына карата булган вазифалары
Балаларның әти-әниләренә карата вазифалары
Гаиләбезгә карата булган вазифалар
Туганнар һәм якыннар
Кардәшләр (дуслар)
Күршеләр
Ватан һәм милләтебезгә карата булган вазифалар
Бөтен кешеләргә карата булган вазифалар

***Ислам әдәпләре***

1. Ашау әдәпләре
2. Бәдрәфкә керү әдәпләре
3. Мәҗлес әдәпләре
4. Авыруның хәлен белү
5. Төчкерү әдәпләре
6. Юл әдәпләре
7. Кием әдәпләре
8. Мәчет әдәпләре
9. Сәламләшү әдәпләре

*Әхлак дәресләрен уздыру үрнәкләре*

**Тема: "Сердән авыр нәрсә юк"**

**Максат: Әхлаклыкның мөһим шарты буларак, сер саклау серләренә өйрәнү.**

***Дәрес барышы:***

***I. Өйгә бирелгән эшне тикшерү.***

***II. Уку мәсьәләсен кую (төркемнәрдә тикшерергә):***

- Борынгылар "Сер саклый белә торган кеше – акыллы кеше ул" дигәннәр. Нәрсә ул сер? Ни өчен сер саклый белү акыллы кешенең мөһим сыйфаты булып исәпләнә?

- Әлегә ачылмаган, танып беленмәгән үзлек, сыйфат һ.б. (Фән серләре ачыла башлады). Кешегә белдерергә ярамаган яшерен мәгълүмат һ.б. (Тыңла, үзеңә бер сер сөйлим). Берәр

нәрсәнең төп эчтәлеге, асылы, әһәмияте. (Компьютерның серләренә төшенеп барам). Ачыкланмаган, билгесез сәбәп. (Озак яшәүнең серенә төшендем).

Сер саклый белә торган кеше – ышанычлы кеше, ул илен дә, халкын да – беркемне дә сатмый һ.б. Әйтик, әгәр табиблар, Гиппократ антын бозып, авыруга: “Син якын арада яшәүдән туктаячаксың”, - дисәләр, нәрсә килеп чыгар иде?

- Фаҗига, әлбәттә.

- Димәк, без бүген дәрестә нәрсә турында сүз алып барачакбыз? Нәрсәгә өйрәнәчәкбез?

- Сер турында. Аны саклый белү серләренә өйрәнәчәкбез.

***III. Уку мәсъәләсен чишү.***

Методик күрсәтмә. Дәреснең башында яисә азагында уен оештырып була. Һәркем үз янында утырган иптәшенең колагына сер итеп кенә бер сүз әйтә. Түгәрәк ясап утырганда “сер” колактан колакка әйтелә.

1 нче бирем. (Төркемнәрдә тикшерегез).

Шушы ике очракта әйтелгән сүзнең кайсын “сер” итеп саныйсыз? Һәм ни өчен? Серне ничек кенә саклап була? Сер кайчан сер булудан туктый?

Үз-үзеңә бәя кую.

2 нче бирем. (Төркемнәрдә эшләгез).

Сер саклау белән бәйләнешле нинди мәкальләр һәм әйтемнәр беләсез?

“Сер тотмас – дус тапмас”.

“Сер күтәрә алмаслык кешегә сер сөйләмә”.

“Вак җан сер саклый белми” (һиндлар мәкале).

“Сердән авыр нәрсә юк” (французлар мәкале).

“Күп сөйләгән авыз – бәхетсезлек капкасы” (японнар мәкале).

3 нче бирем. (Төркемнәрдә тикшерегез).

- Нинди серләр була?

- Гаилә сере, табиб сере, хезмәт сере, хәрби сер, коммерция сере, хатлар язышу сере һ.б.

- “Сер” сүзе белән бәйләнгән нинди кинолар, әсәрләр беләсез?

- “Серле утрау”, “Серле сандык”, “Сертотмас үрдәк” һ.б.

- Сер тота белү ахыр чиктә гадәткә әверелергә тиеш дип уйлыйсызмы?

- Алай булмаганда, ул кешене акыллы дип санап булмый.

- Сер тота белмәүнең нәрсәләргә китерүе мөмкин?

- Күңелсез хәлләргә, фаҗигагә һ.б. Әйтик, дәүләт серен сату – илгә хыянәт итү дигән сүз.

- Сер тотмаучыларны ничек дип атыйлар?

- Хыянәтче, гайбәтче һ.б.

- “Ант итү” һәм “Ант кабул итү”не сез ничек аңлыйсыз? Аларның “сер” сүзе белән мәгънәви бәйләнеше бармы?

Җаваплар.

- Малайлар да сер саклый белә, кызлар да. Ничек уйлыйсыз: сер саклауга алар бер үк дәрәҗәдә җаваплы карыйлармы?

- Юк, әлбәттә.

- Ни өчен?

Җаваплар.

Укытучы өстәмәсе. Психологиядә шул билгеле: хатын-кызлар арасындагы дуслык ирләрнекенә караганда күпкә тотрыксыз. Балачак дуслыгы ирләрдә озак саклана. Хатын-кыз заты эмоциягә тизрәк бирелүчән. Ахирәтләр бер-берсе белән ныклы элемтә урнаштырырга омтылалар, бер-берсенә ышаныч арттыру өчен, эч серләрен сөйләүдән дә тартынып тормыйлар. Ике сердәшнең берсе хәйләкәррәк булса, ахирәтен “чишендереп” үк ташлый, тегесенең бер сере дә калмавы ихтимал.

Ир-ат бу мәсъәләдә тотрыклы. Сорауга җавап биргәндә төбенә тоз коймый, бар нечкәлеген сораштырмый (әгәр мәсъәлә үзенә кагылмаса). Ир-ат арасындагы сөйләшү, нигездә, эшлекле мәсъәләләр буенча гына алып барыла.

Малайлар зур төркемнәр эчендә дуслашалар (футбол

командасы) һәм тормышчан мәсъәләләрне тикшерергә яраталар. Кызларның дуслыгы исә, 2-3 кешедән артмый. Аларның сөйләшүе, нигездә, интим, шәхси мөнәсәбәтләргә кайтып кала. Шунлыктан, кызлар, сезгә киңәш: үз серләрегезне кемгә дә булса чишәр алдыннан бик ныклап уйлагыз ("Җиде кат үлчә, бер кат кис"). Шулай иткәндә ызгыш-талашка дә сәбәп аз калыр. Татар халык мәкалендә шундый сабак алырлык сүзләр бар: "Сер сөйләмә дустыңа, дустыңның да дусты булыр, ул да сөйләр дустына". Уйланылмый әйтелгән сүз, ахыр чиктә, үзегезгә каршы юнәлгән булуы ихтимал.

Үз-үзеңә бәя кую.

4 нче бирем. (Мөстәкыйль эш).

Сер саклый белү буенча үз-үзеңне тәрбияләү планын языгыз.

Көтелгән план үрнәге.

1. Әдәби әсәрләрне даими укып барырга һәм анализлый белергә

2. Сер тотмау – тәртипсез кешенең сыйфаты булуы турында мисаллар китерегез.

3. Беркайчан да бер кешенең серен өченче кешегә белгертергә ярамый.

4. "Сер" темасы белән бәйләнешле әдәби әсәрләр исемлеген төзергә.

***IV.*** Бүгенге дәрестә сүз нәрсә турында барды? Сер саклау серләренә ничек өйрәндегез? Дәрестән үзегезгә нинди сабаклар алдыгыз? Дәрес сезгә ошадымы? Дәрес сезнең өчен файдалы булдымы?

***V. Өйгә эш бирү.*** "Безнең гаиләдә сер тота beləләрме" дигән темага гаиләдә сөйләшү оештырырга.

**Тема: “Үзең эшләгән эшкә җавап бирә белү – чын кешенең гүзәл сыйфаты”.**

**Максат: укучыларда үзләре эшләгән эшләргә җаваплылык тәрбияләү.**

***Дәрес барышы:***

***I. Өйгә бирелгән эшне тикшерү.***

***II. Уку мәсъәләсен кую:***

Бер вакыт бер бәләкәй малай урманда адашып калган. Ул юлны озак эзләгән, әмма таба алмаган. Һич көтмәгәндә аңа бер карт очраган. Шатлыгыннан малай аны кочаклап алган. “Мин адаштым, - дигән ул, - миңа урманда бик тә куркыныч. Минем бик ашыйсым килә. Үтенеп сорыйм ярдәм итегез миңа”. Бабай сабыйга карап алган да, башын чайкаган... һәм ары таба китеп барган. Малай аның артыннан йөгергән һәм бертуктаусыз кабатлаган: “Минем ашыйсым килә”. Ләкин бабай бу юлы да аңа бертөрле дә ярдәм күрсәтмәгән... Бераздан малай картның ни эшләгәнен күзәтә башлаган: бабай җиләк җыйган һәм агачтан чикләвекләр өзгән. Һәм малай да карт эшләгәннәрне кабатларга керешкән. Бабай ялгызын, кара урманда калганда ни эшләргә кирәклеген белгән, һәм малай да аңардан күп нәрсәгә өйрәнгән.

Төркемнәрдә тикшерү өчен сораулар:

- Урманда карт артыннан барып, малай нәрсәгә өйрәнгән? (Бар нәрсәне дә үзең башкарырга, мөстәкыйльлеккә, түземлеккә, максатлылыкка, хезмәт яратырга).

- Картның малайга булган мөнәсәбәтен нинди бер сүз белән әйтеп була? (Үзлектән эшли алу – җаваплылык).

- Шулай итеп, бүгенге дәрестә без нәрсә турында сүз алып барачакбыз?

- Эшне үзлектән эшләү турында.

***III. Уку мәсъәләсен чишү.***

1 нче бирем. (Төркемнәрдә тикшерегез).

- Нәрсә ул җаваплылык?

- Җаваплы булу хисе, эшкә җитди караш. Нәрсәгә дә бул-

са тулы хуҗа булу, барлык хокуклардан файдалану һәм бурычларны үтәү үз өстеңдә булу (Бөтен җаваплылыкны үземә алам).

- Үткәннәргә кайтып хәтерегезгә төшерегез әле: туган көнегездән алып сезнең эшләрегез өчен кемнәр үзен җаваплы итеп сизде икән?

- Бишектә ятканда безнең өчен җаваплылык әниебезгә төште. Без бераз үсә төшкәч, җаваплылыкны әтиебез алды. Без балалар бакчасына йөри башлагач, җаваплылык тәрбиячеләргә кайтып калды. Без мәктәпкә укырга баргач, җаваплылык укытучыларга һәм сыйныф җитәкчеләренә йөкләтелде. Без уку йортларына (техникумнарга, институтларга һ.б.) укырга кергәч, үзләрен җаваплы итеп мөгаллимнәр, үзлелектән эшли башлагач – җитәкчеләр сизәчәк.

- Ничек уйлыйсыз: болай итү яхшымы, начармы?

(Фикерләр аерыла. Бәхәсләшкәннән соң шундый уйга киләләр: һәркем үзе башкарган эш өчен үзе җавап бирергә тиеш һәм моның өчен аңа мөмкинлекләр тудырырга кирәк).

- Уйлап карыйк әле: эшне нәрсәдән башларга? Өй шартларында, мәктәптә? Җәмәгать урыннарында? Йортта һәркем бәләкәй чактан ук нәрсәдер эшләү (өй җыештыру, кибеткә йөрү, чүп түгү, гөлләрне карау, бакчада эшләү һ.б.) өчен үзендә җаваплылык тоярга тиеш. Мәктәптә – үзидарә органнарында эшләү һ.б. Җәмәгать урыннарында – юл кагыйдәләрен үтәү, җәмәгать тәртибен саклау һ.б.

- Сез: “Мин үз гомерем өчен үзем җаваплы” дип әйтә аласызмы? Монда сез нинди бурычлар үтәүне күз алдында тотасыз? (Мин – акыллы кеше, минем омтылышларым нык, сер саклый беләм, үз эшемне үзем җаваплылык тоеп башкарам, яшәү өчен кирәк булган бар нәрсәне үзем эшлим, кем дә булса миңа һөҗүм ясаса, үземне саклый алам, юкбарга кәеф-сафа кормыйм һ.б.).

- Үз-үзеңә җаваплы булуны сез ничек аңлыйсыз? (Моны үзеңне яратырга тиешсең дип аңларга кирәк. Безнең күпләребез үзләрен үзләре үк яратмый. Үзебезгә башкачарак итеп карамыйбыз. Безнең һәрберебездә башкалар белән бүлешү өчен сирәк очрый торган байлык бар. Һәркем үзен яратырга һәм үзенә җаваплылык алырга тиеш. Үзебезне күпме ныграк яратсак, яшәвебез шул хәтле уңышлырак булачак).

- Җавапсызлыкның нәрсәләргә китерүе мөмкин? (Чернобыль фаҗигасе, үткәргеч торбаларның шартлавы, елгаларга агулы матдәләр агу, көтелмәгән үлем, төрле йогышлы авырулар йоктыру, сәламәт булмаган балалар туу, гаиләләр таркалу, янгыннар, юл-транспорт һәлакәтләре һ.б.).

- Балалар тарафыннан мәктәптә һәм өйдә нинди җавапсыз эшләр эшләнә? (Начар өлгереш, мәктәп милкен вату, стеналарга, өстәл өсләренә язу, агачларны сындыру, әти-әниләргә дорфа сүзләр әйтү, күршеләрнең тынычлыгын бозу, урлашу, хокук бозу, җинаять ясау, янгыннар чыгару, бер гаебе булмаган кешеләрнең үлүе һ.б.).

Үз-үзеңә бәя кую.

2 нче бирем. (Мөстәкыйль эш).

Үзеңдә җаваплылык сыйфатлары булдыру буенча үз-үзеңне тәрбияләү планын төзергә (күренекле кешеләр, китап батырлары, танышларыгыз, якыннарыгыз тормышыннан мисаллар табарга: көндәлек режим белән яшәргә, үзең башкарган эшләргә көндәлек контроль булдырырга һ.б.).

***IV.*** Без бүген нәрсә өйрәндек? Үз-үзеңә җаваплы булуны ничек аңлыйсыз? Үз эшеңә җаваплы булу нәрсә дигән сүз? Җавапсызлыкның нәрсәләргә китерүе мөмкин? Дәрес файдалы булдымы?

***V. Өйгә эш бирү.***

1. Үзеңдә җаваплылык сыйфатлары булдыру буенча үз-үзеңне тәрбияләү планын төзеп бетерергә.

2. Гаиләдә “Һәр гаилә әгъзасы нәрсә өчен җаваплы?” мәсьәләсен тикшерергә һәм шул нигездә иҗади эш хәзерләргә.

3. Минем тормышымда җавапсызлык күрсәткән очраклар булдымы икән?” – дигән темага иҗади эш язарга.

# 7. МӨСЕЛМАН ДИНИ БӘЙРӘМНӘРЕ

7.1 Мөселман дини бәйрәмнәре
7.2 Мөселман бәйрәмнәрен уздыру максатлары
7.3 Мөселман бәйрәмнәрен уздыру методлары
7.4 Мөселман бәйрәмнәрен уздыруга киңәшләр

## 7.1 Мөселман дини бәйрәмнәре

Мөселман бәйрәмнәре Ислам дине традицияләренең зур өлешен алып торалар һәм динебезнең төп нигезләре белән бәйләнгән. Мөселман бәйрәмнәре кешеләрдә саф күңеллелек, чисталык, пөхтәлек, миһербанлылык кебек иң матур һәм кирәкле сыйфатларны тәрбиялиләр. Ә кеше кечкенәдән шушы матур бәйрәмнәр, күркәм гореф-гадәтләр йогынтысында тәрбияләнсә, аның күңелендә шушы моңнарга, бәйрәмнәргә, туган телгә, дини йолаларга ихтыяҗ гомерлеккә кала, ул үзен үз милләтенең һәм Ислам өммәтенең вәкиле итеп тоя, шуның белән горурлана.

Мөселманнарның бер ел эчендә бәйрәм буларак уздырыла торган мөбарәк көннәрен һәм кичәләрен карап үтик.

Һиҗри ел башы көне – мөхәррәм аеның беренче көне. Ай хисабы буенча яңа һиҗри ел башланган көн.

Гашура көне – мөхәррәм аеның 10нчы көне. Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. һәм сәхабәләр шушы көнне мөбәрәк санап, ураза тота торган булганнар. Күп пәйгамбәрләр бу көндә зур афәт һәм бәлаләрдән котылганнар.

Һиҗрәт кичәсе – сәфәр аеның 27нче кичәсе. Шушы кичәдә Пәйгамбәребез с.г.в.с., Әбү Бәкер әс-Сиддыйк белән, Мәккәи Мөкәррәмәдән чыгып, 12нче рабигыләүвәлдә Мәдинәи Мөнәвәрә шәһәренә барып җиткәннәр. Бу һиҗрәттән соң Ислам дине төрле тарафларга тарала. Шул сәбәпле мөселманнарның һиҗри елы мөхәррәм аеннан башлап хисап кыйлына.

Мәүлид кичәсе – 12нче рабигыл-әүвәлдә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. 571 нче елда 27 апрельдә – 12нче рабигыл-әүвәлдә дөньяга килгән. Бу көн, бөтен дөнья мөселманнарының, дөнья һәм Ахирәт бәхет-сәгадәтләренә сәбәп булган пәйгамбәребезнең туган көне булу сәбәпле, мөбәрәк көннәрдән санала. Бу көнне мәчетләрдә вәгазьләр сөйләнә, мөселманнар өйләрендә Коръән мәҗлесләре үткәрәләр, Пәйгамбәребез с.г.в.с. гә салаватлар әйтәләр.

Рәгаиб кичәсе – рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кичә. Бу кичәдә Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең әтисе Габдулла белән әнисе Әминәнең никяхлары булып, беренче мәртәбә күрешкәннәр.

Миграҗ кичәсе – рәҗәб аеның 27нче кичәсе. Бу кичәдә Пәйгамбәребез с.г.в.с. күккә ашып, Аллаһы Тәгалә белән пәрдә аркылы сөйләшә. Биш вакыт намаз уку шушы кичәдә фарыз ителә.

Бәраәт кичәсе – шәгъбан аеның 15нче кичәсе. Риваятьләргә караганда, бәндәләрнең бер еллык бәхет-сәгадәте шушы кичәдә билгеләнә. Шуның өчен бу кичә изгеләрдән санала. Бу кичәдә мәрхүмнәргә догалар кылына, фәкыйрьләргә хәер-сәдака өләшенә, мөселманнар бер-берсенә кунакка йөрешәләр.

Фәтех Мәккә көне – рамазан аеның 21нче көне. Бу көндә Пәйгамбәребез с.г.в.с. 12 мең гаскәре белән Мәккәи Мөкәррәмәне кяферләр кулыннан алып, кыйблабыз Кәгъбәи–Мөгаззәмәдән сыннарны чыгарган.

Кадер кичәсе – Рамазан аеның 27нче кичәсе. Бу кичә елның кайсы көнендә булуы ачык мәгълүм булмаса да, риваятьләр буенча, күбесенчә Рамазан аеның 27нче кичәсенә туры килүе ихтимал ителә. Бу кичәдә изге гамәлләрнең савабы башка кичәләргә караганда күпкә артыграк. Бу һәм рамазан ае тәмамланыр алдыннан булучы башка төннәр – йокламыйча, Аллаһы Тәгаләдән ярлыка-

вын теләп-ялварып, намаз-гыйбадәт белән уздырыла торган төннәр дип санала.

Гайдел-фитыр көне – шәүвәл аеның беренче көне. Рамазан аеның уразасы тәмам булганнан соң бәйрәм ителә торган көн. Бу көндә фәкыйрьләргә, ятимнәргә һәм мохтаҗларга ураза тәмамлану шатлыгы белән фитыр сәдакасы бирелә, гайд намазы укыла.

Гарәфә көне – гайдел-корбан көненнән әүвәлге көненә, зөл-хиҗҗә аеның 9нчы көненә туры килә. Хаҗ гамәлләре шушы көннәрдә эшләнәләр. Һәр ел бөтен дөньядан җыелган хаҗилар, "Гарәфә көнендә" Гарәфә тавында дога һәм гыйбадәттә булалар. Бу көндә якын туганнарның каберләрен зиярат итү, сәдакалар өләшү, якын туганнарга бүләкләр өләшү була.

Гайдел-Корбан көне – зөл-хиҗҗә аеның 10нчы көне. Бу көндә мөселманнар гайд намазы укыйлар, корбан чалалар, догалар кылалар. Шулай ук табын мәҗлесләре җыеп, туганнарын, дусларын, кардәшләрен чакырып юмартлык күрсәтәләр, вәгазьләр сөйләнәләр.

Тәшрик көннәре – зөл-хиҗҗә аеның 11нче, 12нче һәм 13нче көннәре. Бу көннәр дә бәйрәм көннәре. Гарәфә көненең иртә намазыннан башлап, 13нче зөл-хиҗәнең икенде намазына кадәр, җәмәгать намазларыннан соң, мөселманнар "тәкбир тәшрик" исемле тәкбирне әйтерләр.

Җомга көн – барча мөселманнар өчен олуг бәйрәм көне. Бу көндә мөселманнар мәчеткә җыелып җомга вәгазен һәм хотбәсен тыңлыйлар, җомга намазын укыйлар. Бу көндә өйдә, җомга көнен хөрмәтләп, бәйрәм табыннары әзерләнә, тәүбәләр ителә, догалар кылына, сәдакалар бирелә.

## 7.2 Мөселман бәйрәмнәрен уздыру максатлары

1) Бәйрәм (кичә) хакында белешмә бирү, аның фазыйләтләрен ачыклау, мөселманнар өчен әһәмиятен, аның белән бәйле тарихи вакыйгаларны тасвирлау.

2) Күркәм сыйфатларга карата мәхәббәт тәрбияләү, начар сыйфатларга карата тискәре мөнәсәбәт булдыру.

3) Балаларга бәйрәмдә катнашу тәртибен сеңдерү, үзара аралашу, үз-үзеңне тотуны тәрбияләү.

## 7.3 Мөселман бәйрәмнәрен уздыру методлары

Мөселман бәйрәмнәрен уздыруга ниндидер аерым һәм төгәл методлар юк, чөнки мондый бәйрәмнәрне уздыручылар үз тәҗрибәләренә һәм үзләре биргән өстенлекләргә таяналар. Шулай ук, бәйрәмнәрне уздыру методлары бәйрәмдә катнашучыларның яшенә, дини яктан булган белемнәренә карый. Дини бәйрәмнәрне уздырганда түбәндәге факторларны исәпкә алу кирәк:

- бәйрәмнең яисә кичәнең кайсы төре уздырылуы – бу иң беренче исәпкә алырга тиешле булган фактор, чөнки аңа карап бәйрәмнең (кичәнең) планы төзелә, нәрсәгә күбрәк басым ясалырга тиешлеге күренә һ.б.;
- бәйрәмнең (кичәнең) уздыру урыны;
- һәрбер бәйрәмне (кичәне) уздыру методлары аерым була һәм алар катнашучыларның кызыксынуларына бәйле;
- бәйрәмдә (кичәдә) булган барча нәрсәләр (чыгышлар, уеннар, сәхнәләштерелгән постановкалар һ.б.) катнашучылар тарафыннан кабул итәрлек булырга тиеш; алай булмаса бәйрәм (кичә) кызык булмаячак.

## 7.4 Мөселман бәйрәмнәрен уздыруга киңәшләр

1- Уку елы башында мөселман бәйрәмнәрен уздыру планын төзү, аларның уздыру вакытларын һәм җаваплы кешеләрен билгеләү.

2- Бәйрәмгә алдан ук әзерләнә башлау: уздыру сценариясен җитәкчедә раслау, бәйрәмдә катнашучы балаларны һәм укытучыларны бәйрәмне уздыруга җәлеп итү, аларны оештыру.

3- Бәйрәм булачагын алдан ук игълан итү: бөтен кешеләр күрерлек игълан элеп кую, әти-әниләргә һәм кунакларга чакырулар бирү һ.б.

4- Бәйрәм узачак урынны бәйрәмчә бизәү:

- бәйрәм белән котлау сүзләре язылган плакатлар элеп кую, мәсәлән “Яңа 1435 һиҗри ел белән!”, “Хуш килдең Рамазан!”, “Корбан гаете мөбарәк булсын!”, “Бүген Гашура көне!” һ.б.;

- бәйрәмгә туры килгән Коръән аятьләре, Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең хәдис-шәрифләре яисә хикмәтле сүзләр язылган плакатлар элеп кую;

- шарлар, милли сөлгеләр, динебезгә туры килгән башка төрле җиһазлар белән бизәү һ.б.

5- Бәйрәм тамашасы узачак сәхнә урынын уңайлы сайлау.

6- Бәйрәм карап утыручыларга уңайлы урын булдыру: кече яшьтәге балаларга, уртача яшьтәгеләргә һәм өлкәннәргә.

7- Бәйрәмне әгүзе-бисмиллә, Аллаһы Тәгаләне мактау сүзләре, Пәйгамбәребез с.г.в.с. гә салават әйтү белән башлап җибәрү.

8- Сәлам сүзләре, җыелуның сәбәбе кыскача гына әйтелер, соңыннан Коръән Кәрим укылыр һәм кыскача дога кылыныр. Коръән Кәримне укыганчы азан да әйтелергә мөмкин, бәйрәменең төренә карап.

9- Бәйрәм вакытында кемгәдер вәгазь яисә котлау сүзләре өчен вакыт бирелсә, бу вәгазьләр һәм сүзләр артык озын булмаска тиеш, ә кыска, аңлаешлы һәм тәэсирле. Мондый вәгазьләр һәм сүзләр ике-өч кешедән артса, алар бербер артлы түгел, ә башка тамашалар белән аралаштырып бирелсә отышлырак булыр.

10- Бөтен бәйрәмнәрдә дә һәм бәйрәм барышында да чыгыш ясаучылардан бер үк кешеләр булмаса яхшырак. Мөмкин булган хәтле күбрәк кешеләрне бәйрәмдә катна-

шуга җәлеп итү кирәк, чөнки бу катнашучыларга да файдалы һәм катнашучыларның әти-әниләренең дә, танышдусларының да күңелләренә хуш килә.

11- Һәрбер дини бәйрәмне уздырганда, бәйрәмнең төреннән чыгып, бу бәйрәмне уздыруның максатларын дөрес кую һәм аны уздырганда халкыбызның тарихына, аның белән бәйле гореф-гадәтләренә игътибар итү кирәк. Шул сәбәпле бәйрәм вакытында мөнәҗәтләр уку, шагыйрьләребезнең шигырьләрен уку күркәм булыр.

12- Бәйрәм белән бәйле сәхнәләштерелгән постановкалар кую.

13- Бәйрәм азагында кабат котлау сүзләрен әйтү, бәйрәмдә катнашканга рәхмәтләр белдерү һәм кыскача дога кылып тәмамлау.

14- Бәйрәмнән соң чәй эчү мәҗлесе уздыру.

## Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр:

1. Мөселман бәйрәмнәренең төшенчәсе, әһәмияте нидән гыйбарәт?
2. Мөселманнарның нинди бәйрәмнәре, мөбарәк көннәре һәм кичәләре бар? Шуларны, аңлатмалары белән, китерегез.
3. Мөселман бәйрәмнәрен уздыруда нинди максатлар куела? Шуларны әйтеп чыгыгыз.
4. Мөселман бәйрәмнәрен уздыру методларын китерегез.
5. Мөселман бәйрәмнәрен уздыруга нинди киңәшләр бирелә? Аларны әйтеп чыгыгыз.

## Кушымталар

*Мөсеман бәйрәмнәрен һәм кичәләрен уздыру үрнәкләре*

***№1***
***Рамазан – дуслык, кардәшлек бәйрәме***
***(кичә уздыру сценариясе)***

Методлар:

1) Укучылар белән әңгәмә (ураза тотуның кирәклеге, Ислам динендәге мөһимлеге).

2) Кичәне алып баручының балалар белән эшләве (кичә сценариясен кабатлау).

3) Залны бизәү (мәчет рәсеме, хәдисләр, догалар, ризыклар, магнитофон).

4) Кешенең асыл сыйфатларын билгеләү (әби роле аркылы әдәп кагыйдәләрен искә төшерү, кабатлау).

Зал бәйрәмчә бизәлгән. Алгы планда мәчет рәсеме ясалган, хәдисләр, догалар язып эленгән, бер якта өй сурәтләнгән, ризыклар белән өстәл куелган. Бер малай чыгып Коръән укый. Олырак кеше чыгып кыскача дога кыла.

Алып баручы: Бисмил-ләһи-р-рахмәни-р-рахим. Әссәләмү гәләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү! Аллаһы Раббыбызга барча мактауларыбыз, Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһү гәләйһи вә-сәлләмгә, аның әһлебәйтенә, сәхабәләренә салаватларыбыз булса иде! Хөрмәтле кунаклар, әти-әниләр! Без сезнең белән бүген Рамазан ае башланып китү бәйрәменә җыелдык. Бәйрәмебез мөбәрак булсын!

Рамазан ае – мөселманнарның изге ае, чөнки шушы айда Аллаһы Тәгалә тарафыннан Коръән иңгән. Шуңа күрә Рамазан аен кеше, Аллаһы Тәгаләгә күңеле белән якын килеп, ураза тотып уздырырга тиеш. Ураза тоткан кешенең күңеле сафланып, акылы ачылып китә.

Рамазан бәйрәме – безнең өчен аеруча изге дип санала. Ул өч көн үткәрелә. Бәйрәм көннәрендә бөтен җирдә туганлык хисе хөкем сөрә. Бу көннәрдә бер-берсенә үпкәләгән кешеләр килешәләр, дуслар очрашырга, туганнар бер-берсен йөреп чыгарга, һәркем әти-әнисенең хәлен белергә тиеш. Ятимнәр, фәкыйрьләр, бәхетсезлеккә очраган кешеләр дә игътибардан читтә калмасын. Бәйрәм көнне елаган күзләр көләргә, авырулар – күңелләренә юаныч алырга, нәниләр сөенергә тиеш. Бу бәйрәм кешеләрдә саф күңеллелек, чисталык, пөхтәлек, миһербанлык, игелеклелек кебек иң матур һәм кирәкле сыйфатларны тәрбияли.

1 бала: Җилфердәсен динебезнең
Яшел ефәк байрагы.
Рамазан – дуслык, туганлык,
Зур кардәшлек бәйрәме!

Магнитофон язмасында “Изге Рамазан” (Р.Яхин сүзләре һәм көе) җыры башкарыла.

2 бала: Рамазан ае килде,
Зурлап сәламен бирде:
Әссәләмү гәләйкүм,
Изге кешеләр! – диде.

Балалар “Әссәләмү гәләйкүм” җырын (Р.Әхиярова көе, Г.Садә сүзләре) башкаралар.

3 бала: Изге Рамазан ае –
Бик мөбәрак бер айдыр.
Аның башы – рәхмәт,
Уртасы – гафу итү, кичерү,
Ахыры – Җәһәннәм газабыннан котылудыр.

4 бала: И мөселман кардәшләр,
Динебезне тотыгыз!
Рамазан айлары җитте,
Уразалар тотыгыз!

5 бала: “Бисмиллә”, - диеп,
Телне ачыйк таңда.

Йөзне борып Кыйбла ягына.
Аллаһы Тәгаләнең биргән көнен зурлап,
Иман нуры җанда кабына.
Бисмилләһи-рахмәни-р-рахим!
Хөрмәтле кунаклар!

6 бала: Әссәләмү гәләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү! Мөселманнар шатланып көтеп алган изге Рамазан аебыз җитте!

Алып баручы: Изге Рамазан аебыз да башланып китте. Бу айда теләкләребез кабул булып, Аллаһы Тәгалә өйләребезгә – тынычлык, муллык, гаиләләребезгә – татулык, дуслык, балаларыбызга тулы иман насыйп итсен.

Рамазан аенда мөселман кардәшләр ураза тоталар. Нәрсә соң ул ураза? Ураза ул, безнеңчә, тыелып тору. Ураза тотучылар, таң атканнан алып кояш батканчыга кадәр, ашауэчүдән тыелып торырга тиешләр, аларга дару эчәргә, начар сүзләр әйтергә, кешегә яла ягарга, ялган сөйләргә ярамый. Сезнең дә, балалар, әби-бабаларыгыз ураза тоталар, намаз укыйлар.

Бер малай азан әйтә. Ике оныгын (малай һәм кыз) ияртеп, әби керә.

Малай: Әбекәй, азан әйттеләр бит, авыз ачарга вакыт җиткәндер инде.

Әби: Шулай шул, балакайларым, кояш та баеды инде, авыз ачарга вакыт җиткән.

Алып баручы: Исәнме, әбекәй!

Әби: Исәнме, кызым! Балакайларым, сез монда нишлисез?

Алып баручы: Без Рамазан бәйрәменә җыелдык.

Әби: И, шулаймыни!

Малай: Әбекәй, әйдә, авыз ачарга вакыт җитте бит инде.

Алып баручы: Әбекәй, килегез бирегә, башта авыз ачып, тукланып алыгыз.

Әби оныклары белән өстәл янына утыра.

Әби: Бисмилләһир-рахмәни-р-рахим”

Әби башта тоз, аннан җимеш каба. Оныклары да шуны кабатлый. Малай белән кыз сөйләшә һәм көлешә башлыйлар.

Әби: Нишлисез сез? Ашаганда көлешеп утырмыйлар дип, ничә мәртәбә әйттем мин сезгә, балалар?

Малай: Көлешсәк ни була, әбием?

Әби: Көлгәндә ялгыш ризыгыгыз сулыш алу җиренә кереп китәргә мөмкин.

Кыз: Шулаймыни, әбием, ярар, көлешмибез, алайса. Син туйдыңмы, Фаил?

Малай: Мин туйдым (киерелә).

Әби: Өстәл янында киерелеп утырмыйлар. Балаларым, бервакытта да туйдым дип әйтмәгез, ризыктан туймыйлар. Аллага шөкер, тукландым дияргә кирәк. Тамак туйдыргач, дога кылабыз.

Алып баручы: Әбекәй, утырып кына тыңлап тор, балалар бәйрәмгә матур-матур шигырьләр өйрәнделәр.

Балалар өйрәнеп килгән шигырьләрен сөйлиләр.

Әби: Балакайларым, бик матур шигырьләр өйрәнгәнсез.

Алып баручы: Безнең халкыбыз – моңлы халык бит ул. Элек әбиләребез бик күп бәетләр, мөнәҗәтләр белгәннәр. Әбекәй, син безгә бүген берәр мөнәҗәт әйтеп күрсәтмәссеңме икән? Әби мөнәҗәт укый: “Менә шундый заман җитәр”.

Әби: Хәзер сезгә Алсу апагыз “Сак-Сок бәете”н әйтеп күрсәтер (бәетне тыңлыйлар). Балалар, бервакытта да каргарга ярамый. Каргаган кеше үзе гөнаһлы була. Әниләрегезнең сүзен тыңлагыз, алар сезне бервакытта да каргамасыннар, яхшылыклар гына теләсеннәр.

Алып баручы: Менә без дә бәйрәмгә дип, “Әнкәйнең догалары” исемле җыр өйрәндек.

Балалар җырны башкаралар.

Әби: Ә сез, балалар, кешенең асыл сыйфатларын беләсезме?

Балалар: Әйе, беләбез.
1 бала: Кеше өчен иң әүвәл – намус, дигән.
Намусыңны сатып итмә табыш, дигән.
Байлык өчен илен, көнен саткан кеше.
Ике дөнья өчен дә ул – явыз, дигән.
2 бала: Икенчесе – иң кыйммәте – акыл, дигән.
Акылсызда акыл ягы такыр, дигән.
Акылсызда намус та юк; иман да юк.
Ялганга ант итеп, барын сатар, дигән.
3 бала: Өченчесе – иң кыйммәте – әдәп, дигән.
Әдәп көчле мәхәббәткә сәбәп, дигән.
Әдәпсездә бәхет тә юк, тәүфыйк та юк,
Кеше исемен күтәрү дә гаҗәп, дигән.
4 бала: Дүртенчесе – иң кыйммәтлесе – күңел, дигән.
Күңеле бозык кеше – кеше түгел, дигән.
Бозыкларга җир өстеннән асты яхшы,
Яшәмә дә үлеп җиргә күмел, дигән.
5 бала: Бишенчесе – иң кыйммәтлесе – сабыр, дигән.
Сабыр кеше зур бәхетләр табар, дигән.
Бер дә юкка ачуланып дөнья бозу
Бер кайгыдан икенчегә салыр, дигән.

Алып баручы: Әйе, кеше өчен намус, акыл, әдәп, күңел, сабырлык кирәкле сыйфатлар. Алар бер-берсе белән нык бәйләнгәннәр.

1 бала: Оран салмыйм, кычкырмыйм мин,
Масаймыйм синең белән.
Киләчәккә барасың син,
Туган тел, минем белән.
2 бала: Синең белән булганга мин,
Шатланып җырлыйм менә.
Җырлаган саен яңа җыр
Канат җәя күңелемдә.
3 бала: Аннан күтәрелеп китеп,
Оча дөнья күгенә,

Туган телем, хәзер миңа
Бөтен дөнья күренә.

Алып баручы: Аллаһы Тәгалә җир йөзенә тынычлык, һәммәбезгә дә сәламәтлек, бәхет, шатлык, авыруларга шифасын бирсә иде. Амин!

4 бала: Барыгызга да булсын хәер-дога,
Буыннар чылбыры өзелмәсен җирдә.
Изге нурлар иңсен һәр иманлы өйгә.
Рамазан бәйрәме шуның белән тәмам була.

***№2***
***Иманым – юлдашым***
***(хатын-кызлар өчен ял кичәсе сценариясе)***

Кичәне башлау:

- Коръән Кәримнең “әл-Бәкара” сүрәсеннән “Фәзкүрун” укыла;
- дога кылына;
- вәгазь сөйләнә (кыскача эчтәлеге): сәхабәләр бик тәкъва булганнар, бик күп гыйбадәтләр кылганнар, әмма алар шаярта да, тыйнак кына күңел ача да белгәннәр.

Танышу:

Безнең иң кечкенә шәкертебез Гөлия. Аңа 1 яшь (әнисе аны үзе белән алып йөри). Иң олы шәкертебез Ләйлә апа.

Сәхнәләштерелгән “Дәва” исемле сценка күрсәтелә:

Сәхнәгә Шифа исемле бер шәкерт чыга, авырыйм дип зарлана. Ләйсән исемле кыз янына килә.

Ләйсән: Беләм, сиңа иң шәп дәва – спорт белән шөгыльләнү. Менә сиңа каратэ алымнарын күрсәтәм, кабатла аларны!

Ләйсән бер ничә каратэ алымын күрсәтә, әмма Шифа аларны зәгыйфь кенә кабатлый, ахырдан “Булмый”, - ди.

Шуннан Ләйсән: “Алайса әнә табиб янына бар”, - диеп Нәсимә исемле табиб янына җибәрә.

Нәсимә ханым карый, кайсы җирен караса да әйтеп бара:

“Намаз кирәк, ә бу авыруыгыз ураза тотсагыз савыгыр, монысы зикерләр әйткәч бетәр, Аллаһы Тәгалә теләсә. Һәм тагын да файдалырак булыр, әгәр Коръән Кәрим укысагыз”. Кыскасы, рецептка исламча яшәү рәвешен язып бирә.

“Вәйселкарани” мөнәҗәтен һәммәсе бергә башкаралар:

Гасасы вар иде аның илкендә,
Камәре вар иде аның билендә,
Аллаһның зикре датлы телендә.

Кушымта:
Йәмән илләрендә вәйселкарани –
Гарәп чүлләрендә вәйселсолтани.

Пәйгамбәр мәсҗидтән өенә килде –
Гайшәдән сорады: Өйгә кем килде?
Дустының килгәне турында белде.

Кушымта:
Йәмән илләрендә вәйселкарани –
Гарәп чүлләрендә вәйселсолтани.

Һәр сәхәр вакытында бу иде касды,
Арпадин икмәге идеке ашы,
Акарды күзендән мөбәрәк яше.

Кушымта:
Йәмән илләрендә вәйселкарани –
Гарәп чүлләрендә вәйселсолтани.

Хиркасы вар иде дәва йонындан,
Гасасы вар иде хөрмә талыннан,
Һич хата чыкмас иде датлы телендән.

Кушымта:
Йәмән илләрендә вәйселкарани –
Гарәп чүлләрендә вәйселсолтани.

Габдулла Тукайның “Тәәсер”[25] дигән шигыре башкарыла:
Гомернең иң читен, җайсыз, уңайсыз бер минутында,
Әгәр янсам каты хәсрәт вә кайгының мин утында,

Укыйм тиз-тиз күңелдән бер гаҗаиб сүрә Коръәннән, –
Газаплар мәгънәви бер кул илән алынадыр җаннан.

Оча дилдән[26] бөтен шик-шөбһәләр, һәм мин җылый башлыйм:
Яңакларны мөкаддәс күз яшемлә энҗели башлыйм.

Бөтенләй сафлана күңлем; укыйм иман, булам мөэмин;
Киләрәхәт җиңеллекләр: хәлас булам[27] авыр йөкдин.

Ходаем! Син тыйган эшләр тәмам әкътагъ вә әбтәр[28], дим:
Иям баш сәҗдәгә: “Аллаһе хак! Аллаһе әкбәр!” – дим.

Күңелле конкурслар:

1. Кәгазьгә темасы белән бирем язып бирелә һәм берничә пар мөселман хатын-кызлары аны тавышсыз гына сүрәтләп бирергә тиешләр. Темалар: “Йокыдан уятучы сәгать һәм мөселман»; “Рамазан аенда мөселман кыз һәм күмәч”; “Ике ана әңгәмәсе – берсенең кызы иманлы булып мөселманча киенеп дин кануннарын үтәүче, ә икенчесенең кызы исламнан ерак булучы”.

2. Яулыкларны матур итеп ябып күрсәтү бәйгесе.

3. Сораулар биреп ярыш уздыру: 1) Коръән нинди

[25] Тәәсер – тәэсирләнү.
[26] Дил – күңел.
[27] Хәлас булу – азат булу.
[28] Әкътагъ вә әбтәр – кирәксез һәм яраксыз.

исемнәр белән атала? (“Әл-Китаб”, “әл-Мүбин”, “әл-Кәрим”, “әл-Кәләм”, “әл-Фүркан”, “әт-Тәнзил” һ.б.); 2) Коръәндә ничә сүрә бар? (114 сүрә); 3) Коръәндә иң озын сүрә кайсы? (“Әл-Бәкара” сүрәсе); 4) Коръәндә иң кыска сүрә кайсы? (“Әл-Кәүсәр” сүрәсе); 5) Кайсы сүрәдә Аллаһы Тәгаләнең исемнәре бер-бер артлы 15 тән артык саналган? (“Хәшер” сүрәсендә “Лә-ястәви”); 6) Коръәндә ике җирдә кешеләрнең хайваннарга әйләндерелүе турында әйтелә. Кайсы сүрәдә һәм аятьтә ул килә, нинди ул хайваннар? (“Маидә” сүрәсе, 60 аять, анда маймыллар һәм дуңгызлар турында сүз бара); 7) Кайсы пәйгамбәр бик кечкенә бөҗәк белән сөйләшкән? (Сөләйман г.с. кырмыска белән, “Нәмл” сүрәсе, 18-19 аятьләр); 8) Ислам дине тарафыннан хөрмәт ителә торган хатын кызлар исемнәрен атарга (Һава р.а.г., Асия, Сара, Хаҗәр, Мәрьям, Әсма, Нусәйбә, Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең хатыннары һәм кызлары һ.б.)...

Җиңүчеләргә бүләкләр бирелә.

***№3***

***Мөхәммәд с.г.в.с. белән бер кич***

***(хатын-кызлар җыены сценариясе)***

Ашъяулык идәнгә җәелә, кешеләр табын тирәли утыралар. Коръән Кәримнән “әл-Бәкара” сүрәсеннән “Фәзкүрун” укыла, дога кылына.

Алып баручы: Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән нигъмәтләре чиксез, шуларга Аллаһы Раббыбыз шөкер итәргә куша. Бу дөньяда Ризыкландыручы да Ул. Кешенең яшәешен саклау өчен кирәкле булган минималь микъдарда ризык ашауның хөкеме – ваҗиб (тиеш). Моннан артыгын ашау – мөбах (кылган кеше дә, кылмаган кеше дә – саваплы да булмас, гөнаһлы да булмас). Кешенең гәүдәсе үзләштерә алган микъдардан артыграк ризык ашауның хөкеме – хәрам (катгый тыелган). Пәйгамбәребез с.г.в.с. әйтте: «Ашагыз, эчегез, сәдакалар бирегез, тәкәбберләнмичә

киемнәр киегез, чөнки Аллаһы Тәгалә бәндәләрнең бирелгән нигъмәтләрне куллануларын ярата». (Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгы).

Беренче сөйләүче: Пәйгамбәребез с.г.в.с. һәм сәхабәләр тормышына күз салсак, ризыкны кабул итү белән бәйле аерым кагыйдәләр булган. Ашау әдәпләре түбәндәгеләр:

- ашарга утырыр алдыннан кулларны юу;
- ризыкны ашыйсы килгәндә генә ашау, ашап туйгач та ашказанын артыгы белән тутырмау;
- ашар алдыннан дога уку:

اللَّهُمَّ بَارِكْ لَنَا فِي مَا رَزَقْتَنَا وَقِنَا عَذَابَ النَّار بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَانِ الرَّحِيم

*(Әл-Лааһүммә бәәрик ләнәә фии мәә разәктәнәә вә кынәә гәзәәбән-нәәр. Бисмил-Ләәһир-рахмәәнир-рахиим)* мәгънәсе: “Әй Аллаһ, ризыкландырган нәрсәләребездә бәракәт бир һәм Җәһәннәм газабыннан сакла. Шәфкатьле һәм Рәхимле Аллаһ исеме белән башлыйм”

- ашар алдындагы доганы әйтергә онытса, исенә төшергәч тә шушы доганы укуы:

بسم اللهِ في الأوَّلِ والآخِرِ

*(Бисмил-Ләһи фил-әввәли вәл-әхыри)* мәгънәсе: “Аллаһ исеме белән ашау алдыннан да, ашап бетергәндә дә”;

- ашаган вакытта уң кул белән ашау һәм эчү (ризыкны өч бармак белән ашау мактаулы санала);
- әгәр ризыкны таба белән бирсәләр, үз каршысыннан гына алу;
- авызны ризык белән артык тутырмау, чәйнәп ашау, чәйнәмичә йотмау;
- ризыкны чәйнәгән арада сөйләшмәү, сөйләшкән вакытта ризыгы авызыннан чәчрәмәсен өчен, чәйнәп бетергәч кенә теләгән сүзен әйтү;
- ризыкны ашаганда яисә су эчкәндә, утырып ашау һәм эчү, ә баскан һәм йөргән килеш түгел;
- ашаганнан соң дога кылу:

الحَمْدُ للّٰهِ الَّذِي أَطْعَمَنَا وَسَقَانَا وَجَعَلَنَا مِنَ الْمُسْلِمِينَ

*(Әлхәмду лил-Ләәһил-ләзии әтгәмәнәә вә сәканәә вә җәгәләнәә минәл-мүслимиин)* мәгънәсе: “Безне ризыкландырган һәм мөселманнардан кылган Аллаһка барча мактаулар”;

- әти-әнисенә (яки пешерүчегә): “Аллаһның рәхмәте яусын”, - дип әйтү;
- ашаганнан соң кулларны юу, авызны чайкау.

Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең хәдисе: “Әдәм баласы тутырган капчыклар арасында корсактан да зарарлы капчык юк”.

Ашаган вакытта кеше карынын өчкә бүләргә тиеш: бер өлешен каты ризык, икенче өлешен су, өченче өлеше буш калырга.

Югарыда сөйләнгәне һәм ризыкка кагылышлы нәрсәләр буенча катнашучылар арасында ярыш үткәрелә. Иң яхшы җавап бирүчеләргә бүләкләр бирелә.

Алып баручы: Ә хәзер Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. тормышыннан берничә хикәятләр сөйләп үтәбез.

Икенче сөйләүче: Мөхәммәд с.г.в.с. гә Аллаһы Тәгалә биргән бер могҗиза турында. Бервакыт Әбү Тальха (Үммү Сәләмәнең ире) Мөхәммәд с.г.в.с не кунакка көтә, ә Пәйгамбәребез с.г.в.с. үзе белән 80 кеше алып килә. Ризык исә, әз була, чөнки ул бер Мөхәммәд с.г.в.с. өчен генә әзерләнгән була. Пәйгамбәр с.г.в.с. өйгә керә дә ризык пешкән казан янына килә һәм дога укый. Әбү Тальхага 10 кешегә ризык салырга куша. Шушы 10 кеше ашап чыгып киткәч, яңадан дога кылып, яңадан 10 кеше кереп ашый. Шулай 80 кеше ашый.

Өченче сөйләүче: Әнәс р.а.г. дән бер хәдис риваять ителә: Бервакыт Рәсүлүллаһ с.г.в.с. коллыктан үзе азат иткән кеше янына бара. Ул кеше тегүче була һәм Мөхәммәд с.г.в.с. не кабак белән сыйлый. Әнәс р.а.г. әйтте: “Шул вакытта, Рәсүлүллаһ с.г.в.с. нең кабак ашаганын күргәннән бирле мин үзем дә кабакны ашарга ярата башладым”. (Бохари хәдисләр җыентыгы).

Дүртенче сөйләүче: Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.с. Тәбук сугышына барганда (һиҗри белән 9 ел, Византиялеләр-румнарга каршы) могҗизалар була. Сулары, ризыклары бетә яза. Әбү Бәкер Пәйгамбәребез с.г.в.с. янына килеп әйтә: "Я Рәсүлүллаһ Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорамассың микән?". "Син моны чыннан да бик телисеңме?", - дип сорый Пәйгамбәребез с.г.в.с. "Әйе", - ди Әбү Бәкер. Мөхәммәд с.г.в.с. дога кыла да болыт килә һәм ул, кешеләр су эчеп туйганчы һәм савытларына тутырганчы, ява. Аннан соң Рәсүлүллаһ с.г.в.с. ризыкларны бер җиргә җыярга куша. Аллаһы Тәгаләгә дога кыла. Савытлар тула, ризык хәтта артып та кала.

Алып баручы: Ә хәзер, хөрмәтле мөслимә кардәшләр, сезгә кайбер сораулар бирәм: 1) Коръән Кәримдә нинди җимешләр, ризыклар искә алына? 2) Миграҗ кичәсендә нинди эчемлекләр тәкъдим ителгән иде, аның нәтиҗәсе? (Хәмер, сөт). 3) Ризык кабул итәргә ярамый торган вакыт кайчан? (Ураза вакыты). 4) Нәрсә ул мисвак, аның турында нәрсә беләсез? 5) Кемнәр алар "Маидә әһелләре"? ("Маидә" сүрәсе, 60 аять). 6) Ни өчен сүрә "Маидә" дип атала? 7) Терлек чалынганда нинди сүзләр әйтелә? (Бисмилләһи. Аллаһү Әкбәр!).

Йомгаклау сүзе: Мөселманнарның күбесе Пәйгамбәребез с.г.в.с. сөннәте белән яхшы танышлар һәм сөннәтнең Ислам тарихында нинди урын биләвен беләләр. Сөннәт кушканча яшәү һәр мөселманның бурычы. Исламча тормыш итү рәвешен тулаем үзләштергәнче күпмедер вакыт кирәк. Әмма, нигә соң бүген үк менә Пәйгамбәр Мөхәммәд с.г.в.с. белән бер көн үткәреп карамаска? Иртә белән торып Аллаһы Тәгаләне һәм Пәйгамбәр с.г.в.с. не үзегезнең беренче фикере һәм эшләрегездә искә алу сезнең өчен ни икәнлеген аңлап карагызчы. Аллаһы Тәгалә һәм Аның Илчесе турында йокыга китәр алдыннан һәм көндез уйлагыз. Аллаһы Тәгалә рөхсәт иткән эшләрне эшләгез, Ул

тыйганнардан тыелыгыз. Һәм бу көнегезне шул рәвешле Пәйгамбәр с.г.в.с. сөннәте буенча үткәреп, үзегезгә сорау куегыз, болай итү бик кыен идеме, әллә Аллаһның рәхмәте белән сезгә файдалы гына булдымы? Аннары Пәйгамбәр с.г.в.с. белән икенче бер көнегезне үткәрү турында уйлагыз.

# 8. ЯРЫШЛАР (БӘЙГЕЛӘР)

8.1 Ярышның (бәйгенең) аңлатмасы һәм максаты
8.2 Ярышны (бәйгене) уздыруга киңәшләр

## 8.1 Ярышның (бәйгенең) аңлатмасы һәм максаты

Ярыш (бәйге) – ул берәр өлкәдә беренчелекне алу, узып китү яки гомумән югары нәтиҗәләргә ирешү өчен көрәш. Ул Коръән Кәримне яттан белүчеләр арасындагы бәйге яисә Ислам дине нигезләрен белүчеләр арасындагы ярыш яки азан әйтү бәйгесе, я дини тематикадагы сәнгать төрләрен ясау (мәсәлән, матур гарәп язу үрнәкләре, шамаилләр, түбәтәй һәм калфаклар чигү ярышы булырга мөмкин) һ.б.

Ярышларның максаты – катнашучылар арасындагы осталык дәрәҗәләрен чагыштыру, Ислам диненә кызыксыну уяту. Шул сәбәпле, ярышлар (бәйгеләр) кешенең үсүенә, осталыкларының шомаруына (яхшыртуына) зур этәргеч була, чөнки алга таба бару үзеңне башкалар белән чагыштырганда гына була ала.

## 8.2 Ярышны (бәйгене) уздыруга киңәшләр

1) Ярышны (бәйгене) оештыру күп төрле баскычлардан тора (әзерлек, оештыру, ярышны үткәрү, нәтиҗәләр ясау һ.б.) һәм аларны оештырганда күп төрле мәсъәләләрне исәпкә алу кирәк: катнашучыларның яше, ярышның төре һ.б.

2) Ярышны (бәйгене) уздыру карарына килгәннән соң аңа ачык, үзенә җәлеп итә торган һәм ярышның төп асылын ачыклаучы исем сайларга тырышырга кирәк. Мәсәлән: "Әл-Форкан осталары бәйгесе" (Коръән Кәримне яттан белүчеләр арасындагы бәйге); "Сөембикә варислары"; "Моңлы азан тавышы" һ.б.

3) Ярышның (бәйгенең) төп асылын билгеләү: ярыш (бәйге) нинди юнәлештә булачагын ачыклау (мәсәлән: хәдисләрне белү, Пәйгамбәребез с.г.в.с. нең сирасын), катнашучылардан таләп ителә торган нәрсәләрне билгеләү (мәсәлән: Нәвәвинең 40 хәдис китабы буенча).

4) Ярышның (бәйгенең) бәя бирү шартларын һәм критерийларын билгеләү.

5) Ярышны (бәйгене) оештыручыларның төп вазифалары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- ярышның (бәйгенең) планын төзү;
- ярыш (бәйге) уздыру хакында алдан игълан итү;
- катнашучыларны җәлеп итү, моның өчен стендларны, игъланнар бирүне куллану; иң мөһиме – мөмкин булган хәтле күбрәк кешеләрне җәлеп итү;
- кунакларны чакыру;
- ярышны (бәйгене) уздыру өчен кирәк-яракларны алдан әзерләү (урындыклар, өстәл һ.б.)
- алып баручыны билгеләү;
- катнашучыларга дөрес бәя бирүләре өчен жюри әгъзаларын чакыру (моны башкаруда киңәшләр: 1) жюри әгъзаларының саны 3 кешедән алып 7 кешегә кадәр булуы; 2) бәя бирүдә тәҗрибәле булулары; 3) нәтиҗә бирүдә үз мәнфәгатьләре булмавы); 3) жюри әгъзаларын утырту урынын сайлау;
- ярыш (бәйге) узучы урынны әзерләү;
- әгәр ярыш (бәйге) сәнгать төрләрен ясау белән бәйле булса, экспонатларны кую урынын билгеләү;
- ярышны (бәйгене) ачып җибәрү тәртибе;
- җиңүчеләрне бүләкләү мәсьәләсе: бүләкнең төре, ничек тапшырылуы, кемнең тапшыруы һ.б.

**Кабатлау өчен сораулар һәм күнегүләр:**

1. Ярыш (бәйге) нәрсәне аңлата? Шуңа аңлатма бирегез. Ярышны (бәйгене) уздыруның нинди максатлары бар?

2. Ярышны (бәйгене) уздыруга нинди киңәшләр бирелә? Шуларны китерегез.

## Кушымталар

*Бәйге уздыру программасының һәм алдынгы урыннар алучыларны тәбрикләүнең үрнәге*

***Коръәнне яттан белүчеләр арасындагы бәйгенең программасы***

1. 9 00 – 9 05 – Коръән бәйгесен ачып җибәрү: Коръән уку һәм дога кылу.

2. 9 05 – 9 10 – Бәйгене оештыру комитеты җитәкчесенең сәламләве.

3. 910 – 950 – «Ярты җүз» белүчеләр арасындагы номинациядә катнашучыларның чыгышы (жюри әгъзалары каршында). Бәйге барышы арасында кунаклар өчен Коръән аятьләре, Пәйгамбәребез с.г.в.с. хәдисләре, дини эчтәлекле шигырьләр укыла, вәгазьләр сөйләнә.

4. 950 – 1000 – Мөнәҗәтләр башкарылуы.

5. 1000 – 1040 – «Кыска сүрәләр» белүчеләр арасындагы номинациядә катнашучыларның чыгышы (жюри әгъзалары каршында). Бәйге барышы арасында кунаклар өчен Коръән аятьләре, Пәйгамбәребез с.г.в.с. хәдисләре, дини эчтәлекле шигырьләр укыла, вәгазьләр сөйләнә.

6. 1040 – 1050 – Мөнәҗәтләр башкарылуы.

7. 1050 – 1120 – «Утызынчы җүз» белүчеләр арасындагы номинациядә катнашучыларның чыгышы (жюри әгъзалары каршында). Бәйге барышы арасында кунаклар өчен Коръән аятьләре, Пәйгамбәребез с.г.в.с. хәдисләре, дини эчтәлекле шигырьләр укыла, вәгазьләр сөйләнә.

8. Бәйгедә катнашучыларның барысына да истәлекле бүләкләр тапшыру.

9. Номинацияләрдә җиңеп чыгучыларның Коръән укулары (бөтен кешеләр алдында):

- «Утызынчы җүз»;
- «Ярты җүз»;

- «Кыска сүрәләр».

10. Жюри әгъзаларының чыгышы.

11. Җиңеп чыгучыларны игълан итү һәм истәлекле бүләкләрне тапшыру. Дога кылу. Бәйгенең тәмамлануы, оештыручыларга рәхмәтләр белдерү.

12. 1300 – 1330 – өйлә намазы.

13. 1330 – чәй мәҗлесе.

Алдынгы урыннар алучыларны тәбрикләү:

بسم الله الرحمن الرحيم

**Тәбрик итәбез!**

**2008 нче елның 13-14 мартында "Госмания" урта мәктәбе укучылары арасында Коръән Кәримне ятлау буенча I бәйге узды. Бәйге Рәсәй Ислам Университеты каршындагы "Коръән Кәримне ятлау мәркәзе" белән берлектә үткәрелде.**

***Алдынгылардан булучылар:***

**"Бер жүз" (جزء عم):**

**1 урын: Госман Яруллин (6 сыйныф)**
**2 урын: Ансар Вәлиуллин (11 сыйныф)**
**3 урын: Нурислам Вәлиуллин (9 сыйныф)**
**Хәлимә Яруллина (3 сыйныф)**

**"Ярты жүз":**

**1 урын: Булат Ибраһим (7 сыйныф)**
**2 урын: Илшат Садыйков (6 сыйныф)**
**3 урын: Мәрьям Миндиярова (6 сыйныф)**

**"Кыска сүрәләр":**

**1 урын: Мөхәммәд Шагимарданов (1 сыйныф)**
**2 урын: Зөһрә Миндиярова (1 сыйныф)**
**3 урын: Мәдинә Миндиярова (5 сыйныф)**
**Карина Исакова (3 сыйныф)**

**"Иң кечкенә укучы":**

**Габдрахман Әхмәд (1 сыйныф)**

**Ихластан сезләргә иң изге теләкләребез, Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә киләчәктә сезгә тагы да югарырак уңышларга ирешергә насыйп итсен!!!**

### *Мөхәммәд с.г.в.с. тормышына һәм эшчәнлегенә багышланган конференция*

***Алдан укучыларга конференциянең планы тәкъдим ителә:***

1) Мөхәммәд с.г.в.с. пәйгамбәрнең балачагы.

2) Мөхәммәд с.г.в.с. нең пәйгамбәрлеккә лаек кешелек сыйфатлары.

3) Пәйгамбәр булу ансатмы...

4) Мөхәммәд с.г.в.с. нең Аллаһы Тәгаләнең игътибарына лаек эшчәнлеге.

5) Киң кырлы эшчәнлекнең беренче нәтиҗәләре.

6) Мөхәммәд с.г.в.с. - хәрби җитәкче (Бәдер, Үхүд, Хандак сугышы, Мәккәне алу).

7) Хушлашу хаҗы.

Укытучы укучыларның барсына да Фәрит Яхинның "Олуг Мөхәммәд" китабын (Казан, 1999) укырга тәкъдим итә. Күбрәк белергә теләгән укучыларга өстәмә чыганаклар да китерелә.

Тиешле чыганаклар укылгач, конференция көне игълан ителә. Ул укытучының юнәлеш бирүче сүзе белән башлана. Анда укучылар күрсәтелгән мәсьәләләр буенча бер-бер артлы чыгыш ясыйлар. Пландагы аерым мәсьәләләрнең ачылуын кыскача түбәндәгечә билгеләргә мөмкин булыр иде.

***1) Мөхәммәд с.г.в.с. нең балачагы***

Мөхәммәд с.г.в.с. 571 нче елда дүшәмбе таңында, Гарәбстандагы Мәккә каласында урта хәлле гаиләдә дөньяга килә. Әтисе – Габдулла ибн Габдел Моталлип, улы туганчы, ике ай алдан вафат була.

Мөхәммәд с.г.в.с. не имезүчеләргә тәкъдим иткәннәр. Ятим булганлыктан, башта аны алырга теләмәгәннәр. Ниһаять, Хәлимә исемле тол хатын Мөхәммәд с.г.в.с. не алырга һәм имезергә ризалык биргән. Мөхәммәд с.г.в.с. Хәлимәдә 2 ел яши. Хәлимә бу вакытта үзенә ниндидер

игелек иңдерелгәнне тоя һәм әнисеннән Мөхәммәд с.г.в.с. не тагы 2 елга калдыруын сорый. Әминә риза була.

Дүрт яшендә ул әнисе - Әминә янына кайта. Бераздан 577 елда, алты яшендә Мөхәммәд с.г.в.с., әнисе авырып вафат булу сәбәпле, тулысынча ятим кала.

Мөхәммәд с.г.в.с. бабасы Габдел Моталлип гаиләсендә тәрбияләнә. Игелекле бала икәнен тоеп, ул аны ярата. Әмма бу хәл озак дәвам итми. Малайга 8 яшь тулганда, бабасы үлә, аны тәрбиягә агасы Әбү Талиб ала. Ул аның гаиләсенә үз балаларыдай кабул ителә. Мөхәммәд с.г.в.с. нең егерме буынга кадәрле ата-бабасының нәсел шәҗәрәсе билгеле.

***2) Мөхәммәд с.г.в.с. дә пәйгамбәрлеккә лаек кешелек сыйфатлары***

Мөхәммәд с.г.в.с. бик матур йөзле, әйбәт холыклы, урта буйлы, киң җилкәле һәм аксыл тәнле булган. Иптәшләре арасында намуслылыгы һәм тугрылыклы булуы белән аерылып тора. Аны һәркем ярата һәм «тугрылыклы» дип атый. Ул сыннарга табынмый, аларның исеме белән ант итми, гөнаһ кылмый. Аллаһы Тәгалә аны бөтен кешелек дәньсында иң зур эшне башкару өчен әзерли (һәм ул аны менә дигән итеп башкарып та чыга). Ул кырыс чүл шартларында үсә, саф гарәп телендә сөйләшә. Үзе турында ул: «Минем гарәп телем иң матуры, чөнки мин көрәешләрдән чыккан Сәед ибн Бәкер нәселендә тәрбияләнгән», - ди.

Пәйгамбәр баш һәм имән бармакларын күрсәтеп: «Менә боларның икесе кебек, мин ятимнәрнең яклаучысы», – ди. Ул ятимнәрнең кайгысын белә һәм һәрвакыт аларга ярдәм итәргә тырыша.

Мөхәммәд с.г.в.с. ярлы яши. Акчасы һәрвакыт аз була, ул үз-үзен хәләл хезмәте белән туендыра. Ул Мәккә кешәләренең сарыкларын көтә, моның өчен аз гына эш хакы алуга да риза була.

***3) Пәйгамбәр булу ансатмы...***

Пәйгамбәр - фарсы сүзе. Аллаһы Тәгаләнең җирдәге илчеләре. Пәйгамбәрләр кешелек тарихында хөрмәтле урын алып торалар.

Коръән Кәримдә 25 пәйгамбәрнең исеме зикер ителгән: Адәм г.с., Нух г.с., Идрис г.с., Салих г.с., Ибраһим г.с., Һуд г.с., Лут г.с., Юнус г.с., Исмәгыйль г.с., Исхак г.с., Ягъкуб г.с., Йосыф г.с., Әйюб г.с., Шогаеб г.с., Муса г.с., Һарун г.с., Әл-Ясәгъ г.с., Зүл-Кифел г.с., Дауд г.с., Зәкәрия г.с., Сөләйман г.с., Ильяс г.с., Яхья г.с., Гайсә г.с., Мөхәммәд с.г.в.с. Аларның барысына да Аллаһның сәламе һәм салаваты булса иде. Мөхәммәд с.г.в.с. – иң соңгысы.

Үзенең пәйгамбәрлек хезмәтчәнлеге башланганчы ук Мөхәммәд с.г.в.с. ялгызлыкта калырга һәм кешеләрдәнераграк торырга яраткан. Ул Хира дип аталган мәгарәсе булган Мәккә тавының башына менә торган булган. Анда уйланып, күзәтеп көннәрен һәм төннәрен үткәргән. Ул үзе белән азык-төлек алган, ә ул беткәч, өенә кайтып, тагын алган һәм шунда яңадан барган.

Бервакыт төнлә мәгарәдә чагында аның янына Җәбраил г.с. фәрештә килгән. Бу Рамазан аенда булган. Җәбраил г.с. аны көчле итеп күкрәгенә кыскан һәм әйткән: «Укы!». Мөхәммәд с.г.в.с.: «Мин укый белмим», — дип җавап биргән. Җәбраил г.с. аны икенче мәртәбә шулай иткән һәм шул ук җавапны алган. Өченче мәртәбәдә Җәбраил г.с. әйткән: «Кешене яралткан Аллаһ хакына укы. Укы һәм синең күркәмнәрдән күркәм Раббың каләм ярдәмендә кешегә белмәгәнен өйрәтте».

Мөхәммәд галәйһиссәлам пәйгамбәрлекнең җиңел эш булмаячагын, күп көч һәм хезмәт кую кирәк булачагын тиз аңлаган, әмма тоткан юлыннан чигенмәгән.

***4) Мөхәммәд с.г.в.с. нең Аллаһы Тәгаләнең игътибарына лаек эшчәнлеге***

Җәбраил галәйһиссәлам белән Мөхәммәд с.г.в.с. нең очрашуыннан соң берничә көн үткәч, Аллаһы Тәгаләнең

сүзләре иңгән: «Әй, син, киемгә төренгән! Тор һәм хәбәр ит, Аллаһны зурла, һәм киемнәреңне тазарт, һәм нәҗестән кач (күп аллалыктан, потларга табынудан) һәм үз байлыгыңны арттыру өчен генә изгелек кылма һәм Аллаһ хакына түз».

Мөхәммәд галәйһиссәлам үзенең Раббысын тыңлаган. Ул Сафа тавына менеп, халыкны чакырган. Кешеләр җыелгач, ул аларга әйткән: «Әйтегез, әгәр дә мин менә бу үзән артында атлы гаскәр сезгә һөҗүм итәргә килгән дисәм, ышаныр идегезме?» Алар: «Син һәрвакыт гадел, безнең сине ялганда тотканыбыз булмады, әлбәттә ышанабыз», – дип җавап биргәннәр. Шуннан соң ул аларга әйткән: «Мин - сезне авыр газаплардан котылдыра торган хәбәр китерүче».

***5) Киң кырлы эшчәнлекнен беренче нәтиҗәләре***

Исламны кабул иткән беренче ир-ат – Әбү Бәкер әс-Сиддык, беренче хатын-кыз – Мөхәммәд галәйһиссәламнең хатыны Хәдичә, беренче малай – аның икетуган энесе Гали ибн Әбү Талиб булган.

Бервакыт Мөхәммәд галәйһиссәлам үзенең икетуган энесе белән шәһәрдән чыгып киткән. Алар кеше күзеннәнераграк киткәннәр һәм гыйбадәт кыла башлаганнар.

Шул вакытта алар янына Әбү Талиб килеп чыккан һәм: «Әйт әле, Мөхәммәд, нәрсә бу?» – дип сораган. Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Бу Аллаһ дине, аның фәрештәләре дине, аның илчеләре дине, безнең атабыз Ибраһим дине. Аллаһы Тәгалә мине ул дин белән үзенең колларына җибәрде. Мин тугры юлга күндерергә һәм үгет-нәсыйхәт бирергә тиешле кешеләрнең син иң лаеклысы һәм син миңа ярдәм итәргә тиешсең», – дип җавап биргән.

Әбү Бәкер Мөхәммәд пәйгамбәрнең Исламга чакыруында аның уң кулы булган. Әбү Бәкернең дуслары күп булган. Ул яшертен генә аларда Ислам диненә мәхәббәт һәм потларга табынуга күралмаучанлык тәрбияли башлаган, Ислам динен кабул итәргә чакырган. Аның эшчәнлеге ар-

касында Госман ибн Гаффан, Зөбәер ибн әл-Гаввам, Муса ибн Өмәер, Сәгед ибн Әбү Вәккас, Билал ибн Рабах, Гаммар ибн Ясир һәм башка бик күпләр мөселманга әверелəләр.

***б) Мөхәммәд с.г.в.с. - хәрби җитәкче (Бәдер, Үхүд, Хандак сугышы, Мәккәне алу).***

Мөхәммәд с.г.в.с. нең эшчәнлегенең бер юнәлеше - сугышлар белән җитәкчелек итү.

Бәдер сугышы – ул Мәккә белән Мәдинә арасындагы җир.

Бу сугыш Мәдинәгә күченгәннән соң икенче елда үтә. Мөселманнар ягыннан анда 313 кеше, кяферләр ягыннан мең кеше бер-берсе белән сугышалар. Мөселманнар ягыннан бу сугышта иң мәшһүр сәхабәләр – Хәмзә һәм Гали бик зур батырлыклар күрсәтәләр. Бу сугышта кяферләрнең башлыгы Әбү-Җаһил да үтерелә, имансызлар җиңеләләр. Шушы елны кыйбла Бәйтел-Мөкатдәстән Кәгъбәтуллага күчерелә.

Мөселманнар һәм кяферләр арасында булган мәшһүр сугышларның икенчесе – Үхүд сугышы. Үхүд - Мәдинәдән бер миль ераклыктагы тау. Кяферләр, үч алу өчен, күп кенә гаскәр белән Мәдинә шәһәренә якынлашалар. Бу сугышта Хәмзә һәм җитмеш мең мөселман шәһит була. Сугыш кяферләрнең вакытлыча җиңүе белән тәмамлана, әмма бу өстенлек аларга файдага булмый.

Ике арадагы сугышларның өченчесе – Хандак сугышы. Кяферләр, ун мең гаскәр җыйнап, Мәдинәне һәм андагы мөселманнарның һәммәсен кырып бетерү хакында хыялланалар. Аларның килүе хакында ишеткән Мөхәммәд с.г.в.с., сәхабәсе Салман Фарси киңәшен тотып, Мәдинә шәһәрен чокыр (хандак) белән әйләндереп алдыра. Шуңа күрә дә бу сугыш «Хандак сугышы» дип атала.

Кяферләр Мәдинәне уратып алалар, әмма чокыр (хандак) аша шәһәргә үтеп керә алмыйлар. Аларны бары тик камап кына тоталар. Камап тоту озакка сузыла, шәһәр

халкында азык-төлек бетеп, ачлык башлана. Әмма озакламый кяферләр дә шул ук хәлдә калалар.

Бер кичне Аллаһы Тәгалә кяферләр өстенә бик көчле җил-давыл җибәрә. Аларның чатырлары җимерелә, тузгып һавага оча. Мөселманнарга зыяны тими. Кяферләр, оятлы булып, кайсы кая таралалар.

Мәккәне алу. Мөхәммәд с.г.в.с. үзенең мең дә дүрт йөз сәхабәсе белән Мәккәгә хаҗ кылырга чыга. Алар шәһәр янындагы Худәйбия авылына килеп җитәләр. Шунда Мөхәммәд саплаллаһу галәйһиссәлам, Мәккәгә алдан хәбәр бирер өчен, Госман хәзрәтләрен җибәрә. Әмма кяферләр Мөхәммәд с.г.в.с. нән башка кешегә хаҗ кылырга рөхсәт бирмиләр. Исәпләре: ялгыз кергән пәйгамбәрне тотып алу һәм үтерү була, ә мөселманнар сугышка әзер булмыйлар, үзләре белән берәр кылычтан башка бүтән коралларын алмыйлар. Әмма кяферләр дә сугышырга куркалар, үзләре куйган шартка мөселманнарның ризасызлыгын күреп торганга, алар солых тәкъдим итәләр. Бу килешүнең шартлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт була: ун ел буена сугышмаска, быелгы хаҗны киләсе елга калдырырга, елга бер мәртәбә мөселманнарга Кәгъбәтуллага кереп гыйбадәт кылырга рөхсәт итәргә. Мөхәммәд с.г.в.с. бу тынычлыктан оста файдалана һәм, яһүдиләрнең күп кенә җирләрен үзенә буйсындыру өчен, походлар ясый.

Мәккә кяферләре үзара тарткалашып, сугышып бетәләр, бер-берсен үтерешәләр. Мөхәммәд с.г.в.с., ун мең гаскәрен алып, Мәккә янына килә, шәһәрне камыйлар. Кяферләрнең барчасы бу хәлдә пәйгамбәргә иман китерәләр, Мәккә шәһәрен Мөхәммәд саллаллаһу галәйһиссәламгә тапшыралар.

Мәккә шәһәрен үзенә буйсындырса да, Мөхәммәд с.г.в.с. үзе Мәдинәдә яшәп кала.

***7) Хушлашу хаҗы***

Мөхәммәд галәйһиссәлам хаҗга бара һәм мөселманнар белән хушлаша. Аны гаять күп кеше озата бара.

Үзе янында булган һәммә кеше белән бергә пәйгамбәр Мәккәгә китә. Кәгъбәне күреп ул: «Ий, Раббым, данла аны, аңа зуррак дан, дәрәҗә, игелеклелек бир», – ди. Аннары ул Кәгъбәне җиде тапкыр урап чыга, кулы белән кара ташны тота, Мәкам-Ибраһим янында ике рәкәгать намаз укый, зәмзәм коесыннан су эчә һәм дөягә атланып Сафа белән Мәрвә арасын җиде тапкыр үтә.

Хушлашу хаҗы вакытында, Гарәфәт тавында, җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең түбәндәге сүзләре иңгән: «Бүген мин сезнең өчен динегезне тәмам иттем, сезнең өчен Исламның дин булуыннан канәгать булдым».

Сәфәр аеның ахырында һиҗринең 11 елында Пәйгамбәр галәйһиссәлам авырый башлый.

Мөселманнар Әбү Бәкер имамлыгында, иртәнге намазны укыганда, Аллаһ Рәсүле галәйһиссәлам үзен яхшырак хис итә һәм алар янына чыга. Аларның намаз укуларын күреп, ул бик шатлана. Мөселманнарның Әбү Бәкер кебек кеше кулы астында җыелуына йөрәге тынычлангандай була һәм ул канәгатьлек белән елмая. Кешеләр белән бергә соңгы намазын укый.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам һиҗринең 11-нче елында рабигул-әүвәлнең уникесендә, дүшәмбе көнне алтмыш өч яшендә: «Иң Бөек Дус янына... Иң Бөек Дус янына...» – дип әйтә-әйтә, якты дөньядан китә. Бу көн миладИ белән 638 нче елның 8 нче июненә туры килә.

Укучыларның чыгышлары, бер-берсенә сорау һәм җаваплары тәмамлангач, укытучы конференциягә йомгак ясый. Ул чыгышларның сыйфатына, укучыларның өстәмә чыганаклар өстендә эшләү үзенчәлегенә, боларның конференциядә, чыгышларда чагылуына бәя бирә.

***Диспутлар:***

- Коръәннең барлыкка килүе очраклы күренешме, әллә законлылыкмы?

- Нинди шартлар һәм Коръәннең үз сыйфатларыннан

нәрсәләр Коръәнне Изге, олуг, могҗиза, иң еш укыла торган Китап дәрәҗәсенә күтәргән?

- Коръәнне дуслык, тынычлык, иминлек, кем булуына карамастан, бербереңә хөрмәт китабы, диләр. Бүгенге көндә нәкъ менә Ислам дөньясында террорчылык, кан кою ешаеп китүенә нинди аңлатмалар биреп булыр иде?

- Ислам - гарәп сүзе булып, буйсыну, үзеңне Аллага тапшыру дигәнне аңлата. Шул ук вакытта Коръәндә шәхес иреге мәсьәләсе дә күтәрелә. Мисал өчен әл-Бәкара сүрәсенең 186 нчы аятен, әл-Хаҗ сүрәсенең 40-41 нче аятьләрен китерергә була. Мондый каршылыкларны нинди сәбәпләр белән аңлатырга? һ.б.

***Викториналар*** үз эчендә төрләргә бүленәләр: гакыйдә (дөньяга караш); фикх (Ислам хокукы); әдәп-әхлак кагыйдәләре.

Гакыйдә - дөньяга караш:

- Галәмнәрне юктан бар кылып, кешеләрне үз нигъмәтләре белән сөендерүче, галәмнәрнең тәрбиячесе кем ул? (Аллаһы Тәгалә).

- Безгә күренмәсәләр дә, безнең белән бергә параллель яшәүчеләр кемнәр алар? (Җеннәр).

- Үзләре күренмәсәләр дә, Аллаһы Тәгаләгә һәрвакыт гыйбадәт кылучылар, сәҗдәдә булучылар кемнәр ул? (Фәрештәләр).

Фикх - Ислам хокукы:

- Намаз укыр өчен нәрсә эшләргә кирәк? (Тәһарәт алырга).

- Пәйгамбәребез с.г.в.с. туган ай ниниди ай дип атала? (Мәүлид ае).

- Тәһарәт - намаз ачкычы, намаз нәрсә ачкычы? (Җәннәт).

- Мөселманнарның ике олы бәйрәме нинди ул? (Корбан гаете һәм Ураза гаете).

Әдәп-әхлак кагыйдәләре:

- Беренче кемнәрне ярату фарыз? (Аллаһы Тәгаләне,

Аның илчесе Мөхәммәд с.г.в.с. не, әти-әнине, туганнарны, күршеләрне, дусларны).

- Әнигә мәхәббәт хакында нинди хәдис беләсез? (Хәдис: Мөхәммәд пәйгамбәребез әйтте: “Иң әүвәл Аллаһы Тәгаләне, аның илчесен, әнине, әнине, әнине һәм аннан соң гына әтине яратырга кирәк”).

- Кунаклар килеп, табын әзер булгач, иң әүвәл кемнәр утыра? (Иң әүвәл олылар утырып ашагач кына, балалар утыра).

- Ата-анасын рәнҗеткән бала кая керер дип уйлыйсыз? (Җәһәннәмгә).

Саный китсәң, эш формалары байтакка җыела:

1- Мәккә, Мәдинә, Кодс (Иерусалим), Багдад, Каһирә, Димәшкъ, Истамбул кебек Коръәннең һәм тәфсирләрнең бишеге булган шәһәрләргә, Болгар, Казан калаларына, гомумән, изге урыннар буйлап читтән торып сәяхәтләр;

2- төбәктәге мәчеткә экскурсияләр;

3- мәчетләр, мәдрәсәләр, сарайлар кебек гүзәл архитектура корылмалары, аларның стеналарындагы бизәкләр, мозаика үрнәкләре белән танышу һ.б.

Бу кадәре информация тыгызлыгы таләп ителгән уку-укыту формаларын (дәресләр, конференцияләр һ.б.) уздыру укытучыдан ныклы хәзерлекле булуны таләп итә.

## Кулланылган әдәбият:

1. Валиуллин К.Х. Хозяйственное право в Исламе. Учебное пособие. Казань: ГБУ «Центр исламоведческих исследований» АН РТ, 2012.

2. Вәлиуллин К.Х. Ислам тәрбиясе. 1-4 сыйныфлар өчен дәреслек. Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе. Исламны өйрәнү үзәге. Яр Чаллы: “Ислам нуры” эшмәкәрлек үзәге, 2012.

3. Гармус Габдул-Мүгты. Әсәлиб тәдрис әш-шәригәти әл-исләмийәти /Ислам шәригатен укыту методлары, гарәп телендә. – Ирбид (Иордания): “Дәрул-Кинди”, 1992/1412.

4. Казыйханов В. Иман дәресләре. Мәктәп балалары өчен уку әсбабы. 1 нче кисәк. Казан: «Дом печати” нәшрияты, 2003.

5. Мәчетләр каршындагы берьеллык курслар өчен укыту программасы. Төзүчесе: Вәлиулла хәзрәт Якупов. – Казан: ТҖМДН нәшрияты, 2011.

6. Мөхәммәтшина А.В. Коръән һәм кешелек тарихы (дәрес эшкәртмәсе). Дәүләт тарих, архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы “Казан Кремле.” Татарстан Республикасы Милли музее. Казан, 2002.

7. Рамзи Г. Мәфһүмү әт-тәрбийәти әл-исләмийәти гиндә әт-тәрбәвийин әл-мүслимин фи әл-вәкти әл-хәдыр. Руъятү ли-мәфһүми әт-тәрбийәти әл-исләмийәти фи нитаки мәнзумәти әл-мәфәһим әл-исләмийяти /Хәзерге заман Ислам тәрбиясе галимнәре каршындагы “Ислам тәрбиясе”нең төшенчәсе, гарәп телендә. – Амман (Иордания): “Дару әд-дыяәү ли-н-нәшри вә әт-тәүзиг”, 1998.

8. Субхи И. Әт-тәрбийәтү әл-исләмийәтү вә әсәлиб тәдрисүһә /Ислам тәрбиясе һәм аны укыту методлары, гарәп телендә. – Амман (Иордания): Дару-л-әркам, 1983.

9. Хәсән әш-Шәркави. Нәхү тәрбияти исләмийәти / Ислам тәрбиясенең грамматикасы, гарәп телендә. – Әл-

Искәндәрия (Мисыр): “Мүәссәсәтү шәбәб әл-җәмигәти”, 1983.
10. Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Дидактика: Югары һәм махсус урта уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2002.
11. Чагрыджи М. Мусульманская нравственность /Перевод с турецкого Г.Р.Ахметьяновой. Казань: Российский исламский университет, 2010.

Камил Вәлиуллин

**Ислам тәрбиясе**
**дәресләрен укыту методлары**

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 14.11.2013.
Форматы 60х90 1/16
Яр Чаллы шәһәре
«Ислам нуры» эшмәкәрлек үзәге